Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

01
гыйнвар 2019
ISSN:2500-011X

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

СЕРГЕЙ ЛЫВИН «ТАТАРСТАН КИҢЛЕКЛӘРЕНДӘ»

Без – мираслы халык!

19 декабрь көнне «Безнең мирас» журналы редакциясенең редколлегия утырышы узды. Анда әлеге басманың, татар матбугатының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында фикер алышынды. Бу хакта тулырак язманы «Безнең мирас»ның 2 нче санынннан һәм beznenmiras.ru сайтыннан укырга мөмкин булачак.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең Мирас

12 +

01 (301)

гыйнвар 2019

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

48

17 **ЧИТАДА ЯҢА ЕЛ КАРШЫ АЛУ.** *У.Суләҗи*

72 **КӨНЕҢ ӨЧЕН ЯШӘМӘ...** *Ләлә Мортазина*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Фатих Кәрим**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Гәүһәршад.** *О.Иванова*
11 **Сәгыйдь.** *Ризаэддин Фәхреддин*
17 **Читада Яңа ел каршы алу.** *У.Суләҗи*
26 **«Тамашачы» журналы.** *Л.Гобәйдуллин*
32 **Садри Максуди Арсалның Сорбонна университетындагы соңгы дәресе.** *К.Локман*
36 **Саралы мең ыруы татарлары.** *Р.Мәрданов*
44 **Илдус Әмирханов: «Дәүләт милләтне тудырмый, милләт дәүләтне тудыра!»**
47 **Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре**

ТАТАР ГАМЕ

48 **Әлмәт театрының асылташы.** *Р.Сәгъди*
57 **Халкыбызның асыл заты.** *Ф.Җәүһәрова*

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

58 **Җәнҗал агачы.** *А.Сарманбәтов*

ДИНИ МИРАС

66 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

72 **Көнең өчен яшәмә...** *Л.Мортазина*
78 **Киләчәккә йөз тоткан берлек.** *М.Закир*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

80 **Уттан сау чыккан хәтер-хатирә (Фронтовик этием язмалары).** *Р.Мәһдиев*
86 **Истә, һаман да истә!**

СӘНГАТИ МИРАС

88 **Борынгы татар милли музыка уен кораллары.** *Р.Гыйләҗев*
94 **Хикмәтле хатлар.** *Ә.Гаффар*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

100 **Телнең киләчәге – безнең киләчәк!** *Ә.Гадел*

ХӘТЕР САГЫНДА

104 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
110 **Ябынчыда – «Муллалар коесы».**
112 **Киез итекләр иле**

116 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Гыйнвар*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Илсур Һадиуллин
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89520365448

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррирләре
Марат Закир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №Е-3565. Тираж – 1550 данә. Формат 70 Х 108 $^{1}/_{16}$.
Басарга кул куелды: 26.12.2018.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе иректә.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, "Татар энциклопедиясе" томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Татарстан киңлекләрендә».** 1960. *Фрагмент.* **Сергей Лывин** рәсеме

ФАТИХ КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА – 110 ЕЛ!

Фатих Кәрим

(09.01.1909-19.02.1945)

БЕЗНЕҢ УРАМДА

Без кояшка карап айныдык
Башны томалаган уйлардан.
Ил өчен без бары кайгырдык
Дәһшәт баскан авыр елларда.
Кунмасын, дип, коллык сөреме,
Аямадык канны, гомерне.
Үзәкләрне өзде кышкы җил,
Үлем белән бугазлашты ил.
Илем түзде, көче сынмады,
Көчен һөҗүм итеп сынады.
Көнбатыштан килгән каралык
Тузды төтен кебек таралып.
Кара диңгез ярсый шатлыктан;
Украина азат коллыктан.
Яшел каеннарны җил сөя,
Чөнки азат Белоруссия.
Сайрый кошлар безнең урманда,
Хәзер бәйрәм – безнең урамда.
Җилләр сирпи безгә һәрьяклап
Сирень чәчәгенең сафлыгын;
Җилдә шыбырдаган һәр яфрак
Хәбәр итә җиңү шатлыгын.

1944 ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2019

Гәүһәршад

Ольга Иванова

Гәүһәршад, хәттатны[1] ярдәмгә чакырмыйча, рисаләләрне[2] үз кулы белән яза иде. Ак кәгазьгә генә ышанып тапшырган сүзләренең кем колагына барып ирешүеннән дә күп нәрсә тора! Казан ханлыгында кенәз Василий китереп утырткан яшь хан – Шаһгалине түнтәрү нияте өлгереп килә. Үз-үзләренә сокланып утырган горур Гәрәйләр дә күңеленә ят, әмма бу вакытта Гәүһәршадка бүтән сайлау мөмкинлеге юк. Казан үз тәхетендә, Шаһгалигә караганда, Сәхибгәрәй солтанны хуш күребрәк кабул итәр иде... Ханбикә шул турыда язган юлларын кабат укып карады да, Юраучының кичәге сүзләрен искә төшереп, уйга калды. Ханнар бер-бер артлы килер дә китәр, әмма берсе дә хакимият дилбегәсен ныгытып тота алмас, диде бит ул. Бүген Казан тәхетендә Касыймнан кайткан йолкыш малай утырса, иртәгә Гәрәйләр нәселеннән бер солтан килсә, аңардан соң кем булыр? Ул йолдызбагарыннан бу кадәресен сорый алмый калды шул. Югыйсә, кичә егерме бишенче ай көне иде, Юраучы, вәгъдә иткәненчә, соңгы ноктасын куйгандыр да хәзер тыныч кына йоклап ятадыр.

Гәүһәршад, хәтерендәге бар нәрсәне җилләтергә теләгәндәй, кулын чайкап куйды. Багучылар турында уйлап утырмаячак ул, чөнки барысы да Аллаһ иркендә, тик бу ханлыктагы хакимият өчен көрәшүдән ул әле туктамаячак. Хатын ирләрчә авыр, киң адымнар белән бүлмәсе буйлап узды. «Казан белән кем идарә итәргә тиеш: Касыйм калдыгымы әллә Кырым кырдыгымы? Бөек халыкның өметләрен кайсы тарафка юнәлтергә? Гәрәйләр нәселе комсыз ерткычларга тиң, тәхеткә утыртсаң, алар бөтен ханлыкны талап бетерәчәк! Борын асты кипмәгән Шаһгали, ботагы кәкрерәк булса да, бөек Олуг Мөхәммәд нәселенә барып ялгана. Ичмаса, әз генә кыяфәте булса иде мәкруһның[3]. Шәехәүлиярдан, юньле кешеләрнең өнен алырлык, яисә эчен катырып көлдерә торган ярминкә шамакае сыман, шундый малай яралган бит, ә! Бу ханның, Гәүһәршадныкы кебек үк, эче пошадыр пошуын. Ә менә урыс патшасына, аның воеводаларына мәхәббәте күңелне укшыта!» Ханбикә кашларын җыерды, ачуы килеп мышнап куйды. Шул гарип адәмчек аның тынычлыгын алды бит, бүтән сайлау юлын калдырмады. Чынлыкта казанлылар белән Карпов дигән урыс илчесе оятсыз рәвештә, ачыктан-ачык идарә итә. Ә Шаһгали, кечкенә сабый сыман, аның сүзеннән

Ахыры. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

[1] Хәттат – матур язу остасы.

[2] Рисалә – хат *(тәрҗ. иск.)*.

[3] Мәкруһ – сөйкемсез, ямьсез *(тәрҗ. иск.)*.

чыга алмый. Карачының икәүдән-икәү генә калганда аны аңына китерергә тырышуына, нәфрәтле сүзләренә каршы, яшь хаким һаман үзенекен тукый:

– Безнең бабайлар кайчандыр Русьтан ясак түләткәннәр икән, ул бит Мәскәүнең буыны сыек чагы булганлыктан гына. Хәзер инде Русь көчәйде һәм бөек кенәзатакаем белән ике араны бозмаячакмын! – дип тәкрарлый.

Яшь ханның Казан аксөякләренә ошамый торган бу ләббәйкә укуына биш мең Касыйм казагы һәм воевода Поджогин җитәкчелегендәге мең урыс яугире төп терәк булып тора. Кодрәтле ханбикә, бу кадәресен белү өстенә, Шаһгалинең иң зур остазы һәм киңәшчесе булган баяр Карповны бигрәк тә яхшы хәтерли. Анысы казанлылар ягыннан әз генә канәгатьсезлекне дә иснәп-иснәнеп, һәр адымнарын саклап-санап кына тора. Баяр кушуы буенча, баш күтәрүләре ихтимал берничә татар аксөяге зинданга ташлангач, Гәүһәршад ханбикә икеләтә саграк кылана башлады. Хәтта иң югарыда утырган әмирләр дә бу астыртын эшнең җеп очы вафат булган Ибраһим ханның кызы кулында икәнлеген белмәделәр. Ул һәрвакыт үз биләмәсендә гомер итте, башкалага диван утырышларында катнашу өчен генә барып кайткалады. Әлеге югары даирә мәҗлесләрендә утыз өч яшьлек хатын үзенең барлыгын да сиздермәде. Ул инде, сүнгән бөек Олы Мөхәммәд нәселенең тамгасы булып кына, таштан уелган өнсез-телсез сын сыман, шым гына утыра, әзерләнә торган түнтәрелеш башчысы дип саналган Сәйед угланнан кала, берсе дә бу хатынның күңелен нинди ут өтәләгәнен белми иде.

Казан ханбикәсе яңадан киң урындыгына килеп утырды, гадәтенчә, аякларын бергә куйды. Фикер каймагы куерып җиткән иде, шуңа күрә кулы каләмгә үрелде, бормалы гарәп язуы кәгазь буйлап шуып китте. Гәүһәршад Кырым ханы Мөхәммәдгәрәйгә яза иде бу мәктүбен. Хатынның йөрәге тынычланып өлгергән, тормыш тарткалашларында ныгыган бәгыренең бер кылы да тибрәнми. Күп вәгъдәләр белән тулы юллар барып ирешәсе хакимнең кайчандыр беренче мәхәббәте булуын да исенә төшермәде диярлек. Шактый озын, каршылыклы гомер юлы яшьлек хатирәләренең төсен уңдырган, бары тик бер генә төс элеккечә үк якты булып тора, ул да булса – Гәрәйләр нәселен күралмау. Шуңа күрә Гәүһәршад ханлыктан урыска башы-бавыры белән хезмәт итүче адәмчекне кудыртыр өчен генә файдаланырга теләгәнен үзе белә иде. Аннары ул Казан тәхетенә бүтән – лаеклырак варис эзләп табар әле... Гәүһәршад шундый уйлар белән ерак киләчәкне юрый, ә кулы бүгенге мәшәкатьләрне барлый. Ул Кырым ханының йөрәгенә май булып ятарлык, ул тарафларда күптән көтелгән сүзләрне сырлый: «...Казан Иле үз тәхетендә Сезнең энекәшегез Сәхибгәрәй солтанны күрергә тели, Аллаһ аңа мәңгелек рәхмәтен яудырсын! Сезнең кан кардәшегез, бөркет булып, яугирләре белән ханлыкка бәреп керсен дә моннан урыс этләрен һәм аларның көчекләрен – Шаһгали малайханны куып җибәрсен! Алар, койрыкларын кысып, үз тарафларына йөгерсеннәр, ә Гәрәйләр нәселендәге бөркет Казанның бөек ханнары биләгән тәхеткә килеп кунсын!»

Гәүһәршад, хатындагы татлы телле бу вәгъдә-юлларны кабат укып чыкты да, албүлмәдә көтеп торган угланны чакырды. Анысы, керү белән, ханбикә каршында тез чүкте. Хатын үз мөһере сугылган һәм алтын җеп белән бәйләнгән төргәкне аңа сузды да коры гына сорап куйды:

– Хатны үзегез илтерсезме?

– Әйе, мөхтәрәмә ханбикә, – дип җаваплады Сәйед углан. – Әмирләр дә шул фикердә.

– Алайса, ашыгыгыз. – Гәүһәршад, ирнең ымсынулы карашын һәм еш-еш тирән сулыш алып торуын сизмәгән дә кебек, аңа аркасы белән борылды.

Бер углан гынамы икән никахыннан азат хан кызын үз җәмәгате итәргә теләгән! Әмма абыйсы Мөхәммәдәмин ханның инде әллә кайчан, Гәүһәршад мәңгелек тол булачак, ул җәзага тартылган ирен оныта алмый яши, дигән хәбәрне таратуы ук әле яшь хатынга авыз суын корытып йөргәннәрнең телен тешләргә мәҗбүр итте. Углан тагын бер кат баш иде дә ишеккә таба юнәлде, ә ханбикә җилкәсе аша гына аңа борылып карады. Нык бәдәнле, көчле, өстәвенә, яшерен эшләренең хәтәр җепләре белән бәйләнешкән бу ир Гәүһәршадның да дәртен кузгата һәм үзенә тарта иде. Әмма кияүгә чыгарга теләге булмады. Муенында йөгән тоясы килмәде. Теләсә – бүләкли, теләсә – җәзага тартырга, камчы белән суктырырга, хәтта кабер туфрагы итәргә булдыра ала. Йөрәгендә мәхәббәткә урын юк, ярату аны көчсез һәм гакылсыз итәргә мөмкин, ә ул корычтай нык ихтыярына һәм хәйләкәр акылына гына буйсынды.

Сәйед угланның албүлмәдән чыгып китүенә ышангач кына, Гәүһәршад, тирән сулыш алып, кәнәфигә җәелеп утырды. Маңгае киеренке уйга чумуын күрсәтеп җыерылды, ә аягы, түземсезләнеп, чуар келәмне тукылдата башлады. Соңгы айларда хәйлә белән эш йөртүгә ханлыкның күп кенә көчле ирләрен җәлеп итүгә иреште ул. Хәтта тәкәббер олы карачы Булатширин да Сәйед угланның кыстауларына биреште. Йосыф бәй ише, Мәскәүнең бөек кенәзенә тугрылыкта ант эчкән бер-ике адәмне генә үз якларына аудару мөмкин түгеллеге ачык иде. Әмма мәскәүлеләрнең яңа көч белән басымчаклык итә башлавына карата гади халыкта өлгереп килүче нәфрәт хисе олы карачы Булатширинның, аннары ханлыкта җир эшләре белән идарә итүче Йосыф бәйнең дә каршы торуын сындырды. Гәүһәршад үзалдына, чынлыкта бу эшләрнең артында кем торганын белсә иде Булатширин, дип көлемсерәде. Ул чакта, үтә масаеп йөрүен җиңеп, ханбикә белән ничә заманнар ярышуыннан туктый алыр идеме икән олы карачы?

Киеренке хәлдә утыра-утыра аркасы ойый башлаганын тоеп, ул киерелеп куйды, үзенең көзгедә чагылган төс-кыяфәтенә җәһәт кенә күз салып алды. Венеция осталарының иҗат җимеше булган зур көзге аңа үзе танырга теләмәгән ягын ачып салды: яшьлек инде артта калган икән шул. Нечкә бил дә юкка чыккан, чәч үремнәре дә куелыгын һәм яндырып торган төсен югалткан. Матурлыгы белән беркайчан аерылып тормаган хатын-кыз кояшы баер алдыннан күңелне тартып торырлык булмавын белми идемени соң! Шуңа да карамастан, ирләр, утка очкан күбәләк сыман, аңа тартылалар: берәүләрен – затлы нәселдән чыгышы, башкаларын – аңа бәйле булуы җәлеп итсә, калганнарын – ханбикә кулындагы күз күрмәгән, колак ишетмәгән байлык кызыктыра. Гүр иясе булган олы карачы Коләхмәдтән шактый мирас калды. Ә пайтәхеттәге, кайчандыр атасы төзеткән сарайны үлем түшәгендә яткан Мөхәммәдәмин хан аңа васыять итте. Хатын көзгедәге чагылышына карап көлемсерәп куйды. Теләсә, Казан ханлыгының иң күренекле аксөяге, чибәр ир-егетләреннән берсе – Булатширин аның ире була алмас идемени! Ул чакта матурлык нигә кирәк? Затлы нәселгә, хакимлеккә, кодрәткә һәм акылга ия хатынга өстәп тагылган мондый йөкнең нигә кирәге бар? Көзгедән күзен алып, ул, бу айларда ирешкәннәреннән иң мөһиме тормышка ашты: менә олы карачы да инде астыртын эшне хуплаучылар арасында, дип куанды. Хәзер инде чигенү юлы юк, аяусыз көрәштә җиңелү ихтималы булмаячак. Иң кирәкле мәлдә Шириннарның эчке гаскәренә, башка бәй һәм карачыларның яклавына таянып, Шаһгали ханның Василий җибәргән яугирләрен аяк астында таптар да, Кырымнан килүчеләр пайтәхеткә бер тоткарлыксыз керә алыр. Ул чакта инде Гәүһәршад күләгәдән чыгаргамы-юкмы икәнен үзе хәл итәр!

***

«Тәхет иле»[4]нең бөтен җирләренә хуҗа булырга хыялланган кырымлыларның Мәскәү белән Бакчасарай арасында күптән барган тарткалашлар уртасында калган ханлыкны кулдан ычкындырасы килми иде, әлбәттә. Кырымга, Казан тәхетен Сәхибгәрәй солтан алсын, дигән тәкъдим белән яшерен илчелек килүгә үк, Мөхәммәдгәрәй хаким энесенә өч йөз җайдактан торган гаскәр туплап бирде. Яз ахырында Сәхибгәрәй ханзадә Итил ярларында торган пайтәхеткә бер киртәсез барып керде.

«Гәүһәршад». Зөфәр Хәкимов рәсеме

Казан каласы шул көнне үк ярсып кайный-дулкынлана башлады. Һөҗүм буласын көтмәгән Шаһгали иярченнәре Касыйм казакларын чакырып китерергә дип йөгереште. Воевода Поджогин исә, бер файдасы да булмаячак урыс ратникларын җыярга маташып, ишегаллары буйлап чабачәбәләнә иде. Баш күтәрүчеләр ягына баскан Казан казаклары, төз сафлар рәвешендә, кырымлыларга ярдәм итәргә, дип, аларны каршы алырга чыкты. Кирмәндә, Хан сараеның ишегалдында һәм шәһәрнең тар җусык-урамнарында суеш башланды. Түнтәрелешләр вакытында гел булып торганча, урыс сәүдәгәрләренең кибетләрен таларга тотындылар. Халык кузгалышы көчәйгәннән-көчәя барды да бистәләргә һәм мәскәүлеләр тауарларын сакларга куйган кәрвансарайларга тикле ташып чыкты. Ханлык кешеләрен – аксөяген дә, ярлы-ябагаен да – уртак сөенеч, баскыннарны һәм кяферләрне җиңүдән әсәрләнү биләп алды...

Кичкә табарак бөтен дөнья тынып калды. Ниһаять, Казан сараенда Гәрәйләр куйган Сәхибгәрәй солтан пәйда булды. Кырым солтанының ханлыклар арасындагы иң бөегенә хаким буласы иртәгә үк хәбәр ителәсе иде. Бу кадәр җиңел җиңүгә ирешүеннән мәмнүн яңа хан бәреп төшерелгән Шаһгалине һәм баяр Карповны Мәскәүгә озатырга кушты. Воевода Поджогин, халыкның канын эчкән сәүдәгәрләр белән урыс илчелегендә торган дьяклар[5] зинданга ябылды.

Шулай итеп, әлеге түнтәрелеш дулкынында Казан тәхетен Кырым Гәрәйләре биләде.

Милади белән 1521 ел бара иде.

[4] «Тәхет иле» – элек Алтын Урданы шулай дип йөрткәннәр.
[5] Дьяклар – рус дәүләте хезмәткәрләре (тәрҗ. иск.).

Бөек Мәскәү кенәзлегенә шом-шөбһә кереп, аларга да югалтулар сәгате сукты. Василий, үзе куйган Шаһгалинең бәреп төшерелүен һәм казанлыларның аңа хыянәт иткәнен ишетү белән, гаскәр җыярга әмер бирде. Бу мәлдә Мәскәү патшасы ачудан шартларга җитеште, аны биләгән төп теләк – инде үзенеке дип санаган җирләрне кан белән катыштыру, юып «агарту» иде. Мәгәр бу ярсуның яшен ташын көнбатыштагы күршесенә атарга туры килде. Көтмәгәндә генә Литва белән ике арада яңа сугыш уты кабынып китте.

Бөек Литва кенәзлеге белән Мәскәү Русе инде дистә еллап тарткалаша иде. Ике кенәзлек тә Смоленск дигән бай каланы үзара бүлешә алмыйлар. Литвалыларның яңа һөҗүме 1521 елның җәенә туры килде. Мәскәү яугирләре Литвага каршы сугышырга дип киткәндә, Рязань җирләре аша Руська Кырым урдасы килеп җитте. Калалар һәм авыллар дөрләп яна башлады, башакка утыра башлаган басуларны, яңа гына чабылган печән кибәннәрен ут ялмап алды. Василий III татарларга каршы Старицкий кенәзнең бик кирәге чыкканда гына кузгатыла торган гаскәрен җибәрергә мәҗбүр булды. Русь, шомланып, куркып, яңа бәрелешләрнең ни белән төгәлләнәсен көтте.

Ә ул арада берләшкән Казан-Кырым явы Мәскәүгә килеп бара иде. Мөхәммәдгәрәй белән Сәхибгәрәй ханнар Воробьёв карьясендә инде җиңү тантанасын билгеләп үтәргә җыендылар. Ә Волоколамскида бөек кенәз Василий авыр сынау алдында торып калган иде. Дошман белән канга бата-чума көрәшергә һәм бөтенесен бер көндә югалтырга да мөмкин, әллә, бөек кенәз горурлыгын җиңеп, үз башыңны һәм Русьтагы хакимлегеңне саклап калыргамы? Мәскәү патшасы икенче юлны сайлады. Ул үзара сөйләшүләр башлауны сорады.

Мөхәммәдгәрәй хан бер генә нәрсәне: Мәскәүнең үзен Кырымга бәйле дәүләт – вассал итеп тануын һәм аңардан, урыс кенәзләренең йөз елларча Алтын Урдага буйсынганы кебек, ясак түләп торуын таләп итте. Василий белән бергә бөтен Русьны тезләндереп түбәнсеткән килешүгә шул көнне үк кул куелды. Солыхка ирешкәннән соң, Кырым һәм Казан ханнары үз җирләренә кайтып киттеләр. Бу бөек җиңү Гәрәйләр нәселенең, Бакчасарайда һәм Казанда гына түгел, бөтен мөселман дөньясындагы дәрәҗә-абруен күтәрде. Миңлегәрәй хаким улларының шулай бәхетле башланган язмышы, кайчан да булса, алар өчен көтелмәгән фаҗига белән төгәлләнер, дип, ул чакта кем уйлаган?!

Ә шуның артыннан ук тагын бер җиңү тантанасын кичерәсе җәй килде: Мөхәммәдгәрәй үз гаскәрен Хаҗитарханга таба юнәлтте. Кодрәтле хан кырымлыларны сугышка ашкындырып торган Итил ярларына үзе барып чыкты. Мәскәү җирләреннән алынган мул табыш ком сибелгән су кебек сеңеп өлгергән иде инде. Нихәл итмәк кирәк, яугирләрнең дә аяусыз яу чабуларда табылган байлыкны үзләштерергә һәм шуның белән гаиләләрен тукландырырга хакы бар. Хөсәен хан кырымлыларның басымына түзә алмады, шулай итеп, Хаҗитархан алар үкчәсе астында калды. Аксөякләрнең сарайлары, өйләре, базарлары һәм амбарлары таланды. Борынгыдан килгән гадәт буенча, яугирләр бу җиңүне берничә көн бәйрәм иттеләр.

Ул көннәрдә Казанда да яңа дулкын кузгалды. Урыс сәүдәгәрләренең кибетләрен талау янә башланып китте, ә арада кансызлыгы белән танылган мәскәүлеләрне һәм урыс илчесе Василий Поджогинны да, әсирлеккә алмыйча, Сәхибгәрәй хан әмере буенча, җәзалап үтерделәр. Монысы инде Мәскәүгә янә бер таш ату, башкаларга да сабак булсын, дип, тәкәллефсез ишарә ясау иде.

***

Бу көннәрдә Гәүһәршад ханбикә беркайчан да булмаганча шат күңелле иде. Казан җирләренең өскә калкып чыгуына сөенеп бетә алмады ул. Дәүләтнең элеккеге куәте торгызылды һәм Гәүһәршад, моңа тантана итеп, үзалдына сөйләнде:

– Кара әле, атам, хәзер Мәскәү Казаннан өркеп яши! Билгеле, моңа ирешүдә Гәрәйләрнең дә өлеше шактый зур булды, әмма аның җимешләрен безнең ханлык һәм аның халкы татый. Бер көн килер, Аллаһ кушып, Сәхибгәрәй дә Кырымына кайтып китәр, ә тәхеткә мин тавыш-тыны чыкмый торган берәр «курчак»ны утыртырмын. Бармагымны кайсы якка юнәлтсәм, ул шунда таба барыр. Олуг Мөхәммәд нәселе нигез салган бу илдә, затлы нәселнең иң соңгы буыны булып, мин идарә итәчәкмен!

Шулай итеп, хатын Казан белән горурланды, әмма күңеле Кырым ханының да хезмәтен таный иде. Мөхәммәдгәрәй аны кабат сокландырды. Ул Гәүһәршадның калган гомерендә хыял офыкларын яктыртачак, җылытып торачак чын хаким һәм яу батыры булып чыкты. Казанның яңа ханы Сәхибгәрәй исә вәлидә Нурсолтанга һәрвакыт хөрмәт белән карады, шуңа күрә аның кызын да зурлап яши иде. Мәскәү белән сугыштан ханбикәгә йөзләгән тотык-әсир һәм ике олау байлык алып кайттылар. Ибраһим хан белән Нурсолтанның дан-шөһрәт яратучы кызы бу уңыштан бик канәгать, әмма, Гәрәйләр бөек Олуг Мөхәммәд нәселенә лаеклы алмаш булыр, дигән уйны башыннан ук чыгарып ташлады ул. Менә Сәхибгәрәй урынында Мөхәммәдгәрәй үзе булып чыкса иде! Гәүһәршад, инде үзенең дә киселмәгән ефәк кебек яшь кыз түгеллеген онытып, хыялга бирелеп, күзләрен йомды: «И-и, Мөхәммәд, елларның калын катламы астыннан да умырзаядай калкып чыктың һәм йөрәгемне урыныннан кузгата алдың бит!»

Шулчак бөтен төшенә пычрак чәчрәгән атчабар буш сарайга көтмәгәндә генә атылып керде дә ханбикәнең аяк очына егылды. Ул кулындагы төргәкне сузгач, хатын тетрәнеп китте. Хат хаким Сәхибгәрәй исеменә язылган, әмма хан үзе бу сәгатьләрдә Кабан күле буенда аучылык итеп күңелен күтәрмештә иде. Гәүһәршад, ныклы кулы белән мөһерне сындырып, хатны ачты. Кәгазьдәге шәмәхә юллар күз алдыннан йөзеп, каралып китте. Кырым алпаутлары Мөхәммәдгәрәй ханның үлеме турында хәбәр иткәннәр иде. Күптән түгел генә Кырым хакиме ягында торып сугышкан Нугай морзабәкләре, Мөхәммәд артык көчәеп китте бугай, дип санаганнар. Мәсьәлә күз ачып йомганчы хәл ителгән. Кырым ханы, үзенең дан-дәрәҗәсе, куәте иң югары ноктага менеп җиткәндә генә, яу-сәфәр чатырында хаиннарча пычак кадап үтерелгән...

Яу башы калмагач, сугышчылар кире ярымутрауга таба чигенгәннәр, әмма күчмәннәр аларны куа килеп, бер ай элек хаҗитарханлыларны кырган кебек, барысын да юк иткәннәр. Шул рәвешле, Кырым ханлыгы ятим калган. Чәчәк атып утырган ил буйлап рәхимсез һәм комсыз кара өермә узган. Таланган Кырым олысы инде яңа хуҗаны – хакимиятнең җиргә төшкән дилбегәсен күтәрерлек нык куллы яклаучысын көтә икән.

Сәхибгәрәй хан, аудан кайткач, албүлмәсендә бикләнеп, үз янына беркемне дә кертмәде. Аксөякләр авыр сулап башларын чайкадылар, алар, Казан хакиме абыйсын югалтудан тирән кайгыга төшкәндер, дип уйлады. Ханның ялгызы гына калуының чын сәбәбен һичкем белми иде. Ә Миңлегәрәйнең улы бу мәлдә бары бернәрсә турында уйлый: Бакчасарай тәхете бушап калган. Ул үзенең туганнары арасында бу майлы калҗа өчен нинди талаш-җәнҗал кубасын алдан күреп тора. «Мөгаен, берсенберсе йоннарын туздырганчы йолыккалап бетерер, – дип, борчылып, гарьләнеп уйланды Сәхибгәрәй. – Алар, кем көчлерәк – шул җиңәр, дип уйлыйлардыр. Ахмаклар! Алар, кайсысы хәйләкәррәк, кайсысы Сөләйман солтанның күңеленә хуш килердәй,

– дилбегәне кулына шул эләктерәсен белмиләр. Бакчасарай тәхетенә Истанбул хакиме куйган кеше генә утырачак!» Сәхибгәрәй хан хәзерге вазгыятьтә, барысыннан да уздырып, Сөләйман Кануни солтанның аяк очына үзенең егыласы килгәнен әченнән генә дә таныырга курыкты. Госманлылар хакименә ошар өчен, ул таулар күчерергә һәм елгалар агышын кирегә борырга да риза булыр иде! Әмма бу турыда сөйләү түгел, хыялланырга да кыймады Сәхибгәрәй хан. Кырымның башка солтаннарыннан аермалы буларак, аңа шушы киң һәм бай ханлыктагы хакимиятне бүләк иткәненә рәхмәт укыйсы урында, күңеленә шундый канәгатьсезлек уен керткән өчен Ходай орыр, дип курыкты. Әмма шималь төрекләре илендә хакимлек итү ни өчендер Сәхибгәрәйне бер дә сөендерми, ул, Бакчасарай турында, хәзер бөек Сөләйман солтанның сараенда нинди хәлләр булып ята икән, дип, үҗәтләнеп уйлый-уйлый, маңгаен җыера, иреннәрен тешли.

Ә бу мәлдә төрек солтаны тәхете янында Сәгадәтгәрәй солтан басып тора һәм нәкъ менә аны госманлылар хакиме Кырым ханы дип игълан иткән иде. Әмма төрек солтаннарына күп еллар хезмәт иткән Сәгадәт үз туган җиренә курка-курка гына аяк басты. Бакчасарайда аны ызгышып-талашып беткән, тәмам явызланган туганнары арасындагы низаг, үз нәселләренә иң зур өстенлек алырга сусаган Кырым аксөякләренең бер-берсен чәйнәшүе көтә иде. Менә шул канәгатьсезлекләре тышка бәреп чыккан һәм үзара ачыктан-ачык дошманлашкан алпаутлар беренче көннәрдә үк, әйләнбәйләнкилеп, яңа хакимне уратып алдылар. Гәрәйләрнең күбесенә хас корыч ихтыяр һәм рәхимсезлеккә ия булмаган, йомшак-нечкә күңелле, нәзакәтле Сәгадәт хан бүгеннән үк төрле фиркаларнең кулында бер уенчык булырга мәҗбүр иде. Кырым чарпаланды. Диван утырышларындагы тарткалашлар һәм кырыс ызгышуларның иге-чиге булмый башлады. Кырым түрәләренең башлары, яңа яулап алулар турында бүтән уй кертмичә, ни булган биләмәләрен, байлыкларын саклау кайгысы белән генә тулган иде. Нык куллы, яу чабуга һәвәс Мөхәммәдгәрәй заманнары үткәндә калды һәм Мәскәү патшасы, ярымутраудан яу белән бүтән килмәсләрен белеп, тынычланды. Кырым ханлыгындагы хәлләр Казанда да котылгысыз һәм кырыс үзгәрешләр буласына ишарә иде бит. Куәтле, гүзәл һәм киң колачлы ил үзен туракларга әзерләнгән тегермән ташларына таба тәгәри. Әмма Казан ханлыгының үзендә әле моны бик азлар гына аңлый...

Бусагадан 1524 ел кереп килә иде.

Редакциядән:

Хөрмәтле укучыларыбыз! 2019 елның 2 нче санынннан башлап трилогиянең өченче китабы – «Сөембикә» романы белән таныша алырсыз. Һәрвакыттагыча, сезнең фикер-тәкъдимнәрегезне көтеп калабыз.

Урысчадан ***Мөдәррис Вәлиев*** *тәрҗемәсе* ■

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИНЕҢ ТУУЫНА 160 ЕЛ

Р.Фәхреддиннең бу әсәре – авторның берничә дини эчтәлектәге китабыннан соң, 1897 елда басылып чыккан тәүге тарихи һәм биографик хезмәт. Соңрак галимнең биобиблиографик «Асар» исемле китаплары бер-бер артлы дөньяга тарала башлый. «Сәгыйдь» әсәре ярдәмендә мөхтәрәм укучыларыбыз хәзерге Оренбург өлкәсендәге Татар Каргалысы (Сәгыйдь бистәсе) авылы халкының, андагы зыялылар, сәүдәгәр һәм имамнарның Россия империясенең төрле төбәкләре белән икътисади, рухи-мәдәни бәйләнештә торганын аңлар. Китап бер гасырдан артык вакыт игътибардан читтә калып, бүгенге заман укучылары хозурына беренче мәртәбә тәкъдим ителә. Аның күчерелмәсен редакциябезгә юллаганы өчен Әлмәт районының Кичүчат авылындагы Р.Фәхреддин мемориаль музее җитәкчесе ***Диләрә Гыймранова****га олуг рәхмәтебезне һәм чиксез ихтирамыбызны белдерәбез.*

Редакция

Сәгыйдь[1]

Ризаэддин Фәхреддин

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим

Сәгыйдь бистәсе Русия дәүләтендә мәшһүр булган Оренбург вилаятендә. Оренбург шәһәренең төньяк тарафыннан якынча егерме чакрым ераклыкта. Казакъ, башкорт, төрек халкы бергә яшәгән бу мәмләкәт мөселманнарының милли шигырьләрендә искә алынган Сакмар елгасы, Сәгыйдьнең көньягыннан кичеп, Оренбургта Җаек елгасына кушыла. Сакмар елгасы көчле агуы вә ләззәтлеге илә танылган. Бар халыктан бигрәк мөселманнарны тәрбия әйләмәктә вә туйдырмактадыр. Ата-бабаларыбыз вә

Оренбург губернасы картасыннан фрагмент. 1802 ел

[1] Текст хәзерге әдәби телгә якынайтылып бирелә. Җәя эчендәге ел хисабын үзебез билгеләдек. — *Ред.*

хөрмәтле остазларыбыз ошбу Сәгыйдьтә булган газиз мәшаихлар *(ишаннар)* хозурында тәрбия ителгәннәре кеби, бу көндә дә йөзләгән шәкерт андагы мәдрәсәләрдә уку илә мәшгуль. Ошбу көндә сигез меңнән артык җан хисабы булып, барчасы да мөселманнар. Халкы исә иҗтиһадлы, кәсеп һәм сәүдә хозурында дикъкать вә игътибарлы, тәкъва, диндар, мосафирпәрвәр, мөравәтле вә вафа *(сүздә тору)* илә башкалардан өстен булу белән данлыклы. Хәер-иганәләре илә мәшһүр булган сәүдәгәрләр вә сәүдәгә катыш күп кешеләр ошбу Сәгыйдьтә яши. Таштан бина ителгән олуг бер базары булып, бөек сәүдәсе бар. Зиратында газиз галимнәр вә мөхтәрәм укымышлылар, вә танылган шәехләр җирләнгәнлектән, зиярәт кылу нияте илә һәрвакытта тирә-яктан һәртөрле халыклар килә. Гадәттән тыш төзек вә нык булган таш җәмигъ мәчетләр Сәгыйдьне аерым бер зиннәт белән күрсәтеп, мәхбүбәләр[2] буйларына охшашлы манаралары ерак җирләрдән күренеп, мосафир вә сәяхәтчеләрнең күңелләрен әсир итеп торыр. Бу көндә тугыз җәмигъ мәчете булып, күбесендә голүм гарәбия укыр өчен махсус олуг мәдрәсәләр бар. Вә ибтидаи мәктәпләре аерым булып, җиде, сигез, тугыз, ун яшьләрендә булган ир балалар монда белем алалар, иман, ислам вә язу өйрәнәләр. Күпчелек мөгаллимнәренә хезмәт хаклары хаҗи Габделгани бай кесәсеннән түләнә. Рус телен укыту өчен бик яхшы бер мәктәп төзү фикере сәгыйдьлеләр арасында тәмам урнашып җиткән. Боларның ният иткән фикерләре бервакытта да юлда калмаганлыктан, тиз заманда мондый мәктәпнең барлыкка киләчәгендә шөбһәбез юктыр. Моннан башка иман, ислам, игътикад, хөсне хат, әхлак, бала тәрбияләү, һөнәр, сәнгать гыйлемнәрен укыту өчен махсус кызлар мәктәбе төзеләчәк ки, мондый мөһим вә кирәк мәктәпне ачуда беренчелек бәхете Сәгыйдь халкына хас булачактыр. Бу көннең кыз балалары киләчәк көннең мөхтәрәм аналары булачагыннан, боларның мәктәпләре вә тәрбияләре өчен җан бәрабәрендә булган малларны сарыф кылу вә мөмкин кадәр ярдәм вә иганә итү – беренче мәртәбә кирәкле эштер. Кыз балаларны яхшы тәрбия итеп укыткан халыкларның беренче дәрәҗәдә бәхетле хәлдә булганнары мәгълүм. Иншаллаһ, Сәгыйдь халкы бу хакта камил фикер итәр вә бу морадларын мөкәммәл сурәттә гамәлгә ашырыр, дигән нияттә калабыз.

Сәгыйдьнең төзелү тарихы

Сәгыйдь бистәсе миляди илә 1745 елда **Сәгыйдь бине Ает Хыялин** исемле кеше тарафыннан төзелгән. Сәгыйдь баба Казан мозафатындагы *(губернасы)* Саба[3] исемле авылдан бер сәүдәгәр, сүзе үтә торган һәм дәрәҗәле кеше булган. Моны төзү өчен императрица Язавета бинте Бәтрас[4] тарафыннан 1744 елны март аеның 13 нче көнендә рөхсәт бирелгән. Сәгыйдь баба илә бергә Сенбер, Казан, Касыйм, Кирмән, Вятка, Самар тарафларыннан шактый кешеләр дә бу бистәгә күченгәннәр. Сәгыйдь баба, беренче ташханәсен бина итеп, бистәгә Сәгыйдь дип үзенең исемен биргән. Шуннан бу мөбарәк сүз халык арасында һәм дәүләт эшендә рәсми исем булып файдаланыла башлый.

Сәгыйдь бабаның үтенеченә күрә, иператрица Язавета тарафыннан ошбу әмерләр бирелгән: 1) Сәгыйдь һәм аның угланнарына ошбу урында җир бирү хакында рөхсәт. Ул Казан тарафыннан 200 йорт мөселманны чакырып урнаштыру хосусында ихтыярлы. 2) Игенлек вә печәнлек, хайван йөрердәй кыр вә болыннар вә йортка кирәк булган урыннар, Сакмар суында булган балыклар, Сакмар урманында булган агачлар, Каргалы суына кадәр булган урманнар – барчасы боларга милек булып файда-

[2] Мәхбүбә – сөелгән, яратылган хатын. – *Ред.*
[3] Саба – Мамадыш шәһәренә ерак түгел урында бер авыл. Байлар Сабасы дип тә танылган. Мөхәммәд бине Афман бине Илкәй исемле кеше тарафыннан нигез салынган.
[4] Императрица Елизавета Петровна. – *Ред.*


«سعيد»

اورينبورغ شهرينه تابع اولان «سعيد» ننك جامع وامامارينى
تعريف ايدن رسالەدر .

اثر
رضاء الدين

طبع مصارفندن قالان حاصل وربحى مذكور سعيديەدە اولان «مكتب اناث»
فائدەسينه تبرع وهديه ايدلنه چكدر .

بوكتابننك باصمه سنه رخصت بيرلدى سانكت پيتربورغده
۳۰ نچى ايونده ۱۸۹۷ نچى يلده

چيستايده ابراهيم الكمالى كتبخانه سى
БИБЛІОТЕКА И. З. КАМАЛОВА ВЪ ЧИСТОПОЛѢ

Дозвол. цензур. С. Петербургъ. 30 Іюня 1897 г.
Типографія Б. Л. Домбровскаго, въ Казани.

Р.Фәхреддиннең «Сәгыйдь» китабы. 1897 ел

ланулары хакында рөхсәт. Бу урында тегермән, завод бина итүдә дә чикләү юк; 3) Һөнәр вә сәнәгатьтә маһир вә остазларны кайсы мәмләкәттән булса да үз араларына чакырырга мөмкин.

Сәгыйдь бабаның таш бинасы авылның тәмам урталыгында булып, 1314 елның шәвәлендә *(1897, март)* без булган вакытта харап хәлдә иде, ләкин, ишетүебезгә караганда, ахун Исхак бине Мәхмүднең дәлиле һәм кызыктыруы илә Мәхмүд бине Гали әл-Хөсәени акчасына гүзәл итеп яңартылган һәм ныклап төзекләндерелгән.

Кайбер мәшһүр кешеләре

1) **Исмәгыйль бине Бикмөхәммәд**. Бу кеше 1751 елда беркадәр юлдашлары илә чит мәмләкәтләрдә сәяхәт иткән. Бу турыда бер сәяхәтнамә язган. Гәрчә бу сәфәрендә Бохара, Һәрат, Кандаһар, Килат, Бәсра, Хәйдәрабад, Бинарис[5] кеби олуг шәһәрләрдә булса да, язган сәяхәтнамәсеннән файда вә тиешле дәрәҗәдә гыйбрәт нәрсәләр аңлашылмый. Җәгърафия *(география)*, һәйәт *(астрономия)*, һәндәсә *(геометрия)*,

[5] Р.Фәхреддин «Асар» исемле хезмәтендә Исмәгыйль бине Бикмөхәммәднең бу сәфәре вакытында Ягъкуб, Габдеррахман, Надир исемле иптәшләре белән Мәккә, Мәдинә, Шам, Коддес, Истанбул кебек зур шәһәрләр аркылы да узуы турында яза. – *Ред.*

хисап гыйлемнәрен белмәгән кешеләрнең сәяхәтләреннән файдалану мөмкин түгел, аларның сәяхәтнамәләре «Әлфе ләйлә» хикәяләре рәвешендә файдасыз булуы мәгълүм. Исмәгыйль әфәнденең бу гыйлемнәрдән мәгълүматы булмаган кеби, гарәп вә фарсы телләреннән дә белеме юк. Шуңа күрә аның алда искә алынган шәһәрләрдә танылган галимнәр вә мәшһүр әдипләр илә сөйләшү-аралашулары булмаган. Хәлбуки, бу гасырда Хәйдарабад, Һәрат, Кандаһар шәһәрләрендә олуг галимнәр булганы тарих гыйлеменә мәгълүм.

2) **Котлыгмөхәммәд бине Тәвәккел бине Мәмеш бине Дәүләт Мөхәммәд бине Уразмөхәммәдҗан**. Ерак бабасы Уразмөхәммәд, Кирмәндә хан булып, 1119 (1707) елда вафат булган. 1147 (1734) елда Котлыгмөхәммәд Оренбург шәһәрен бина иткән вакытта күп вә олуг хезмәтләр күрсәткән. 1169 (1755) елда сәламәт иде. Әмма хатыны Хәдичәбикә 1165 (1751) елда вафат булып, Сәгыйдь кәберстанына җирләнгән. Каберендә гүзәл рәвештә язылган ташы вә нык итеп корылган ихатасы бар.

3) **Әбелмәних бине Әбелфәез бине Габдессәлам.** Бу кеше 1231 (1815) елда Мөхәммәд Йосыф исемле илчегә юлдаш булып, Истанбул шәһәренә барган вә аннан Хиҗаз тарафына сәфәр итеп, Мәккә, Мәдинә шәһәрләрен зиярәт кылган. Кырык яшендә вакытында, икенче мәртәбә хаҗ кылу нияте илә ватаны булган Сәгыйдьтән аерылган, ләкин, ошбу сәфәрендә әҗәле ирешеп, вафат булган. Кайсы елда вафат булуы[6] вә кайсы шәһәрдә җирләнгәне безгә мәгълүм булмады. Шагыйрь вә әдип кеше иде. Моннан башка янына килеп-китеп йөргән укымышлылар да күп булган.

ҖӘМИГЪ МӘЧЕТ ВӘ ИМАМНАРЫ

Беренче мәчет

1159 (1745) елда Сәгыйдь бистәсе төзелгән заманда Сәгыйдькә бирелгән урман агачларыннан салынган. Моны исә Сәгыйдь баба акчасы илә төзегәннәр. Бу изге бина харап булганнан соң, ярарлык әсбапларын җыю шарты илә Сәгыйдьнең варисларыннан алып, 1195 (1781) елда **Әбүбәкер бине Габделмөэмин** яңадан таш мәчет төзетә. 1275 (1858) елда **Гатаулла бине Мөхәррәм,** мең сум акча сарыф итеп, бу мәчетнең бинасын киңәйтә.

Мәдрәсәсе. Бу мәчет хозурында булган мәдрәсәләрне хаҗи **Мөхәммәдбакый бине Салих** төзеткән иде, ләкин 1882 елда бу биналар янып әрәм булды. Соңрак **Мәхмүд бине Гали әл-Хөсәени** илә **Рәхмәтулла бине Мөхәррәм** гүзәл вә хуш шәкелдә таш мәдрәсәләр бина итте.

Беренче имам **Габдессәлам бине Уразмөхәммәд (Орави) бине Колмөхәммәд бине Колчура**. Асылы Казан мозафаты Алат юлындагы Мәңгәр исемле авылдан. 1159 (1746) елда Казан янындагы Ташкичү авылында дәрес илә мәшгуль булганы мәгълүм. Бу мәчет хозурында имам вә ахун һәм мөдәррис булган. Мәшһүр шагыйрь Әбелмәних бине Әбелфәйз бу затның оныгы була. Сәгыйдь баба илә ошбу Габдессәлам ахунның вафат булу еллары мәгълүм түгел.

Икенче имам – моның углы **Габделлатыйф бине Габдессәлам**. Гүзәл дәрес биргәне риваять ителә. 1194 (1780) елда вафат.

Өченче имам – **Габдессәлам бине Колмөхәммәд бине Чупаш бине Апач бине Акман бине Аккөчек**. Әбүбәкер бине Габделмөэминнең кызын никах итеп, кияве булды. 1258 (1842) елда вафат.

Дүртенче имам – **Габдерәхман бине Мөхәммәдшәриф әл-Кирмәни**. Касыйм та-

---

[6] Р.Фәхреддин «Асар» китабында «1240/1825 елда вафат булган», дип яза. – *Ред.*

Каргалының 1 нче мәхәллә мәчете

рафындагы Җаубаш исемле авылдан. Исхак бине Габделкәрим, Габдерәшид бине Габделкәрим, Мөхәммәд бине Гали әд-Дагыстани (казый Ака ахун) хозурларында укып, заманасында булган мөдәррисләрнең бик атаклысыдыр. 1242 елда (1826) 83 яшендә вафат булды.

Бишенче имам – моның углы **Гатаулла бине Габдерәхман**. 1259 (1843) елда вафат.

Алтынчы имам – **Хәсән бине Мостафа бине Хушкилде.** 1269 (1852) елда вафат.

Җиденче имам – **Хәйрулла бине Гатаулла бине Габдерәхман**. Габдулла бине Яхъя әл-Мәчкәрәви хозурында укыган. 1300 (1882) елда хаҗ сәфәрендә Мәдинә шәһәрендә вафат.

Сигезенче имам – **Исхак бине Мәхмүд бине Исмәгыйль**. Ахун һәм мөдәррис булып, мәдрәсәсендә күп имамнар җитешкән.

Тугызынчы имам – **Гыйниятулла бине Хәйрулла бине Гатаулла**. Аз гомер итеп, 1310 елда (1892) хаҗ сәфәрендә Мәккәи мөкәрәмәдә вафат.

Унынчы имам – **Хәйрулла бине Габдерәхман**. Фатих бине Гайнетдин, Мөхлисулла бине Максуд хозурында укып, Гыйниятулла бине Хәйрулла вафаты соңында имам вә мөдәррис булган. Хезмәте булыр, дип өмет ителгән яшь голәмәбездер. Бу җыентыкны бастырып чыгару өчен акча җыйганда олуг иганәте булды.

Икенче мәчет

Яшел мәчет исеме белән танылган. Эче чуар кирпеч илә зиннәтләнеп, гаять нык итеп бина ителгән. Кайбер вакытта булган төзекләндерү-яңартуларны исәпкә алмаганда, бу мәчет бина ителгән хәленчә тора. Моны 1217 (1802) елда **Габидулла бине Мөхәммәдрәхим бине Заһид** исемле кеше төзетте. Янында булган таш мәдрәсәсе дә – ошбу затның тырышлыгы. Сәгыйдь базарында булган таш кибетләр дә ошбу заһидинең акчасына төзелгән. Мәчете исә гүзәл вә күпләрне кызыктырырлык рәвештә бина ителгән.

Беренче имам **Сәйфулла** исемле кеше. Аның турында мәгълүматыбыз юк.

Икенче имам – **Үзбәк бине Сөбханкол бине Мостафа**. Бабалары Сембер моза-

Каргалының 2 нче мәхәллә мәчете

фаты Шәйморза исемле авылдан булып, бирегә Сәгыйдь баба илә бер вакытта күчеп килгән. 18 ел дәвамында имамлык итү, дәрес укыту илә мәшгуль булып, 1236 (1820) елда вафат булган.

Өченче имам – моның углы **Госман бине Үзбәк**. 1241 (1825) елда вафат.

Дүртенче имам – моның карендәше **Гатаулла бине Үзбәк**. Мәчкәрәдә ахун Мөхәммәдрәхим бине Йосыф хозурында укыган. Рәсме хатта остазлыгы илә мәшһүр. 1248 (1832) елда вафат.

Бишенче имам – моның карендәшенең углы **Габдессәлам бине Госман бине Үзбәк**. Мәчкәрәдә Габдулла бине Яхъя хозурында укыган. Гыйльме кыйраәттә сәләте илә шөһрәте таралган. 1281 (1864) елда вафат.

Алтынчы имам – **Габделкәрим бине Габдерәфигъ**. Бу кеше ахун булып, иҗтиһад вә зур тырышлык илә укыган. Казанда Габделгаффар (Габди) хәзрәттә, Габденнасыйр бине Рәхманколыйда, Чистайда Исхак бине Сәгыйдьтә тәрбияләнгән. 1302 (1884) елда вафат.

Җиденче имам – **Нуретдин бине Ногман**. Мәчкәрәдә Габдулла бине Яхъя вә Казанда Байморад бине Мөхәррәмнән гыйлем алып, 1298 (1880) елда вафат булган.

Сигезенче имам – **Габдулла бине Габделкәрим ахун**. Атасы хезмәттән азат ителгәннән соң, 1287 (1870) елда имам булды.

Тугызынчы имам – **Садыйк бине Мөхәммәд бине Госман**. 1303 (1885) елда имам булды. Остазлары Исмәгыйль бине Муса әл-Кышкарый, Рәхмәтулла бине Хәлилрәхман.

Ахыры киләсе санда

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Мәчет фотолары ТР Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана торган «Юбилей ядкәре» (Казан, матб. «Кәримия», 1911 ел) исемле китаптан алынды.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2019

Читада Яңа ел каршы алу

У.Сүләҗи



Сүләҗи У. Читада Яңа ел каршы алу. – Уфа, 1916. – 26б.

Чита шәһәрендәге татар мәхәлләсе турында Габдерәшит Ибраһим «Ислам дөньясы» исемле хезмәтендә тәфсилләп яза. Шуннан бер өзек китерәбез: «Бик мөлаем карт. Аның белән күрешергә өенә баргач, миңа: «Безгә бирегә бер йөз ел элегрәк килергә кирәк булган. Патшалык игълан итәргә дә көчебез җиткән булыр иде», – диде». XX йөз башында Читада татар бистәсе, каторжаннарның тырышлыгы белән 1907 елда төзелгән мәчет, аның астында иллеләп балага белем бирә торган мәктәп булган. Кызыксынган укучыларыбыз тулы текстны ***beznenmiras.ru*** *сайтыннан яки журналыбызның 2018 елгы 10 нчы (октябрь) саныннан укый ала.*

Редакциядән

Чита шәһәренең татар зыялылары һәм балалары

Яңа ел бәйрәме хакында тәртип ителгән парчаларны рисалә шәкелендә нәшер итәргә ният иттегеңезне аңладым. Мәктәп вә мәдрәсә файдасында тырышуыңыз өчен тәшәккеремне гарыз итәм. Минем сөйләгән сүзләремнең нәшер ителүеннән файда булуына күңелем җитмәсә дә, берсе – үзем тәхсил иттегем *(укыган)*, икенчесе үзем мөгаллимлек иттегем гыйлемханәләре файдасына улдыгыннан, нәшеренә мәгалмәмнүния648 *(шатланып)* рөхсәт итәм.

Ихтирам илә, мөгаллим ***Вәсим Солтанов.***

1334 нче ел керүгә 15 көн *(1916 елның октябрь аена туры килә. – Ред.)* микъдары калдыкта мөгаллим әфәнде Чита могтәбәрләре белән Яңа елны каршылау тугрысында мөзакәрә итте *(киңәште)*. Вакыт аз калган булса да, бәйрәм итәргә карар бирелде. Мәктәп балаларын бәйрәм өчен хәзерләп мәшәкатьләмичә, дәрес арасында гына укыган шигырьләрен декламировать иттерергә булды. Ахунд хәзрәт тиешле урыннан рөхсәт алды. Фәкать ул көннәрне авырып киткәннән, мәгънәви идарәне мөгаллим әфәндегә тапшырды. Бу бәйрәм, бердән, Читада беренче мәртәбә булганга, икенчедән, башка җирләргә дә үрнәк булыр өмиде белән нәшергә карар бирелде.

Нашир: ***М.Әһлетдинов.***

ЯҢА ЕЛ КАРШЫ АЛУНЫҢ ПРОГРАММАСЫ

Беренче бүлек

1. Коръән укып, падишаһ хәзрәтләренә һәм гаскәремезнең җиңүенә дога.

2. Шәкертләр тарафыннан «Бәйрәм бүген» шигыре хор белән әйтелер.

3. Яңа ел тугрысында бер-ике сүз. Тарихыбызның башы булган һиҗрәтен-нәби тугрысында һәм Яңа елны бәйрәм итәргә һәр мөселманга тиешлеге тугрысында сөйләнер.

4. «Авыл». С.Рәмиев шигыре. Укый – Мәкъбулә Мөхибуллина.

5. «Киңәш». Г.Тукаев шигыре. Укый – Камилә Нәҗметдинова.

6. «Көзге җилләр». Г.Тукаев шигыре. Бәян Әһлетдинова.

7. «Тәңре Тәгали». Фазыйлә Арсланова.

8. «Җәй көне». Сәгъдетдин Сираҗетдинов.

Ярты сәгать тәнәфес. (Бу тәнәфестә шәкертләргә чәй эчерелер).

Икенче бүлек

1. «Эш». Г.Тукаев. Озын көйгә әйтеш. Мөхибуллина.

2. «Яңа елдан теләгем». Сөйләү. Мөгаллим Вәсим Солтанов.

3. «Яңа елдан ни телисез?» (Һәркемнең әүвәлдән таратылган кәгазьләргә язылган җаваплары укылыр. Язмый сөйләгән кешеләргә рөхсәт ителер.)

4. «Теләнче». Г.Тукаев. Укый – Фагилә Сираҗетдинова.

5. «Ятим бала». Н.Думави. Укый – Исхак Мөхибуллин.

6. «Теләнче». З.Ярмәки. Укый – Нәсибулла Сабитов.

7. «Туган тел». Г.Тукаев. Укый – Әбелкәрим Сәгыйдов.

8. «Бу кай чак була?» Г.Тукаев. Укый – Саимә Һидаятуллина.

9. «Ике угыл». Халык әкияте. Укый – Тәлгать Мөхибуллин.

10. «Мәхәббәт». Г.Т. Озын көйгә әйтә – Мәкъбулә Мөхибуллина.

11. «Балаларга». Хор белән укылыр.

Тәнәфес (ярты сәгать).

Өченче бүлек

1. «Туган авыл». Г.Тукаев. Сәфәрбикә Макиева.
2. «Гыйффәт туташ хатирәсе». Гыйффәт. Зифа Солтанова.
3. Яңа ел каршы алу мәрасиме.
4. Яңа ел һәм иске ел тугрысында шигырь.
5. «Бәйрәм котлы булсын». Фагилә Сираҗетдинова.

Сәгать беренче, котлашу.

***

Мәктәп бүлмәләре яшь ханым вә туташлар тарафыннан һәртөрле флаг вә чәчкәләр белән зиннәтләнгән, хисапсыз күп шәм вә лампалар белән яктыртылган иде. Мәктәпнең зур бүлмәсенә кечкенә генә сәхнә дә хәзерләнгән. Кечкенәрәк ягында бер тарафта зур өстәл татлылар вә тәгам *(ашамлык)* әсбабы белән тутырылган, стенада чәчкәләр арасында «Буфет» дигән сүз күренеп тора. Икенче тарафта зур-зур ашъяулык белән капланган берничә өстәл һәм урындыклар да куелган. Ханым вә туташлар вә яшүсмерләр һәркаюсы билгеләнгән хезмәтенә сызганып торалар.

Сәгать 7дән башлап мәктәпкә халык агыла башлады. Мәктәпнең өске каты – мәсҗедтә көненә мөнасиб *(туры китереп)* матурланган, яктыртылган иде. Зур җәмәгать белән ястү намазы әда ителде *(укылды)*. Сәгать сигез булганда инде мәктәпнең һәр ике бүлмәсендә карт, яшь, олуг, кечек ир вә хатын – кыскасы, аягына баса башлаган баладан алып карт вә карчыкларга кадәр тулган иде. Кавказлы кардәшләремез дә шактый күп килгәннәр. Һәркемдә – шатлык, һәркемдә – хушнудлык *(сөенеч)*, һәркайсының кайгы вә хәсрәтләре вакытлы булса да онытылган; бар да көлә, бар да елмая. Һәр кеше бүгенге көннең хиссияте вә киләчәк елгы өчен изге өмидләр белән капланган. Кайсы сөйли, кайсы тыңлый, кайсылары чәй эчә вә кәеф коралар. Бу чуар халык төркеме шатлык белән сугарылган. Һәммәсе Яңа ел өчен изге теләктә иштирак иткәннәр.

Менә мәктәп сәгате, яңгыратып, 8не сукты. Звонок һәммә халыкны кузгатты. Дөберди, шатырдый... 10 минут кадәр бервакытта һәммә кеше урынлы урынына утырдылар. Тынлык...

Кәләме Шәриф укылды. Падишаһ хәзрәтләренә дога кылынды. «Ура!!!» вә «Мәрхаба!» *(Хуш килдегез!)* тавышлары мәктәпне яңгыратты. Соңра сәхнә ачылды. Кечкенә калфаклы, кара кәләпүшле, һәркайсы бәйрәм киемендә матур итеп тезелгән мәктәп балалары күренде. Тагын тынлык. Алар мәгъсуманә *(саф, эчкерсез)* тавышлары белән Габдулла Тукайның «Бәйрәм бүген» шигырен моңлы вә матур көй белән әйттеләр. Халык озак алкышлады.

Соңра мөгаллим әфәнде тарихыбызның мәбдәэ *(башлангычы)* булган һиҗрәтеннәби *(Мөхәммәд с.г.в. – Ред.)* хакында тәфсилле итеп сөйләде. Хәзрәти Рәсүлгә пәйгамбәрлек килгәннән алып, Мәккәдә булган вакыйгалары, күргән җәфалары вә һиҗрәте бик тәэсирле чыктылар. Мәдинә шәһәрендә Рәсүл гамне каршы алдырып, Әюп ән-Нәсари хәзрәтләре ханәсенә илтеп төшерде.

Башка милләтләрдә, мәсәлән, христиан, яһүд вә юнаннарда тарихны нинди вакыйгадан игътибар иттекләрене, гадәттә мәбдәэ *(башлангыч)* тарих итеп бер әһәмиятле вакыйганың алынуы һәм һиҗрәтен-нәбинең әһле ислам өчен зур әһәмиятен бәян итте вә Яңа елның бәйрәм ителергә тиеш идеген күп дәлилләр белән аңлатты. Кавказлы кардәшләремез дә булдыгыннан, Гашура бәйрәме тугрысында да бераз тукталды. Гашура бәйрәме өммәвиләр тарафыннан чыгарылган уйдырма бәйрәм, аны бәйрәм итәргә тиешле түгел, бәлки әфәндемез саллалаһу галәйһи вәссәламнең күз нуры *(яраткан оныгы хәзрәти Хөсәен ибне Әбү Талиб. – Ред.)* разый Аллаһу ганһуның дошманнар тарафыннан шаһит ителдекләре көн булганга, матәм тотарга тиеш идегене төшендерде.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2019

Кызның кулында «1334 нче ел» (миладине – 1916 ел) дигән язу

Мөгаллим әфәнде сүзен тәмам иттегеннән соңра, программада күрсәтелгәнчә, шигырьләр укылды. Тәнәфес вакытында шәкертләргә чәй вә татлы тәкъдим ителде. Буфет та яхшы гына сәүдә итеп алды. Теләгән кешеләргә номерлап «Яңа елдан ни телисез?» дигән сөаль язылып хәзерләнгән кәгазьләр таратылды. Бу кәгазьләргә һәркем үз теләген язып, махсус өстәлгә куйдылар.

***

Икенче бүлектә «Эш» шигыре җырлангач, мөгаллим әфәнде сүз башлады:

– Сөекле кардәшләр! Программа буенча әүвәл мин сөйләргә тиеш булсам да, сезнең язуларыңызны укырга вә сезнең киләчәк елдагы теләкләреңезне тизрәк белергә күңелем ашкынганга һәм сезгә дә төрле кеше фикерләрен тыңлау кызыклырак төсле булганга, әүвәл мин сезнең язуларыңызны укымакчы булдым. Соңра, вакыт калса, мин дә үз тарафымнан берничә сүз кушармын.

Беренче номер: *«1334 нче елның чын Яңа ел булуын телим»*. Касыйм Мөхибуллин.

Номер 2: *«Бөтен дөньяны шаулаткан сугышның безнең файдага тәмам булуын телим»*. Гөлчәһрә Нурмөхәммәдова.

3 нче: *«1333 нче ел безнең хатын-кыз галәменә яңа бернәрсә дә бирмәде, күп ха-*

Безнең мирас №1 гыйнвар 2019

Кызның кулында «Яңа ел котлы булсын!» дигән язу

тыннарыбыз фәкыйрь вә ятимлектә калдылар. Кием-калпак тугрысында сөйләү, мактанышу һәм уздырышу бераз азайса да, һаман бетеп бетмәде. Хатын-кыз уку-укыту тугрысында һаман да баш үтми. Гимназияләрдә беркадәр туташларыбыз булса да, алардан өмид иткән эшләребез күзгә күренерме, юкмы? Мәгълүм түгел. Укыганнарыбызның да гомум эшләргә тотына алырлык куәтләре юк. Бу елда һәр хатын башына әллә никадәр ятим бала калды. Ләкин ул ятимнәрне аталары юклыгын сиздермәслек дәрәҗәдә тәрбияләрлек гайрәтле вә һөнәрле хатыннарыбыз да юк. Хатын-кызларымызның хокукларын язып аңлатырлык мөхәррирәләребез юк. 33 нче елда Гыйффәт туташ кеби шагыйрәбез күренсә дә, ул да әле үзенең кайгы-хәсрәтен генә җырлый. Шулай да аның зоһуры өмидле. «Сөембикә» журналыбыз һаман тукталмый килде. Ун миллионлык Русия мөселман хатыннарына бу юк дәрәҗәсендә аз. Анда да сынар өчен генә маташкан яшь егетләр ояладылар. Алар урынын һаман да үзебез тутыра алмыйбыз. 1333 нче ел безгә Троицки шәһәрендә бер дарелмөгаллимат (хатын-кыз укытучылар әзерли торган уку йорты. – Ред.) бирде. Буңа шатланырга, хәтта кабилиятьле туташларымызны җибәреп укытырга тырышырга ярый. Инде Яңа ел хатын-кызлардагы кимчелекләрне бетерсен иде. Шәригать хөкемнәрендә Ходай Тәгалә бертигез күргән, дөнья низамнарында да без ирләр белән бертигез яшәрлек һәм үз хакыбызны аңларлык гыйлем, һөнәр вә гайрәт бирсен иде. Мин шуны телим».

4: *«Киләсе 1334 нче елга кадәр мөселманнарга үзләре теләгән бер яхшы мөфти куелуын телим»*. Закир.

5: *«Кыз вә хатыннарыбызның алга китүләрен телим»*. Әсма Нәҗметдинова.

6: *«Исламиятнең алга китүен телим»*. Гани Мөхетдинов. *«Мин дә Гани әфәнденең теләгенә кушылам»*. Хәсән.

7: *«Сугышның Безнең файдабызга бетүен телим»*. Әсгадулла.

8: *«Илләргә тынычлык, барча мөэмин вә мөселманга сәгадәт һәм барчамыз туган кеби тату тормакны телим»*. Гыйлаҗетдин Сираҗетдинов.

9: *«Дин исламның алга баруын, бу тугрыда тырышуны яшь милләтебездән көтәм»*. Кәлимулла Бикмөхәммәдев.

10: *«Икенче елларны шатлык белән каршыларга»*.

11: *«Икенче елга Яңа елны шулай ук встречать итәргә»*. Сәлахетдин. *«Ходай Тәбарәк вә Тәгалә хәерле гомер биреп, киләсе елны шатлык белән күрергә»*. Хафиз Мөхәммәтҗан улы.

12: *«Бу елда бөтен галәме исламның алга омтылуларын теләвем илә бәрабәр, Чита мөселманнарының ошбу көнге кеби булган җыелышларының бу ел да күбрәк булуын һәм тәртип белән үтүләрен телим»*. Хәсәнҗан Нәҗметдинов.

13: *«Сугышның үзебез теләгәнчә бетүен телим»*. Нургали.

14: *«Дин тугрысында барчаларымыз ихласымыз белән тырышып, бергәләп киңәш илә вә җәмагатьләребез белән изге эшләрдә йөрергә насыйп әйләсен»*. Гыйльметдин Төхфәтулла улы.

15: *«Хатын-кызлардагы өшкерү-төкерү, әби һәм күрәзәләргә ышануның бетүен, гыйлем вә мәгърифәт нуры белән нурлана башлавыбызны телим»*. Шәмсеҗиһан.

16: *«Иске елда булган һәммә иске вә караңгы тормышның бетүен, яңа вә якты тормышка аяк басуымызны телим. Ягъни надан вә җаһиллек дәрьясыннан чыгып, башка милләтләр кеби гыйлем вә һөнәрләремезнең артуын һәм алар кеби дөньяда шат вә күңелле булып, алар кеби үк һәммә хокукка вә нишаннарга малик булып, гыйлем вә һөнәрләрдә аларга исемез китми, бәлки үземез үрнәк булып дөньяда, җирдә чын инсан булып, инсаният,* «адәмлек» *исемемезнең зур дәрәҗәгә менүен телим. Иске вә начар фикерләремездән кайтып, ягъни бер-беремезгә һич тә начар вә яман фикердә булмаенча, бәлки һәрвакытта бер-беремезгә ярдәм итешүемезне телим»*. Габидулла Төхфәтуллин.

17: *«Мөселманнарның һөнәр вә сәүдә җәһәтеннән алга китүләрен телим»*. Әкрәм Нәҗметдинов.

18: *«Яңа елда Читада яшьләр тарафыннан, хосусан Мәүлед бәйрәмендә театр ясалуны телим»*. Нурулла Нурмөхәммәдев.

– Хөрмәтле кардәшләр! Сезнең теләкләр – һәммәсе урынлы, һәммәсе гүзәл вә милли теләкләр. Һәммәңезнең шундый гүзәл теләкләрдә булуыңызга гаять тә шатланам һәм Аллаһы Тәгалә хәзрәтләреннән шул гүзәл теләкләреңезне 34 нче елда алдыңызга китереп, һәммәңезне шатландыруын телим. Яңа ел сәгате сугуга тагын бөтен ике сәгать вакыт калды. Шул аз вакыт эчендә мин дә Яңа елда нинди теләкләрем барын әйтеп үтәргә телим. Шулай да, Яңа елдан теләкләрне санамас элек, иске елдагы теләкләрне бераз искә төшереп китәргә кирәк төсле күренә. Чөнки иске ел бервакыт яңа иде. Анда да бер генә шәһәр тугрысында түгел, бәлки бөтен Русия әһле исламы тугрысында.

Кардәшләр! Гомумән бер милләтнең теләге, бер җөмлә белән генә әйттегендә, алга атлау, башка милләтләрдән кысылмау, йотылмаудыр. Мәгълүмеңез, башка милләтләрдән йотылмау һәм бер милләт булып яши алу, икътисади байлыкка һәм гыйлме һөнәргә туктый. «Вакыт» газетасының 176 нчы номерында, бәлки укыгансыздыр: *«Русиядәге һәммә*

мөселман газеталарының иң беренче әсасый максатлары, һич шөбһәсез, мөселманнарны мәдәният вә мәгарифкә өндәүдән гыйбарәттер. Алар барысы да мөселманнарның үзләре аңлаган тел илә язып, алар арасында мәгариф вә мәдәният зыясыны төшерергә, алар арасында иҗтимагый вә икътисади хәят уяндырырга...» – диелмештер. Әлбәттә, газеталарның теләге – милләт теләге дигән сүз. Бу кадәрле сүзләрдән сөзеп алганда гына шул икътисади байлык, гыйлем вә һөнәр килеп чыгадыр. Димәк, **милләтнең теләге – байлык, гыйлем, һөнәр булырга тиеш.** Кайсы гына милләттә шул өч таяныч булдымы – ул милләт аумас, ул милләтнең киләчәге яктыдыр, ул милләтнең еллар белән түгел, бәлки көннәр, сәгатьләр белән алга баруына һич шөбһә итәргә ярамый. Уздырып бардыгымыз иске елның башында да бу тәрәккыйнең мәдаре *(нигезе)* булган өч нәрсәне без теләгәнбездер. Ләкин иске ел бу хаклы уларак эстәдегемезгә *(теләгәнебезгә)* җитештеме? Без әүвәл шуңа җавап бирергә тиешлебез. Ләкин, кардәшләр, тәәссефкә *(кызганычка)* каршы, аз-маз гына алга омтылуларны уйламаганда, бу сөальгә бик озын итеп кенә, юк, дип җавап бирәсе килә. Бер Русия мөселманнарының шул ахыргы сәгатьләрен кичермәктә улдыгымыз елда күпме һөнәри артты, күпме гыйльми артты һәм бездә күпме байлык бар! Бу көндә чиксез табигый байлыкка малик булган Русия мәмләкәтендә һәр җирдә мәйдан ачык, һәр җирдә теләгән эшне тәмам муаффәкыять белән башларга мөмкин. Башларга, дим, чөнки без башлагач та хисапсыз файдалар өмид итәбез, әгәр булмаса, кул селтибез. Берничә еллардан соң килеп үземезгә, булмаса әхфадемезгә *(оныкларыбызга)* файдасы тиярдәй эшләргә катышырга батырчылык итә алмыйбыз. Мөселманнар тарафыннан бер-бер ширкәт ясалдыгы, яхуд *(яки)* фабрика вә завод, яхуд башка шундый файдалы, күбрәк көч тели вә күбрәк файда китерә торган эшләр башлаганлык ишетелдеме? Бардыр, бөтенләй юк, дип кырт өзүе кыенрак вә әһле исламның сан җәһәтеннән күплегенә караганда, бик аз, бик сирәктер.

Аз-маз дәвам итеп яткан ашханәләр, әһәмиятле урыннар бездә дә әҗнәбиләр *(читләр)* кулында. Бер яхшы конторщик кына кирәк булса да, башка милләтләрдән эзләргә тугры килә. Сез үзеңезнең өй эченә бер дикъкать белән күз йөртеп чыгыңыз! Күрерсез ки, мәгыйшәт өчен зарур булган нәрсәләр һәммәсе читләр тарафыннан эшләнгән. Түбәтәй, калфак булмаса, мөселманнар кулы белән эшләнгән күпме генә нәрсә табарсыз икән?! Димәк, мөселманнар үзләренә кирәк нәрсәләрне үзләре җитештерә алмыйлар. Фәкать алар акча бирәләр. Кардәшләр, бик яхшы беләсез, акча бервакытта да күктән яумый. Мөселман, бер арзанлы йорт кирәгене алыр өчен, сызганып, кара тирләрне агызып күкрәгән имгәтә-имгәтә бер караңгыдан бер караңгыга эшләргә мәҗбүр. Димәк, Русия мөселманнарында кара көч – тупас эштән башка һөнәр юк. Беләсез, һөнәр белән байлык бертуган инде, һөнәр булмагач, табигый, байлык та бар, дип булмый. Бинаән галәйһи *(шулай булгач)*, без икътисади байлык вә һөнәр тугрысында катып калган ноктадан бу иске елда бик күп кузгала алмаганбыз. Хәлбуки, мәгыйшәт елдан-ел агырая *(авырая)*, елдан-ел гыйлем, һөнәрнең кирәклеге ныграк сизелә бара, бездә һөнәр азлыгы күрсәтә ки, гыйлем дә аз икән. Чөнки гыйлем белән һөнәр дә бер-берсенә бик нык бәйләнгәннәр.

Мәдрәсәләребезнең хәзерге хәлләре бик аяныч, милли мәктәпләр көннән-көн ябыгалар. Садака белән генә туенып торган кешенең киләчәге никадәр тәэмин кылынганын үзеңез дә беләсез инде. Мәктәпләремезнең киләчәге бик төпсез. Хәлбуки, иң мөкатдәм *(башта)* шул милли мәктәпләремезне аякка бастырырга кирәк иде. Менә инде һаман да милли мәктәпләремез шул какшаган, ыңгырашкан, сүрәнләнгән хәлдә 34 нче елга керәләр. Школаларымызда миллият җәһәте бик ачыга. Безнең Читадагы русско-татарский школа тибындагылар хәзерге заманча милләтебезнең теләгенә өлешчә генә җавап бирә, ләкин ул типтагы мәктәпләр бик аз җирдә генә

Читада 1907 елда төзелгән мәчет

ачылды. Русиядә земски школалар күбәя. Анда белемсез муллалар аена 5 сум акчаны алыр өчен генә дин өйрәтүче булып торалар. Аларның күбесе аена бер кереп тә чыкмый. Тырыша торганнары да иртәнге сәгатьләр арасына керә алмыйлар. Дин дәресен әһәмиятле урынга куя алмыйлар, татар теле дәресе бөтенләй юк. Мәдрәсәләр хәлен әйтмим дә инде. Әнә шул 5 сумга талаша торган муллалар шул мәдрәсә җимешләре инде. Хөкүмәт мәдрәсәләре ачык булса, анда да кереп укучыларыбыз бик аз. Анда да шул татарлыкның затына сеңгән түземсезлек хөкем сөрә. Бер-ике ел дәвам итәләр дә телеграмм укырлык, кул куярлык белгәч, җитәр безгә, дип кул селтиләр. **Туганнан алып рус мәктәпләрендә укыган укучыларымызның миллият җәһәте кысрык чыга.**

Мөгаллимнәр эше күптән рәтсез. Аларга һаман әллә ничек мөгаллимлек исеме тагыла да, шуның белән – син күр дә, мин күр – йөри бирәләр. Икътидары *(сәләте)* бармы, юкмы – бер Аллаһыга гына мәгълүм. Милләт алтын кеби балаларын мөгаллимнәргә тапшыра. Балаларның киләчәк өчен файдалы йә зарарлы гонсыр *(элемент)* булып җитешүләре мөгаллимнәрдән зависеть итә.

Язучыларыбызның хәле артмады. Кода-кодагыйлык белән язучы исемен тага язган бер груһ *(төркем)* матбугатның йомшаграк урыннарына оялап алып, имзалары белән чиле-пешле читек кунычы тәме килә торган мәкаләләрне тарата башладылар. Тукайдан аерылдык! Аның урынына да 33 нче ел бераз мөнәҗәтчеләрдән башка бер рәтле шагыйрь багышлый алмады. Бу иске елда бераз хатын-кыз каләме күренсә дә, җитди язучылар арасында саналырлык кеше күренмәде. Һаман без шул иләктән чиләккә бушатудан артмыйбыз. Мөгаллимлек исеме белән бер такым туташларыбыз мәйданга атыла башладылар. Ләкин алар да мөгаллимләребез кеби аяныч туалар, кызганыч көн итәләр. Аларга да бер эш, бер терәк күрсәтелми. Троицки шәһәрендәге дарелмөгаллимат иске елларның зур бүләгеннән санала.

Кардәшләр! Ярты сәгатьтән Яңа ел керә һәм иске ел бер дә килмәскә саубуллаша, китә. Шуның өчен мин дә Яңа елдан теләгемне бер-ике сүз белән әйтеп калырга ашыгам. Шуңа кадәр сездән бер-ике генә нәрсә сорыйм:

1. Музыкалар, художестволардан, театрлардан лаф орды да, инде килеп, барысын Коръәнгә, дингә бәйләде, дип мине осуждать итмәңез, безнең дини җәһәтебез эзгә төшсә, һәммә төеннәребез чишеләчәк.

2. Бик озак сөйләде, ялыктырды, дип кәефеңез китмәсен. Сез бик ихлас тыңлаганга, мин күпме сөйләгәнемне дә белмәдем. Хакыйкать, гүзәл тыңладыңыз. **Сүз сөйли белү ирлек түгел, тыңлый белү – ирлек,** диләр. Һәм Чыңгызның сүзе дип хәтеремдә калган, егет кеше шул булыр, ди, бер сүзне инде йөз кат ишеткән, хәзер йөз дә беренче мәртәбә ишетә икән, һич ишетмәгән кеше кеби тыңлар, ди.

Яңа елда калебләремез яктырсын, терелсен вә Коръән кушканча чын мөэмин вә мөселман булсак иде!

***

Программадагы шәкертләр укыдылар, балаларга дигән шигырь халыкны җанландырды. Тәнәфес булды, чәй эчелде. Һәркем ишеткән сүзләрне, алган хиссиятләре тугрысында сөйли. Звоноктан соңра тагын халык урыннарына утырды. Сәгать 12 сукты, сәхнә ачылды. Бик ямьсез ак сакаллы карт чыкты. Кызыл белән 1333 дип язылган. Кылыч вә мылтык, вә пушка рәсемнәре куелган. Мөгаллим әфәнденең иске вә яңа елга дигән шигыренең әүвәлге хор кыйсеме укылды:

Иске елда җир йөзе кан берлә капланды тәмам,
Кан агызмый өйдә яту ирләргә булды хәрам.
Ул ятимнәр зарлы аһы күкләргә чыга һаман.
И, Яңа ел, хуш, сафа кил, каршыларбыз, мәрхәбә!
Әйтче, иске ел, ни бирдең ошбу татар халкына?
Күпме безләр алга киттек, әйтче, Аллаһ хакына?
Күпме дошманлык сеңеште бу татарлык затына.
И, Яңа ел, хуш, сафа кил, каршыларбыз, мәрхәбә!

Иске ел югалды, артыннан Яңа ел булып бер кыз чыкты. Рәсемнәрдә күрсәтелгәнчә, аңа шигырь укылды:

Үтте иске ел, хәзер килде Яңа ел безләрә;
Зур бәшарәтләр бу көндә ир, хатын вә кызлара;
Яңа тормыш, изге тормыш нуры чыксын йөзләрә,
Әй, Яңа ел, мәрхәбә, хуш, саф килдең, мәрхәбә!
И, Яңа ел, зур теләк синнән безне юлга төшер,
Барча дошманлык вә явызлыкны син бездән бетер.
Ал наданлык чирен һәм безне инсафка китер.
Әй, Яңа ел, мәрхәбә, хуш сафа килдең, мәрхәбә.
Хак Тәгалә безне чыннан хәер өмет әйләсен.
Әһле ислам милләткә һәм дингә хезмәт әйләсен.
Әй, Яңа ел, мәрхәбә, хуш, саф килдең, мәрхәбә.

Соңра, «Бәйрәм котлы булсын» шигыре укылгач, пәрдә төште, озак алкышладылар. Халык бер-берсен Яңа ел белән тәбрик итә. Кичәдән алган тирән хиссияте эчендә акрын-акрын тарала башлый.

(Саф файданың 25%ы – Чита мәктәп ибтидаи файдасына, 50%ы Уфа мәдрәсәи Галия файдасына бирелер.)

Текстны басмага ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

«Тамашачы» журналы

«Сәнгать – хезмәт халкына!» 1927-1930 елларда Казанда, Татар дәүләт академия театрының басма органы булып, айга бер мәртәбә чыккан «Тамашачы» журналының (1928 елга кадәр «Татар дәүләт академия театры мәҗмуга-программасы») шигаре менә шулай дип атала. Журнал азагында күрсәтелгән редколлегиядән басманың



«Тамашачы» журналы. Фотода «Наемщик» спектакленнән беренче пәрдәдәге күренеш. 1929 ел, №3 (8)

Мирза Зәетов, Гомәр Гали, Шамил Усманов, Гадел Кутуй, Х.Кәримов кебек драматург һәм язучылар катнашында дөнья күргәне аңлашыла. Журналның эчтәлеге исә абунәчеләргә мөрәҗәгать буларак язылган текстта тәфсилле бәян ителгән: *«Тамашачы»ның һәр санында театр өлкәсендә нәүбәттә торган бурычлар турында мәкаләләр булачак. «Тамашачы» журналында театр, сәнгать белән бәйләнгән теоретик мәсьәләләргә зур урын биреләчәк. «Тамашачы» журналы Татар дәүләт академия театрының һәм башка урыннардагы татар театралларының эшләрен тулы һәм даими рәвештә яктыртып барачак. «Тамашачы» журналы хәзерге урыс театраллары һәм башка милли җөмһүриятләрнең театрлары турында үз укучыларына мәгълүмат биреп барачак. «Тамашачы» урыннардагы сәхнә һәм клуб хезмәтчеләренә даими ярдәмче булып барачак. «Тамашачы»да кино турында яңалыклар яктыртылачак».*

Болардан тыш, журнал битләреннән Ш.Камалның «Ут», Т.Гыйззәтнең «Наемщик», К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» һәм «Сүнгән йолдызлар», М.Фәйзинең «Галиябану», Р.Яхинның «Әрмән кызы», Ә.Сәгыйтьнең «Сәхрә кызы», Г.Кутуйның «Күк күгәрчен», Б.Лаврентьевның «Разлом» кебек пьесаларына һәм спектакльләренә язылган бәяләмәләрне дә укырга мөмкин.

Һәр сан саен диярлек Татар дәүләт аккадемия театрында куела торган әсәрләрнең программасы басылган. Мәсәлән, журнал сәхифәләреннән Ш.Ганиевнең «Сүнмәс йолдызлар» драмасы, С.Сүнчәләйнең «Гыйсъян», З.Солтанов тәрҗемәсендә «Рельсәләр гөрләгәндә» пьесасы, Ә.Хәмиди тәрҗемәсендә «Ике ятимә» драмасы, К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», М.Илдарның Заһир Бигиев әсәре нигезендә иҗат ителгән «Олуг гөнаһлар» драмасы, Һ.Такташның «Югалган матурлык» әсәрләре сәхнәләштерелгәнен беләбез. Программада рольләрне башкаручы артистларның да исемнәре аталган. Журналның һәр санында диярлек театр әһелләренең фотопортретлары, спектакльләрдән күренешләр басылган.

Игътибарыгызга күренекле композитор Солтан Габәши (1891-1942) белән язучы Гадел Кутуйның (1903-1945) хәзерге заман укучыларына билгеле булмаган мәкаләләрен тәкъдим итәбез. Алар ярдәмендә «Тамашачы»ның идея-максатларын һәм эчтәлеген күзалларга мөмкин.

ҖЫРЧЫЛАР РЕПЕРТУАРЫ ТУРЫНДА БЕР-ИКЕ СҮЗ

«Кызыл Татарстан» гәзитенең 57 нче санында этнография концерты турысында язганда Г.Кутуй: «Көйләрне үзләренең җырлары белән үтәргә кирәк», – ди.

Этнография концертында җырларның көйләр белән бәйләнешсезрәк булып чыгулары концертның оештырылу ягыннан булган бер кимчелеге (концерт көненә кадәр җырчылар белән бер репетиция дә ясалмау) аркасында гына килеп чыккан бер хәл булуын әйтеп узганнан соң, бу сүз һәм бу мәсьәләләргә бераз тукталып, ул хакта бер кадәрле фикер йөртергә тиешле күрдем.

Минемчә, Кутуйның бу сүзе, бер концертка гына карата узгынчы бер сүз кыяфәтендә генә әйтелмичә, бөтен башка концертлар турында да әйтелергә тиешле бер сүз.

Һәркемгә мәгълүм ки, татар җырларының һичберсе (бәетләр һәм кайбер җырларның кушымталарыннан башкалары) үзенә генә хас булган һичбер көй белән бәйләнмәгән һәм, киресенчә, һичбер халык көе үзенә генә махсус булган бертөрле сүзләр-җырлар белән бәйләнмәгән була. Шунлыктан, теләсә нинди халык җырын теләсә нинди халык көенә салып җырларга мөмкин. Хәтта бик кыска гына үлчәүдә булган такмакларны да «Һай, дай, дагна...» дигән төсле берничә иҗек өстәгәндә бик озын, бик моңлы халык көйләренә туры китереп җырлап була.

Менә шул хәлдән файдаланып, җырчыларыбыз күп вакытны җыр белән көйнең



1930 елда «Тамашачы» латин графикасында басылган

эчке бәйләнешләренә, мәгънәви һәм рухани элемтәләренә һич игътибар итми. Теләсә нинди җырны теләсә нинди бер көйгә салып җырлый бирәләр һәм шуның аркасында җырлаучыны, җырдан алынырга тиешле булган тойгылар урынына, үле бер аңлашылмау алырга яки җыр белән көй-музыканың икесен килештерә алмый җан чыгып, баш катырып, актыгында ачу килү хәлендә калырга мәҗбүр итәләр.

Бу хәл бигрәк тә иске халык көйләренә яңа революционный җырлар җырлый башлаганда зур урын тота. Хәзерге көндә заманның һәм әхвәлнең теләве буенча, җырчыларда яңа сүзләр, яңа революционный җырлар җырлыйсы килү дәрте бик көчле урын тота. Ләкин, заманга муафыйк, заманча язылган җырларны җырлау өчен җитәрлек кадәрле яңа көйләр чыгарып торырга җитәрлек композиторларыбыз булмаганлыктан, булган кадәрлесе дә алларына алган аерым эшләре белән мәшгуль булганлыктан, андый яңа җырларның рухларына муафыйк рәвештә ясалган яңа көйләр ишелеп агып тормыйлар. Ә яңа җыр җырларга кирәк. Җырчылар нишләсен?! Билгеле инде: алар яңа җырлар арасыннан борынгы көйләрнең кайсына булса да туры килерлек бер җыр эзләргә тотыналар һәм тапсалар, җырның эчтәлеге белән көенең рухы арасындагы бәйләнеш турысында уйлап та тормый, тоталар да аны шул көй белән җырлый башлыйлар. Шуның аркасында җыр-музыка галәмендә кызык хәлләр хасил була.

Бервакытны мине, уку йортларыннан беренә, нииндидер бер кичә булу мөнәсәбәте

белән, хор оештырып бирергә чакырдылар. Барсам, сүз дә, көй дә табып куйганнар. Анда кайгы-хәсрәт, төшенкелек көенә капиталны ватабыз, яңа тормыш төзибез, дигән шатлыклы сүзләр хәзерләгәннәр.

Җырның эчтәлеге белән рухланырга тотынсак – көе каршы төшә, көе-музыкасы белән моңланырга-ләззәтләнергә тотынсак – сүзе ирек бирми. Шунлыктан, актыгында икесеннән дә ваз кичеп, мөмкин булса, җырчының тавышы ишетелмәслек икенче бер җиргә чыгып качарга мәҗбүр буласың.

Бу турыда таякның бер очы яшь шагыйрьләребез – заман шагыйрьләренең иңсәсенә төшкәнлеген дә әйтеп китми хәл юк. Чөнки бу көнгә кадәрле татар матбугат һәм әдәбият галәмендә халык көйләренә карата җыйналган яңа җырлар мәҗмугалары булмаган шикелле, шагыйрьләребезнең әсәр һәм мәҗмугаларында да берәр халык көенә карата язылган һичбер җыр һәм шигырь юк. Алар язган вакытында шигырьләренең музыка белән бәйләнеп җырланып үтәлүе турысында уйлап та карамыйлар булса кирәк һәм, шул сәбәпле, аларның әсәрләре арасында нинди дә булса бер көйнең музыкаль рухын, хисси эчтәлеген төшенеп, шул көй белән җырлар өчен көйнең рухына туры килгән эчтәлектә язылган шигырьләр, юк кына түгел, бәлки гомумән әйберләренең арасында музыка белән бәйләнеп оеша алырлык нәрсәләр очрамый. Чөнки аларның әсәрләренең күбрәгендә музыканың төп кагыйдәләреннән булган «мәтер»нең *(маэстро)* теләве буенча җырлана торган сүзләрдә табылырга тиеш булган симметриягә игътибар ителмәгән була.

Бу юлда икенче һәм тагын да нигезле, тагын да тирәнрәк төпле мәсьәләләр булып яңа язылган яңа революционный җырлар өчен иске татар халык көйләренең гомумән яраклы булу-булмау мәсьәләсе тора.

Әлеге мәкаләсендә Кутуй: «Сибелә чәчәк» көендә кайдадыр килеп кергән сары сакал, сары мыек юк», – ди. Шулай ук «Сибелә чәчәк»тә (һәм башка көйләрдә дә) интернациональ дә юк! Ягъни, аларның эчке рухлары – музыкалы мәгънәләре интернациональ һәм шул рухтагы җырларны тыңлаучыга бирә торган гайрәт кузгалыш, сугыш, алга омтылыш мәгънәсенә туры килми һәм аны бирә алмыйлар. Чөнки алар (көйләр) «мескин булып торган өч йөз ел» дәверендә чыккан көйләр булганлыктан, аларның берсенең дә настроение рухларында шатлык, гайрәт, алга атлау һәм сугыш шикелле нәрсәләр юк, исләре дә аңкымый. Менә бу мәсьәлә, минемчә, ансат кына җавап бирү мөмкин булмаган күп уйлану, күп тикшерену һәм фикер алышуларны сорый торган нигезле, тирән мәсьәләләрнең берсе булганлыктан, аны халыкның дикъкатенә җиткерәбез.

Инде көй сайлау мәсьәләсенә килсәк, монда талымсызлык тагын да ныграк хөкем сөрә. Җырчыларның бик күбесе үзенең тавышына, рухына, үскән средасына һәм көченә карап көй сайлый белми. Кайда, кемнән берәр матурраак көй ишетсә, шуны отып алып ярты-йорты иттереп булса да җырлый бирә. Ләкин көченнән, кулыннан килмәгәнгә күрә, аның үтәве нәфасәт *(гүзәллек)* урынына нәфасәтне җимерә генә, тыңлаучыларның саруын кайнатырга сәбәпче була.

Бу көй сайлаудагы уйсызлык һәм талымсызлык бара торгач шундый бер тәртипсезлек, бер мантыйксызлыкка барып җитә ки, ахырында хатын җырчы – ир булып, ир җырчы хатын булып җырларга тотыналар. Мәсәлән, сакаллы һәм ир тавышлы бер җегет чыгып баса да: «Челтерәп аккан чишмәләрдән көянтәләп су алдым...» – дип җырлый башлый. Шул хәлне күргәч, җырчының җырын тыңлап зәвыкланырга хәзерләнгән тыңлаучыларның башыннан иң элек: «Бу мескен соң ни эшләп көянтәләп су ташып йөрде икән?» – дигән сорау килә. Аннан соң инде көянтәчиләк күтәреп бөгелә-сыгыла, борыла-сырыла бара торган егет күз алдына килә баш-

лый да, татарларның «... җиңе» дигән мәкале искә төшеп, йә бик каты көләсе килә башлый, йә булмаса, җырчының физиология ягыннан нормаль кеше булмавы күз алдына килә дә, җирәнә башлыйсың.

Соңгы елларда, атна саен дигәндәй, тамашачылар алдында концертлар, атнага 2-3 тапкыр радио аша концерт тапшырулар булып торганлыктан, бу күзгә күренеп торган җитешсезлекләрне бетерү юлына керешергә бик вакыт, дип уйлыйм һәм шуңа күрә аларга җырчыларның дикъкатьләрен җәлеп итәм.

Солтан Габәши

(«Тамашачы». – 1929. – №5(10). – Б.6-7, 10).

ҖЫР, МУЗЫКА КОЧАГЫНДА

Яңа совет авылы татарның канатланып үсеп барган җыр, музыкасын чын иҗатчылар аркылы тыңлый алганы юк әле. Дөрес, бу мәйданда «Татарстан» радиосы күп хезмәт күрсәтте, клуб-читальняларга халыкны җәлеп итте, радиояңгыраткычлар тирәсенә авыл яшьләрен җыйды. Ләкин авыл радиога мәхәббәт баглау белән генә канәгатьләнми, радиода ишеткән җырчы-музыкантларны үз күзе белән күз алдында күрәсе килә. Шул турыда хатлар яза... Мөрәҗәгать итә. Шәһәргә килеп чыкса, студиягә дә керә... Фамилияләрне дә хәтерли... «Фәлән-фәләнне тыңладык, кая ул?» Исендә калган фамилияләрнең хуҗасын күрсә, шатлана...

– Авылдан сәлам! – ди.

Ул күп үзгәргән. Күгеш авылына (хәзер Яшел Үзән районына карый. – *Ред.*) гына карагыз... Авылга керү белән үк радио антенналарын күрәсез... Монысы изба-читальня...

– Әнә анда тагын бер зур матур йорт бар, анысы нәрсә?

– Анысы – мәктәбебез!

Мәктәбе чиста, нәфис, керсәң, чыгасың килми... Бүлмәләр киң һәм биек итеп эшләнгәннәр... Сәламәтлек өчен бу бик файдалы...

Крәстиән хәзер укудан качмый... Киресенчә, уку вакыты җиткәч тә баласын тизрәк мәктәпкә урнаштырып каласы килә. Урын җитмәсә, талаша: «Ничек кенә булса да, укытасы килә. Укысын», – ди. Клуб-читальнялар да мактаулы урын алып киләләр. Китап-журналлар кулдан-кулга йөри. Берәр егетне яки кызны эзләп, кая гына китте икән соң бу, дисәң: «Улмы? Ул клубта – читальняда!» – диләр.

Спектакль, кичә-фәлән булса, урын җитми...

– Клуб стеналары киңәюне сорыйлар. Әнә – Норлат (хәзер Яшел Үзән районына керә, 1961 нче елга кадәр район үзәге була. – *Ред.*). Аны кечкенә генә бер шәһәргә охшатып була. Ике ятажлы мәктәп аны тагы да матурлый. Мәктәпкә керсәк, онытыласың... «Мин кайда соң? Авылдамы, шәһәрдәме?» – дигән сорауны куярга мәҗбүр буласың.

Әнә шундый авыллар белән танышасы, шуны башкаларга сөйлисе килә.

Менә шул ният белән татар пролетариат язучылары һәм татарның танылган җырчы артистлары февраль ахырларын, март башларын кантонда, авылларда йөреп уздырдылар. Татар дәүләт академия театры артистларыннан Вәлиев Сөлүһ, Касыйм Шамил, Хисамов, Камалиева, Закирова, Урмансова һәм тагын берничә иптәш Арча кантонының Күлле-Киме волостена барып, анда «Сүнгән йолдызлар»ны куеп һәм әдәбият кичәсе ясап кайттылар.

Асия Измайлова, Мәхмүд Бөдәйле, Шамил Госманов, гармунчы Сафиуллин һәм тагын берничә иптәш Норлат районында концерт-кичәләр уздырдылар.

Ике-өч көн эчендә Норлатның үзендә – 3, Күгештә 2 концерт ясалып, шуларга берничә йөз кеше җәлеп ителде. Авыл музыканың тәмен белә, авыл яшьләре, авыл комсомоллары спектакль, кичәләр ясап, аны тамашачы карау хәленә китергән, беле-

мен үстергән*. Бер көн эчендә бер авылда өч концерт бирү совет авылының кая таба, ничек һәм нинди юллар белән барганын, үскәнлеген күрсәтсә кирәк.

Бер сәгатьтән соң клубта концерт була, дисәң, шәһәрдәгечә көттереп тормыйлар, ярты сәгать эчендә килеп, клуб халык белән тула.

Уйлап тору юк, кызы да, егете дә, яше дә, карты да килә. Тыңлый, кул чаба. Измайлова алкышлар белән күмелә, җырла, тагын җырла... Күпме җырласаң да, туймыйбыз, һаман тыңларбыз, диләр.

Бөдәйли көлдерә... Әйдә, сөйлә, тагын сөйлә, җитмәде, диләр. Күгештә дә шул ук хәл.

Безгә авылларда берничә көн торырга туры килде. Кунарга кайткачтын да тирәли уратып алалар:

– Сөйләп җибәр әле, – диләр.

Сөйлисең, шәһәр тормышы белән таныштырасың... Төнге ике булуга карамастан, йотлыгып-йотлыгып тыңлыйлар. Китап укуны сорыйлар. Шигырь, хикәя укыйсың...

Авыл тыныч яши. Шәһәрнең кайбер иске-поскы, калдык халкы, гайбәт чәйнәп йөрүдән башканы белмәгәннәре, авыл тегеләй, авыл болай, дип, авылны сүгәләр... Авылның бөтен белгәне дә – икәмәктә аның, диләр...

Ялганлыйсыз, мөхтәрәм әфәнделәр!

Авылның хәзер йөрәк төбендә бер генә сорау бар, ул да: «Менә ничек агарасы иде?» Авыл мәдәният сорый һәм шул турыда гына сөйли дә. Иҗатчылар баргач, бу сораулар тагы да кыздылар.

Менә – Арча. Монда кантонның 8 нче съезды бара. Клуб халык белән тулган. Урын җитми, академия артистларыннан Ситдыйк Айдаров, Бакиров, Камалова, Кушловская, Хисамов, Зверьев иптәшләр концерт бирәләр. Карап, тыңлап калырга урын җитми... Җырланмаган җырлар җырлана.

Фәлән Фәләновлар, диюгә, алар колак тондырырлык алкышлар белән каршы алыналар. Бу концетлардан алган тәэссоратны тулы иттереп язсаң, берничә табаклы китап чыгарырга кирәк булыр иде. Журналыбыз аны сыйдырмый.

Монда бары шуны гына әйтәсе килә.

Бу концертлар беренчесе һәм соңгысы булып кына калмаслар. Аларны тагы да оештырырга кирәк:

– Авыл шуны сорый, авыл шуны көтә!

– Пролетар язучылар авылларга чыгып яңа авылны күрсеннәр!

– Академия театры үз артистларын кантоннарда күрсәтсен!

Гадел Кутуй

*(«Тамашачы»**. – 1929. – №5(10). – Б.1-3).*

*Кереш мәкалә һәм текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

*Шул ук журналда 1927 елның июленнән 1928 елның июленәчә самодеятельный авыл драма түгәрәкләре тарафыннан куелган спектакльләрнең саны һәм репертуары басылган:
«Мамадыш кантоны Мамалай волостендагы өч авылда 24 спектакль куелып, 1840 крәстиән булып узган; Алабуга кантоны Исәнбәй волостенда алты авылда 64 спектакль куелып, 5120 крәстиән булып узган; Минзәлә кантоны Күзкәй волостенда сигез авылда 71 спектакль куелып, 5680 крәстиән булып узган. Арча кантоны Арча, Тукай, Күлле-Киме, Мәмсә, Балтач, Теләче, Янгул, Сәрдә, Яңа Кишет, Мәмдәл, Питрәч, Чүриле, Урбар волостьларында 36 авылда 277 спектакль куелып, 35021 крәстиән булып узган. Авылда драма түгәрәкләренең репертуар ягына килгәндә, күбрәк «Уңган кыз», «Ун ел тулганда», «Ураза бәйрәме», «Бал тәпәне», «Габдерахман мелла», «Яңа тормыш юлында», «Ычкынды» кебек кечкенә күләмдәрәк әкият пьесаларының куелганын күрәбез. Шуның белән бергә, зуррак авыл сәхнәләрендә «Сүнгән йолдызлар», «Галиябану», «Печән базары», «Яшь йөрәкләр» кебек сәхнәгә куяр өчен авыррак, зуррак пьесаларны да очратырга туры килә».

Г.Нагаев. «Татарстан авылларында театр эшләре».

**«Тамашачы» журналының ТР Милли китапханәсе Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендәге нөсхәләре файдаланылды.

МӨҺАҖИРЛӘР МИРАСЫ

Садри Максуди Арсалның Сорбонна университетындагы соңгы дәресе

Кәмал Локман

Мәкаләнең авторы Кәмал Локман (1899-1976) – Төркиянең югары белемле беренче нефть инженеры. Ул Гренобль политехник институтын (Франция), соңрак Страсбург Югары милли нефть мәктәбен тәмамлый. 1929 елда Төркиягә килеп, Җир асты байлыкларын тикшерү һәм эзләү институтында (Maden Tetkik ve Arama Enstitüsü), төрле нефть оешмаларында дәүләт хезмәткәре буларак эшли һәм Төркиядәге нефть индустриясе үсешенә җитәкчелек итә. 1957 елда Төркия Җөмһүрияте нефть оешмасы (T.C. Petrol Dairesi) башлыгы итеп тәгаенләнә.

Гомерен нефть өлкәсенә багышлаган милләттәшебез – дистәләгән фәнни китап авторы. Төркиядә дөнья күргән журналларда басылган мәкаләләренең күп өлеше кара алтын табу, геология мәсьәләләренә багышланган.

Гаяз Исхакыйның кызы, галимә Сәгадәт Чагатайның Кәмал бәй вафатыннан соң «Азәрбайҗан» журналында (Төркиядә чыккан журнал, 1976 ел, 220 нче сан) басылган истәлек язмасында мондый җөмләләр бар: «*...Мәрхүм Кәмал бәй үзенең туган һәм балачагы узган, бабалары туып-үскән Идел-Урал һәм Төркестан өлкәсен һич онытмас. Бөтен илдәшләрен дус тотар, аларга төрле ярдәм күрсәтер. Төрки өлкәләрнең төрле җирләреннән килгән мөһаҗир дусларыбызның әтиләре кебек иде. Һәрберсен самими каршылар, кулыннан килгән кадәр ярдәм итәр, эш җире табар, урнаштырыр...*»

Кәмал Локман

Садри Максуди

Тел – бүген милләтнең иң тәэсирле һәм ачык бер документы, элементы буларак кабул ителә.

Кәмал бәйнең милли тормышыбызга кагылышлы берничә язмасы мәгълүм. Шулардан берсе – «Садри Максуди Арсалның Сорбонна университетындагы соңгы дәресе». Әлеге мәкаләсен ул остазының вафатына алты ел тулу уңаеннан язып, «Türk yurdu» («Төрек йорты») журналының 1964 елгы ноябрь санында бастырган.

Шуны әйтергә кирәк: 1920 нче елларда фикер иясе Садри Максуди аңа бик зур ярдәм күрсәтә. Кәмал Локман чит илдә укыганда матди кыенлыклар кичерә. Страсбургның Югары милли нефть мәктәбенә керү имтиханнарын бирүенә карамастан, укый алуы акчага бәйле була. Төркиянең Икътисад министрлыгы, нефть өлкәсе белгечләре кирәклеген искә алып, аның уку һәм яшәү чыгымнарын дәүләт хисабына алырга карар бирә. Әмма бер шарт куела: дәрәҗәле бер кеше аның өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга тиеш. Менә шулчакта ул Сорбонна университетында укыткан Садри Максуди Арсал белән очраша, аңа үзенең гозерен җиткерә. Мәшһүр татар мөгаллиме милләттәше өчен җаваплылыкны үз өстенә ала. Булачак нефть белгече шулай итеп югары белем алуын дәвам итә.

Кәмал Локман Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый кебек танылган татар мөһаҗирләре белән дә якыннан аралашкан, алар эшчәнлеген дәвам иткән.

Айзирәк Гәрәева-Акчура

1925 ел, май аеның соңгы көннәре иде. Париждагы Төрек укучылары (студентлары) җәмгыяте әгъзаларында бер хәрәкәт күзгә чалынды. Садри Максуди бу көннәрдә ике елдан бирле Парижда Сорбонна университетының әдәбият факультетында төрек тарихы турындагы соңгы дәресен бирәчәк иде. Әмма укучылар арасындагы хәрәкәт төгәл генә Садри Максуди бәйнең соңгы дәресен бирәчәгеннән тумады. Бу дәрескә ул заманда Төркиянең Париждагы баш консулы Фәтхи бәй дә чакырылган иде. Үз тарихлары турындагы дәрескә ике ел буе һич килмәгән бик күп студентлар бары тик илче киләсе сәбәпле залны тутырганнар иде. Асылда дәрескә даими йөрүчеләр арасында төрекләрдән тыш, күбрәк башка милләт кешеләре, бигрәк тә, төрек тарихы белән кызыксынган французлар да күп иде. Бәрәкәт бирсен (Аллага шөкер мәгънәсендә), Фәтхи бәй ни Төрек студентлары җәмгыяте әгъзаларына, ни җәмгыять җитәкчесенә Садри Максуди бәйнең дәресләрен дәвам итү-итмәвенә, файдалы булу-булмавына кагылышлы һичбер сорау бирмәде. Юкса бик зур кыен һәм комик бер хәл уртага чыгачак иде.

Һич онытмам, Садри Максуди бәй мөнбәргә иреннәрендә бер билгеле елмаю белән чыкты. Дәресен аңлата башлады. Садри Максуди Сорбоннада төрек милләтенең гомуми һәм бигрәк тә Исламга кадәрге чакларына бәйле тарихны укыта иде. Ул көнге соңгы дәресе бөтен ел буена укытылган дәресләрнең бертөрле нәтиҗәсе һәм йомгагы булып, Садри Максуди бәй тарихи вакыйгалар диалектикасыннан кайбер карарлар чыгарды. Соңгы дәресендә сөйләгәннәре акылымда төгәл калган. Бу дәресне кыскача шулай әйтә алам.

Төрек милләте милләт булу хосусиятенә бик борынгы чаклардан бирле казангандыр. Тарихның, вакыйгаларның, көч балансларының тәгәрмәчләре әйләнгәндә һәм шартлар үзгәргәндә, бик күп инсан җәмгыятьләре холыкларын, үз-үзләрен тотышларын үзгәрткән хәлдә, төрекләр барысы төрек буларак калганнар. Культура бәйләнешларын, кемлекләрен, атларын, бер үк халык әгъзасы булу рухын саклаулары һәм тарих буенча асыллык холкын дәвам итүләре төрекләрнең үзенчәлеге булган. Әйтергә

мөмкиндер ки: халык, милләт булу хосусиятендә иң югары дәрәҗәдә бер социологик дисциплинаны төрекләр күрсәткәндер. Характер берлеге, хәрәкәт итү бөтенлеге төрекләрдә биологик кануннар кебек нормаль һәм физик кануннар кебек ачыктыр. Тарихның төрле чакларында һәм төрле өлкәләрдә башка-башка исемнәр астында күктөрек, уйгыр, караханлы, Алтын Урда, чагатай, сәлҗуклы, госманлы төрекләре корган дәүләтләр һәм императорлыкларның нигезендә бер үк төрле тузмас, үзгәрмәс, затлы мәрмәр нигез бардыр.

Тел – бүген милләтнең иң тәэсирле һәм ачык бер документы, элементы буларак кабул ителә. Төрек теленең борынгы язма документы булган Орхан язмалары һәм бүгенге төрле сәяси чикләр эчендә яшәгән төркиләрнең телләре, диалектлары арасында бер чагыштыру ясыйк. Күрербез ки, төрекләрдә вакыт һәм урын үзгәргән шартларда инсани небулез халәте үзгәрми. *(Небулез – томанлык, астрономик җисемнәрнең газ халәтендә булуы. Астрономиядәге төшенчәсе – небулез таралмый һәм шушы үзенчәлеге белән Кояш һәм аңар охшаш планеталар тудыра. Таралса, яңа планеталар ясый алмый. – Тәрҗ. иск.)*. Социаль бер барлыкның тарихта шактый озын бер вакытта үзенең дәвамлылыгын биологик берәмлек кебек саклавы бернәрсә белән ачыклана: төрекләрдә милләт булу хосусияте – нык һәм нигезле бер реаль хәлдер. Бу якынлык, берлек ни латин, ни славян ырыкларыннан *(ыру. – Тәрҗ. иск.)* килгән милләтләрдә күренми.

Садри Максуди бәй мәсьәләнең гомуми торышыннан соңрак, бөтен тарих буенча корылган төрек дәүләтләренең охшаш үзенчәлекләренә күчте. Төрек мәдәниятенең формалаштыручы, тәшкиләтче ягына ишарә итте. Аннары төрек милләте җитештергән җитәкчеләр, лидерлар хакында сөйләде. Төрек ырыгының үткәне, бүгенгесе һәм тарихта уйнаган роле күзлегеннән карап бер анализ ясады. Дөнья каршысында алдагы заманда төрек милләтенә кагылган тарихи миссиядәниләр булачагы турында сөйләде. Төрекләргә йөкләнеләчәк бу миссияне бары тик бер сүз белән белдерде һәм дәресен тәмамлады. Әлеге кәлимә – Cest la Civilisation *(француз телендә. – Тәрҗ. иск.),* мәдәният иде.

Бу дәресеннән берничә көн соңрак Садри Максуди бәй, Әнкара Хокук мәктәбенә төрек хокук тарихы профессорлыгы вазыйфасына билгеләнеп, эшен башлар өчен Әнкарага китте*.

Садри Максуди Хокук факультетындагы дәресләре, ирекле сөйләшүләре, тел, тарих һәм хокук өлкәләрендә язган кыйммәтле әсәрләре белән илебездә җәмгыять үсешенә файдалы кешеләр арасында беренче рәттә тора иде. Аның фәнни һәм фикри юнәлеше күп язучылар тарафыннан эшкәртелер һәм тикшерелер.

Без монда, бу форсаттан файдаланып, Садри Максудиның кемлеге хакында бер фикер бирергә, туган җирендә һәм анда яшәгән вакытларда төркилек дәгъвасы хакына башлаган эшләрен күрсәтер өчен, 1328 (1912) елда ясаган бик кызыклы бер чыгышы турында сөйләргә телибез.

«Төрек йорты» журналына тәкъдим ителгән бу «алтын бүләге»ндә (ягъни чыгышында) Садри Максуди бәй Дума парламентында рус шовинистларыннан Алексеевка каршы төрек җәмгыяте исеменнән җавап бирә.

Төрек дошманы Алексеев шулай дигән: *«Мөселманнарның мәктәп мәсьәләсен алга күтәрүләре артында сәяси бер теләк ятадыр. Белем комиссиясендә башлангыч укуларда гарәпчә укыту кирәклеген әйтәләр, чөнки Коръән гарәпчә язылган имеш. Моның өчен иң башта гарәпчә, соңрак төрекчә укыту сорала. Белгәнебезчә, гарәпчә*

---

* Садри Максудиның «Әнкара хокук мәктәбенең тарихи әһәмияте» исемле мәкаләсе «Безнең мирас» журналының 2018 елгы декабрь санында төрек теленнән Миләүшә Гайнанова тәрҗемәсендә басылып чыкты.

Патша Русиясендәге мөселман массасы өчен ана теле түгелдер. Шул хәлдә ни өчен сорала бу? Ислам берлеге фикеренең таралышында кулайлык булдыру максаты белән! Төрекчә дигәннәре дә, үз телләре түгел, госманлы төрекләре теледер. Моны өйрәтүнең максатлары да Анадолудагы төрекләр белән бер көнне берләшергәдер! Кыскасы, мөселманнарның бу таләпләре бары сәяси максатларын туендыра».

Садри Максуди бу дәгъвага каршы Думада җавап бирә: *«Алексеевка күрә без, мөселманнар – панисламизм һәм пантюркизмны гамәлгә ашыруны тәэмин итүчеләр булабыз. Бу уңайдан мин ике мөһим мәсьәлә хакында фикерләремне белгертергә телим.*

Әфәнделәр, һәрберегез беләсез ки, бүген Русиядә кырык миллионнан артып киткән бер мөселман массасы бар. Әмма боларның һәркайсының аерым бер ырыктан килгәнен бәлки белмисездер дә.

Әйе, Русиядәге мөселманнарның барысы, саннары бик аз булган Кавказ таулары җирләреннән тыш, бер ырыктан, ягъни төрек ырыгыннан киләдер. Боларның бер үк ырыктан булуы бер тарихи вакыйгадыр. Алексеевның ризасызлыгы бу сөйләшүгә һичбер тәэсир ясый алмас. Икенче яктан, без – мөселман, дигән вакытта, ул сүз астына төрек мәгънәсен дә туры китергән булабыз.

Миннән алда сүз алган чыгыш ясаучыларның берсе төрек милләте фикерен безнең гүя халыкка бу сурәттә җиткергәнебезне дәгъва итте. Бу дәгъва буштыр. Русиядә яшәгән мөселманнарның барсының төрек булуы фән буенча раслангандыр. Менә сезгә русча бер этнографик карта. Бу картаны ни мин, ни дусларыбыз ясамады. Бу карта Дума мәҗлесендәге мөселман фракциясе дә ясаган түгел. Бу бары тик гыйльми тикшерү нәтиҗәләрендә сызылган бер картадыр.

Хакыйкать шушылай ап-ачык икән, безнең комиссияләрдә яки гомуми сөйләшүләрдә Русия мөселманнарының бер үк ырыктан булуларын, бер үк телдә сөйләшүләрен раславыбыз, ягъни фәнни исбатланганын уртага куюдан пантюркизм пропагандасын эзләү көлке булыр.

Төркиләрнең берлеге бүгенге көннәрдә килеп чыккан бер вакыйга түгелдер. Бик ерак вакытларда булган бер очрактыр. Берничә йөз ел элек Чыңгыз ханның сугышлары нәтиҗәсендә бөтен төрекләр берләшкән иде.

Русия мөселманнары – кайберләребез санаган кебек татар түгел, төректер. Татар кәлимәсе, гыйльми, тарихи бер сүз булмыйча, гаскәри бер гыйбарәдер. Чыңгызның гаскәрләре барысы төрки иде. Чыңгызның балалары һәм оныкларыннан калган элеккеге әсәрләр һәм Рус хәзинә документлары арасында булган Урда ханнарының фәрманнары саф бер төрек теле белән язылган. Бу яктан бакканда, Русиядә яшәгән мөселманнар төрек углы – төркидер. Һәммәсенең теле бердер һәм төрекчәдер. Кайчак кына мөһим түгел кайбер акцент аермалыклары бардыр».

Садри Максудиның Думада ясаган бу яклау җавабы ул вакытта Алексеев кебек славян шовинистларын чыгырыннан чыгарды, Русия чикләре эчендә зур резонанс уятты һәм аңа Төркия матбугатында бик яхшы һәм уңай кайтавазлар булды.

XIX йөзнең икенче яртысында төрки дөньяда милли уянышның, кӧтелмәгән бер вакытта кузгалып, ялкынланып китү тарихын барлаган һәркем Садри Максуди бәйне искә алмый кала алмас. Бу төньяк төрек җәмгыятьләре, Идел-Урал төркиләре җитештергән гаҗәп, уникаль шәхсиятләрдән берсе булган кыйммәтле философ, фикер һәм максаты өчен бөек хәрәкәтләргә кергән көрәш адәмен еш-еш искә алу, бер кадерләү, зурлау һәм бәяләү булачактыр.

Төрек теленнән ***Айзирәк Гәрәева-Акчура*** *тәрҗемәсе* ■

САРАЛЫ МЕҢ ЫРУЫ ТАТАРЛАРЫ

Раиф Мәрданов

Чулман, Ык һәм Иж елгалары буенда күп гасырлар дәвамында яшәгән һәм хәзер дә төп халкын тәшкил итүче милләттәшләребезнең тарихы бик кызыклы һәм ачыкланып бетмәгән табышмаклар белән тулы. Бу мәкаләдә Казан, Мәскәү, Киров, Уфа һәм башка шәһәрләрдәге архивларда сакланган материалларны өйрәнүем нәтиҗәсендә ачыкланган тарихи мәгълүматлар белән уртаклашырга телим. Әлбәттә, монда бәян итeләчәк мәсьәләгә караган архив материаллары һәм документаль дәлилләр бик күп. Аларның бөтенесен дә тасвирлап һәм искәртеп тору шактый урын алыр иде, шунлыктан, мөмкин кадәр чикләнергә тырышабыз.

Галим Дамир Исхаков, Чулман аръягының көнчыгыш төбәге Казан ханлыгы һәм Нугай Урдасының уртак буйсынуында булган территория, дип яза. Аның фикерен Нугай Урдасы тарихын өйрәнгән галим В.Трепавлов хуплый. Бу төбәкнең утрак тормыштагы халкы Казан ханнарына буйсынган, ә җәйге чорда болын-үзәннәр нугайлар карамагында булган.

Чулман елгасы буендагы Алабуга шәһәре һәм Сарапул каласы арасындагы җирләр



Алабуга өязе картасыннан. 1891 ел

электән үк татарларныкы булып, Казан ханлыгына буйсынганнар. XVI гасырның икенче яртысында әлеге шәһәрләргә рус хәрбиләре урнаштырылган, монастырьлар төзелеп, руханилар саны арттырылган. Алабуга шәһәре рус колонизациясенең көнчыгыш юнәлешендәге терәк пунктларыннан берсенә әверелгән. Бу «изге» эштә, Чулман елгасы буендагы Лаеш, Чистай һәм Мамадыштан кала, Алабуга дүртенче үзәк булган, дип язган В.Кудрявцев 1897 елда.

Рус биләмәләренең киңәеп баруы һәм 1630 нчы еллардагы калмык яулары нәтиҗәсендә нугай-татарларның Көньяк Уралдагы һәм Ык буйларындагы хакимлекләре какшаган. Гасырлар буе дәвам иткән яу-сугышлардан йончыган һәм тузгыган Мең ыруының Җаек-Чулман елгалары буендагы төп биләмәләре XVII гасырда руслар кулына кергән. Шулай да бу ыру вәкилләре, үзләренең ата-бабаларыннан калган җир-суларына хуҗа булырга тырышып, берничә гасыр буе дәгъвалашканнар.

Мең ыруының Дим елгасы буйларындагы җирләренә бәйле 1646 һәм 1671 еллардагы архив мәгълүматлары һәм шәҗәрә язмалары бар. Идегәй би дәвамчыларыннан Казанфар бинең һәм Чүблүк бинең уллары, шулай ук Уразлы Урман улы, Мәмәткол Тиңкәй улы, Аккунды Акман улы зур мәйданнардагы биләмәләрне үзара бүлешкәннәр. Бу кешеләрнең аксөяк затлар булганлыгы архив эшләренең берсендә: «...предки наши башкирцы, происходящие от княжества и тарханства татарского», – дип әйтелгән[1]. Ул биләмәләр хәзерге Башкортстанның Стәрлетамак, Дәүләкән, Благовар, Миякә, Чишмә, Гафури, өлешчә Бәләбәй һәм башка кайбер районнары берәмлекләренә керә. Мең ыруы дәвамчылары шулай ук Туймазы, Бишбүләк, Әлшәй, Учалы һәм Ярмәкәй районнарында, Татарстанның Менделеев, Әгерҗе, Тукай, Минзәлә, Сарман, Баулы, Ютазы һәм Азнакай районнарында яши. Биләмә 1646 елда бүленгәнче, әлеге зур территория Мең олысы (волосте) дип аталган һәм аның белән якынча 1610-1630 елларда Казанфар би идарә иткән. 1671 елда бүленгәннән соң, әлеге территориядә Мең татарлары ыруына караган шактый волостьлар барлыкка килгән. XVIII гасырның беренче яртысында төрлечә зурлыктагы андый волостьлар 70-76 исемдә булган.

Кайбер тарихчылар Мең ыруының зур территориясен XVII гасырда бүлешү вакыйгасына хәтле бу ыруның ике өлешкә аерылган булуын язалар. Ягъни, Сарайлы Мең һәм башка кайбер ыруларны күздә тотып, 1630 нчы еллардагы калмык яулары нәтиҗәсендә элекке Нугай Урдасындагы кабиләләр аерылып, көнчыгыш һәм көнбатыш тарафларга бүленгән, диләр. Ләкин архив документлары Сарайлы Мең ыруының көнбатыштагы – Алабуга һәм Ык-Чулман буйларындагы өлеше инде күптәннән шул төбәктә яшәп килгәнлеген раслый. Менә бу мәсьәләне галимнәр хәзергәчә нигезле итеп чишеп һәм аңлатып бирә алмыйлар.

Бик катлаулы һәм моңарчы тәфсилләп өйрәнелеп бетмәгән әлеге мәсьәлә документаль чыганакларның киң даирәсе ярдәмендә ачыклана төште.

Борынгы Мең кабиләсенең бер өлеше ханнар заманында ук Чулман

Алабуга шәһәрендә һәм аның янындагы Саралы исемле авылда Казан ханлыгы чорында Мең ыруына бәйле татарлар яшәгән. Шул заманнарда Чулман елгасы буенда төпләнеп яшәгән Мең (Сарайлы Мең) ыруы татарларының төп җир-су биләмәләре Чулман елгасына бер яктан – Ык, икенче тарафтан Иж елгалары кушылган урыннардан алып Тойма койган урынга кадәр, Чулманның ике ягы һәм Ык, Иж, Тойма һәм бүтән елга-инеш буйларында булган.

[1] Большая ложь историков Башкортостана: к вопросу о формировании сословия «башкир-вотчинников» в северо-западном Приуралье. – Казань, 2010. – С.19. (Канзафар исеме кайбер чыганакларда Казанфар рәвешендә язылган).

елгасының уң ягында яшәп килгән һәм бу төбәкнең төп хуҗасы булган. Чулман-Ык буйларындагы Саралы (Сарайлы) Мең волосте авыллары Алабуга янындагы Саралы (хәзерге Бехтерево) авылы кешеләренә бирелгән грамоталарны XVI-XIX гасырларда төп хокук документы буларак белдергәннәр. Ә татар һәм башкорт галимнәре Сарайлы Мең ыруының Канзафар би дәвамчылары тарафыннан 1671 елда зур территориядәге биләмәләрен үзара бүлешкәннән соң гына кайберләре Чулман буена (хәзерге Татарстанның Сарман һәм башка районнардагы авылларга) килеп төпләнгәннәр, дип ялгыш язалар. Чөнки Сарайлы Мең ыруы вәкилләренең 1671 елдан әүвәлгерәк җир хуҗалары, башкорт катлавы итеп түгел, ә татарлар буларак язылган грамота һәм ярлыкларга бәйләнешен аңлата алмыйлар. Моның төп хикмәте, архив документларыннан күренгәнчә, Мең кабиләсенең вәкилләре Алабуга төбәгендә борынгырак чордан – Казан ханлыгы вакытыннан яшәгәнлегенә һәм бу ыру халкының Ык буена күчеш процессы көнчыгыштагы меңлеләрдән түгел, ә Алабуга тарафларыннан барганлыгына бәйле. Аларның архив документларында татарлар буларак теркәлгәнлеге хәзерге башкорт галимнәренең Сарайлы Мең ыруы, имеш, этник башкортлар булган дигән ясалма теорияләренә туры килмәве дә мәсьәләнең дөрес чишелүенә бер киртә булып тора.

Дөрес, татар һәм башкорт галимнәре Чулман һәм Ык буйларындагы Саралы Мең ыруы тарихында ачыкланып бетми торган нәрсәләр бар, дип искәртәләр. Әмма Саралы авылында яшәгән һәм шуннан бер өлеше XVII-XVIII гасырларда Чулман елгасының аръягына, Ык елгасы бассейнына таралып урнашкан татарларның бу төбәктә ханнар заманында ук яшәп, күчеп урнашуы мәсьәләсенең очына чыгып бетә алмыйлар.

Мең ыруының Чулман буенда кайчан һәм ничегрәк урнашуы турында тарихчыларның хезмәтләрендә, кызганыч ки, фикерләр дә, фаразлар да юк диярлек. Чулман аръягындагы борынгы татар ырулары нигезендәге волость атамалары уңаеннан бары тик Дамир Исхаков: «Саралы Мең волосте мәсьәләсендә кайбер читенлекләр туа», – дип, 1980 нче еллардан ук язып килде. Башкорт галимнәре этник башкортлар дип ялгыш исәпли торган Сарайлы Мең шәҗәрәләрендә Ык-Чулман буйларындагы авылларга бәйле Мең ыруы грамоталарында теркәлгән кеше исемнәренең булмавын үзләре дә таныйлар, шулай ук: «Подобные труднообъяснимые моменты встречаются», – дип, Исхаков сүзләрен дә кабатлыйлар.

Галимнәрдән Е.И.Чернышёв һәм Д.Исхаков Саралы исемле авыл Казан ханлыгы вакытында булган, дип, гомуми фараз әйтеп үткәннәр. Ләкин Ык буендагы Сарайлы Мең волостена кергән төбәк тарихын өйрәнүчеләр, гадәттә, XVI гасыр грамоталарында язылган Саралыны хәзерге Сарман районындагы Сарайлы авылы белән тәңгәлләштереп хаталаналар[2]. Шулай да төбәк тарихы белгече Дамир Гарифуллин китапларында Алабуга янындагы Саралы авылы белән бәйләү омтылышлары очрый.

Саралы дигән атама үзе Сарайлы исеменнән чыккан булса да, Алабуга янындагы авылга карата кулланылган Саралы (Сарали) рәвешендәге язылышы бу ыруга бәйле документларда нәкъ шулай – «Саралиминская волость» дип язылып килгән. Алабугада рус хакимлеге көчәеп, анда руслар күбәйгән саен, Саралыда һәм аңа якын авылларда яшәгән татарлар читкәрәк күченә барганнар. Монастырьлар һәм чиркәүләр төзелгәч, мөселман динен тоткан татарлар, чукындырудан хәвефләнеп, туган җирләрен калдырып китәргә мәҗбүр булган. Саралыда яшәп килгән татарлар электән

[2] Борынгы биләмә грамоталарында һәм архив язмаларында телгә алынган Саралы авылын кайбер галимнәр Сарман районындагы Сарайлы авылы икәнлеген белдерү өчен архив документларын тасвирлаганда да, «Сарали» исеме очраган саен, җаяләр эчендә Сарайлы дип өстәп баралар.

үк үз биләмәләрендәге тынычрак урыннарга китеп торган булсалар да, аларның төп авылларыннан 1630 нчы елларда бөтенләй күчеп беткәнлекләре аңлашыла. Әле 1619 елда да Саралыда татарлар яшәгән. 1625 елда Саралы авылы татарлары грамота алган вакытта да, ихтимал, шунда торганнардыр. Ләкин шул ук грамотаны 1643 елда яңартканда Саралы авылы кешеләре буларак язылсалар да, инде анда яшәмәгәннәр. Саралы татарларының бер өлеше Татар Чаллысы авылына (хәзерге Менделеев районында) күчеп урнашкан булса, калганнары хәзерге Бәзәкә, Турай, Тогыҗа авылларына һәм башка урыннарга күчкәннәр. Һәрхәлдә, туган төбәкләрендәге төп җирләреннән еракка китәсе килмәгәнгә, баштарак якын-тирәдә урнашканнар. 1648 елгы Писцовая книгада (кенәгәдә) Саралы авылының «ясачное село» дип теркәлүенә караганда, ул вакытта инде анда руслар яшәгән булса кирәк.

Татар тарихына багышланган соңгы фундаменталь хезмәтләрнең берсендә тарихчы Д.Исхаков болай дип яза: «Население Саралы Минской (центр – с.Саралы) волости, известной уже с 1581-1595 гг., в 1641 г. именуется «чувашами», затем, в 1658 г. – «бобылями», позднее – «ясачными татарами» и «башкирами». Очевидно, это население берёт начало с первой четверти XVII в. и связано с «ясачными чувашами»[3] д.Сардык Арской даруги Казанского уезда, владевшими вотчинами по рекам Ик, Сюнь»[4]. Исхаков Саралы авылы үзе кайда булганын төгәл әйтмәсә дә, аның, һичшиксез, Алабуга янындагы Саралы авылы икәнлеге безгә аңлашыла. Галим Саралы Мең волосте халкының Сәрдек исемле авылга (андый исемдәге авыллар хәзерге Кукмара һәм Балтач районнарында бар) бәйләнеше турындагы сүзләренә дәлил китермәгән һәм безнең дә андый бәйлелекне раслый торган архив документын күргәнебез булмады. Д.Исхаковның Саралы Мең волосте халкының XVII гасыр башыннан мәгълүм булуы турындагы сүзләре Чулман аръягы төбәгенә карата әйтелгән. Галим икенче бер хезмәтендә дә Минзәлә елгасы буендагы Сарайлы Мең ыруы кешеләре үзләрен Казан өязендәге Казан ханлыгы чорында ук булган Сарайлы авылыннан күчкәнлекләре турында яза, тик анда да Сарайлы (Саралы) авылының урнашкан төгәл урыны турында фикерен белдерми.

Чулман елгасының уң ягындагы Саралы, Бәзәкә, Турай, Тогыҗа, шулай ук бүтән авылларда яшәгән борынгы бабайлар үзләрен татарларның борынгы Мең кабиләсенә бәйләгәнлеге шәҗәрәләрдә һәм архив документларында язылган. Минем фикеремчә, Мең кабиләсенең бер өлеше, XV гасырның икенче яртысында Нугай Урдасы белән Казан ханлыгы арасында мөнәсәбәтләр җайлана башлаганнан соң, якынча 1480-1490 нчы елларда Алабуга шәһәрендә һәм аның тирәсендә, Чулман елгасының ике ягында төпләнеп яшәгән. Алар Казан ханлыгы чорында шул төбәктә гомер кичергәннәр һәм төп биләмәләре Чулман, Ык, Тойма, Иж һәм башка елга буйларында булган. Казан ханлыгы яулангач, рус патшалары заманында Мең ыруы татарларының биләмәләре кими барган: бер өлеше тартып алынган, кайсыдыр җирләрен үзләре ташлап киткәннәр, күпмесендер рус алпавытларына һәм казнага сатканнар, шактый өлешен вакытлыча файдалану өчен төрле авылларга арендага биргәннәр. Андыйлары да, еллар узгач кире кайтарылмыйча, яңа хуҗалары милкенә күчә барган. Шулай ук хакимият кысуы, русларның бу төбәктә артуы-күбәюе белән бәйле рәвештә һәм төп биләмәләрен югалтмас өчен, Чулман аръягындагы җирләренә урнашып, авыллар корып яшәгәннәр. Шунысы мөһим: гасырлар кичсә дә, Җаек буйларында яшәгән кабиләдәшләре белән кардәшлекне онытмыйча, борынгыдан бәйләнештә булуларын,

[3] Монда әйтелгән «башкорт», «чуаш» һәм ясаклы татар кебек атамалар сословие-катлау бүленешләрен белдерә.
[4] История татар с древнейших времён. В семи томах. Том V. – Казань, 2014. – С.308.

XVII гасыр башында яшәгән Канзафар би Муса улына туганлыкларын искәрткән XVIII һәм XIX гасырлардагы архив документлары бар.

Димәк, архивлардагы тарихи мәгълүматларны җентекләп өйрәнүдән аңлашылуынча, Алабуга шәһәрендә һәм аның янындагы Саралы исемле авылда Казан ханлыгы чорында Мең ыруына бәйле татарлар яшәгән. Шул заманнарда Чулман елгасы буенда төпләнеп яшәгән Мең (Сарайлы Мең) ыруы татарларының төп җир-су биләмәләре Чулман елгасына бер яктан – Ык, икенче тарафтан Иж елгалары кушылган урыннардан алып Тойма койган урынга кадәр, Чулманның ике ягы һәм Ык, Иж, Тойма һәм бүтән елга-инеш буйларында булган. Хәзерге Менделеев районындагы Бәзәкә, Турай, Әтәс, Тогыҗа, Удмуртиядәге Татар Туембашы, шулай ук бу төбәктәге һәм Чулман аръягындагы башка күп авылларда яшәүчеләрнең борынгы уртак бабаларының төп биләмәләре мондый документаль чыганаклар һәм дәлилләр белән раслана:

1. 1523 елның 1 гыйнварында (һиҗри 929 елның 13 нче сәфәр көнендә) Казан



Ык буендагы биләмә бәхәсенә багышланган архив эшенең бите. 1791 ел

ханы Сахибгәрәй тарафыннан бирелгән тарханлык ярлыгы[5]. Анда «әүвәл хан агаларымыздан тархан булган», дип, 7 кеше: Мөхәммәт улы Шәехәхмәт, Шәехәхмәт улы Әбдал, Сәетәхмәтнең (Шәехәхмәтнең) энесе Мәхмүтәк белән улы Муса, Сәет улы Ягъкуб һәм ике энесе Бүләк белән Нурсәет телгә алынган. Сахибгәрәй хан тарафыннан, «Тәңре Тәгалә ризасы вә Мөхәммәд рәсүлуллаһ шәфәгате өчен тархан кылдым», аларның Ык елгасы буендагы җир-су биләмәләренә, кешеләренә, яшәгән урыннарына беркем дә тыкшынмасын, салымнар салмасын, мал-мөлкәтләренә тимәсен, һичбер зыян-зарар китермәсеннәр, дип язылган.

1523 елгы хан ярлыгы шактый таушалган булса да, Казан ханлыгы чорыннан төп нөсхәдә сакланып калган бердәнбер һәм фәнни яктан бик кыйммәтле язма чыганак буларак, XX гасыр башы тарихчыларыннан алып хәзергәчә, галимнәр тарафыннан өйрәнелеп һәм элегрәк аңлашылып бетмәгән урыннары ачыкланып килә. Ярлыкның текстындагы «Ык» елгасы исеме әле соңгы елларда гына тарихчы Ильяс Мөстәкыймов тарафыннан тәгаенләнде. Ул гарәп хәрефләре белән язылган «Ак» яисә «Ык» дип укырга мөмкин булган сүзнең «Ык» икәнлеген, ләкин аннан соң «буендагы» яисә шуңа охшаш бүтән бер сүзнең язылмыйча калганын белдерде[6]. Мөстәкыймов шулай ук Д.Исхаков, М.Әхмәтҗанов һәм Д.Рамазанованың әлеге ярлык ияләре хәзерге Татарстанның Питрәч, Саба, Теләче ягы кешеләре булгандыр, дигән фаразларының, башкорт галимнәренең ярлыкны Ирәкте ыруына нисбәт итүенең дә дәлилләре булмавын язды. Ярлыкның төп нөсхәсе галим Сәет Вахиди тарафыннан Мамадыш ягында табылган булуы уңаеннан, И.Мөстәкыймов, әлеге борынгы документка мөнәсәбәте булган берәр туганнары белән киткәндер, дип фаразлый[7]. Үз

1523 елда язылган Сахибгәрәй хан ярлыгы

[5] Әлеге тарханлык ярлыгының 1912 елда галим Сәед Вахиди тапкан төп нөсхәсе Татарстан Республикасының Милли музеенда саклана.

[6] Мустакимов И. Ещё раз о казанском ярлыке Сахиб-Гирея // Средневековые тюрко-татарские государства. Сборник статей. Выпуск 5: Вопросы источниковедения и историография истории средневековых тюрко-татарских государств. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2013. – С.36.

[7] Борынгы кулъязма истәлекләр (шул исәптән, документлар да) саклаңган бик күп кешеләрнең төрле сәбәпләр белән чит-ят төбәкләргә күчеп китүе очраклары бихисап булган. Мәсәлән, Казан, Оренбург яки теләсә кайсы авыл кешеләренә бәйле язмалар Россия киңлекләрендә төрле урыннарда: Әстерханда, Себердә, Кырымда, Урта Азиядә, хәтта Төркиядә һәм башка төбәкләрдә табылып торуы бер дә сирәк һәм гаҗәп хәл түгел. Шуның кебек үк, чит-ерак җирләрдәге кулъязма истәлекләр Татарстанның теләсә кайсы авылында табыла. Бу – табигый һәм киң таралган күренеш. Хәтта 1999 елда Оренбург өлкәсендә табылган бер үк (!) кулъязма китапның төшкән битләрен 2000 елда Пермь өлкәсендә тапкан идек (Мәрданов Р. Китапларда милләт язмышлары... – Казан, 2010. – Б.72).

Мең ыруына бәйле татарлар Казан ханлыгы җирендәге Алабуга шәһәрендә яшәп, Чулман аръягындагы төбәк белән идарә иткәннәр.

тарафымнан бу фикерләрне куәтлим, хан ярлыгын башка галимнәрнең Казан арты төбәгенә бәйләргә тырышулары, чынлап та, дәлилсез. Өстәвенә, Ык буйлары биләмәләренә гасырлар дәвамында иң күп дәгъва кылып, үзләренең борынгы бабаларыннан килгән җирләре булганын исбатларга тырышкан кешеләр – төп чыгышлары белән Алабуга янындагы Саралы авылы токымнары икәнлеге күп санлы архив чыганаклары белән раслана. Андагы биләмә хокукларын дәвамлы рәвештә даулаган бүтән төбәк кешеләренә бәйле архив документлары очраганы юк. Ә Саралы Мең ыруы үз бабаларыннан калган ул биләмәләренә хокукларын рус патшалары исеменнән дистәләрчә мәртәбә (XVI гасырда гына да 1562, 1567, 1574, 1577, 1580, 1595 елларда) раслатканнар, XVII-XIX гасырлардагы биләмә бәхәсләрендә шул ук документларга нигезләнгәннәр.

XVII гасырда Ык елгасы буендагы биләмәләренә башка ыру кешеләре тыкшынгач Турай авылында яшәгән Турай бабайның Чуашай исемле улы, 1678 елда рус патшасына шикаять язып, тикшерү эше башланган. Чуашай үзе 1679 елда вафат булганнан соң[8], аның Минзәлә төбәгендәге Мөшеге авылында яшәгән ырудашлары эшне дәвам иткәннәр, тикшерүдә 1523 елгы хан ярлыгы борынгыдан килгән биләмә хокукына дәлил буларак кулланылган.

Бу документта Чуашай «чюваш» (ягъни ясаклы татар) дип язылган. Әлеге бәхәсле биләмәнең баштагы хуҗасы Турай булуы һәм аннан соң аның улы Чуашай белән иптәшләре биләгәнлеге («...владели Казанские дороги деревни Тураевы чуваша Турай с товарыщи и товарыщи Чувашаевы Океш Доскеев, Мурзакай Юкачеев с товарыщи»), ул җирләр әүвәлдән үк үз бабаларыныкы булып, вакытлыча ташланып торганлыгы язылган. Ташланып тору вакыты, Нугай Урдасындагы тынгысызлыклар белән бәйле рәвештә, бигрәк тә 1630-1640 нчы еллардагы калмык яулары заманына туры килгәндер. Тикшерүдән ачыклануынча, 1621-1628 елларда турайлылар биләмәсенең бер өлеше Ирәкте ыруы «башкорт»ларына бирелгән булган. Документта Чуашайның «иптәшләре» дип күрсәтелгән ырудашлары – Мөшеге (хәзерге Минзәлә районындагы Татар Мөшегесе) авылының ясаклы татары Әкәш Дүскәй улы (Акешка Доскеев) белән Морзакай Юкәче улы бу бәхәсле мәсьәләне дәвам иткән[9]. Ирәкте ыруы башкортлары: бу ясаклы татарларның биләмәләре Казан өязенең Җөри даругасындагы Кече Чөмән елгасы буенда урнашкан Балтач авылында һәм Тойма елгасы буенда дигәннәр. Ә татарлар үзләре анда (ягъни Казан өязендәге әлеге авылларда) борынгы бабаларының Уфа шәһәре төзелгәнче (ягъни 1574 елга кадәр) үк яшәгәнлеген әйткәннәр.

Документта Мөшеге авылы татарларының Чөмән һәм Тойма елгалары буена бәйләп XVI гасырга карата әйтелгән ишарәсе Ык буендагы биләмәләрнең Чулманның уң ягыннан күчкән кешеләр карамагында булганын дәлилли. Әүвәл Саралы авылында, аннан соң Бәзәкә, Турай, Тогыҗа һәм бүтән авылларда яшәгән һәм алардан Чулман аръягына күчеп киткән Мең ыруына нисбәтле татарларның борынгы бабаларын 1523 елгы хан ярлыгына турыдан-туры тоташтыра торган кеше исемнәре ачыкланмаса да, күп санлы архив документларының һәм нәсел-ыру тамгаларының раславы нигезендә, Саралы авылы татарлары Чулман һәм Ык буйларын төп хуҗалар сыйфатында биләгәнлеге ачык аңлашыла. Бу исә, үз нәүбәтендә, Чулман елгасының аргы ягындагы – Минзәлә төбәге җирләре әүвәл Казан ханлыгы һәм Нугай Урдасының ур-

[8] Кабериндәге ташъязмасы бүгенге Менделеев районының Турай авылы зиратында хәзергәчә сакланган.
[9] Архив документындагы «товарыщи» дигән сүз, гадәттә, ыру-нәсел кардәшлеген аңлаткан.

так буйсынуында булган, дигән фикерне дә куәтли. Мең ыруына бәйле татарлар Казан ханлыгы җирендәге Алабуга шәһәрендә яшәп, Чулман аръягындагы төбәк белән идарә иткәннәр, дигән фикер туа.

Чулман елгасы буйлап югарырак урнашкан Сарапул шәһәрен руслар яулап алгач, анда электән яшәгән татарларның якын-тирәдәге дистәләгән авылларда торганлыгын искә төшерик. Сарапулга иң якын татар авылы 5 чакрымда урнашкан булган[10]. Шуның кебек үк, Алабуга каласындагы татарлар да, руслар басып алгач, башта якын-тирәдәге авылларда торганнар, төп авыллары Саралы исә Алабугага иң якыны булган. Саралыда XVII гасыр башында яшәгән Мең ыруы вәкилләренең бәетләрдә дә «Алабуга олылары» дип зурлап аталуы, шул ыру вәкилләренең кайберләре патша заманында тархан дигән дәрәҗәләрен кайтаруы, бу нәсел кешеләренең Чулман аръягына күчкән кайбер тармакларының хәзергәчә «аксөякләр» дип йөртелүе тарихи чынбарлыкны чагылдыра.

Сахибгәрәй хан ярлыгының Мең ыруы вәкилләренә бирелгән булуын нәсел-ыру тамгалары дараслый. Ык елгасы буендагы Исламбакты авылында (1742 елдан билгеле, хәзерге Башкортстанның Ярмәкәй районында) яшәгән кешеләр дә шул ук ярлык нигезендә рус патшалары заманында тарханлык хокукларын яңартканнар. Аларның XVIII һәм XIX гасырлардагы нәсел тамгалары Турай һәм Бәзәкә авылларындагы ырудашларыныкы кебек үк булган.

Бәзәкә, Турай, Әтәс, Тогыҗа һәм башка авылларда яшәгән татарларның үзара кардәш борынгы бабалары бөтенесе дә гомуми (шул исәптән, Ык буендагы) биләмәләренең уртак хуҗалары булып, турайлылар кузгаткан тикшерү эшенә дәлил итеп китерелгән борынгы документ – хан ярлыгына мөнәсәбәте булган кебек үк, Салагыш һәм Байлар авыллары кешеләренең әүвәлге бабаларының да 1523 елгы хан ярлыгына бәйләнеше булган, дип исәплибез. Ул авылларда яшәүчеләрне электән килгән кардәшлек бәйләгән[11].

1523 елда Сахибгәрәй хан ярлыгында исемнәре теркәлгән кешеләргә элекке ханнар тарафыннан ук тарханлык дәрәҗәсе бирелгәнлеге турындагы сүзләрдән аңлашылганча, аларның ата-бабалары (күрәсең, XV гасырда) шул ук биләмә хуҗалары һәм тархан-аксөякләр булганнар. Ярлык текстында аларның төп яшәгән урыннары әйтелмәгән. Ләкин XVII гасырдагы тикшерү эшендә бу ярлыкта исемнәре язылган кешеләр варисларының төп ватаны Тойма елгасы буенда икәнлеге ачыкланган.

Дәвамы бар ■

[10] Тарихи хезмәтләрнең күбесендә Сарапул шәһәре XVI гасыр ахырында гына нигезләнгән, дип язылса да, тарихи чыганаклар бу тирәдә төрки-татарларның борынгырак заманнан яшәгәнлеген раслый. Мәсәлән, Сарапулдагы борынгы мөселман каберлегендә 1351 елгы эпидемиядән һәлак булган кешеләр җирләнгәнен рус галимнәре 1909 елда ук ачыклаган. Казан ханлыгын руслар яулап алганнан соң, Сарапул шәһәрендә борынгыдан яшәгән татарларның, аннан куылып, авылларга таралуын раслый торган архив чыганаклары да бар. Мәсәлән, 1780 елгы бер рәсми документта Сарапул шәһәре турында: «На сём месте был в старину Болгарский городок, которого жители по завоевании российскими разошлись по деревням», – диелгән. Ул вакытта куылган татарлар еракка таралмыйча, күпчелеге Чулман һәм Сарапул елгалары буендагы авылларда яшәгәннәр. Колонизация көчәйгән саен, бу төбәктән читкә качып һәм күчеп киткәннәр. XVIII гасырда бөтенләй бушап калган татар авылларына руслар һәм удмуртлар урнашкан. XIX гасыр мәгълүматлары нигезендә, Сарапул төбәгендә (әлеге калага 5-50 чакрым ара даирәсендә) алтмышлап татар авылы – Татаркино, Болгуры, Атабаева һ.б. булганлыгы турында язган идек (Мәрданов Р. Сарапул төбәгендә татар эзләре // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2006. – №1. – Б.222-227).

[11] Башта Мең (Саралы Мең) волостенда теркәлгән Бәзәкә, Турай һәм аларга ырудаш башка күп авылларның XVII-XX г. башларында административ яктан Байлар һәм Салагыш волостьларына кергәнлеген дә искәртик.

КУЛАТКЫ УКУЛАРЫ

Илдус Әмирханов:
«Дәүләт милләтне тудырмый, милләт дәүләтне тудыра!» *



Без барыбыз да диярлек дәүләтне кешелек җәмгыятен коруның таҗы, кешелек цивилизациясе тудырган барлык кыйммәтләрнең тупламасы дип саныйбыз. Бәлки шулайдыр да. Әмма дәүләт ул кеше өчен үзмаксат түгел, ә бары тик Аллаһ кануннарын бозуның трагик нәтиҗәсе. Илаһи һәм милли кыйммәтләрдән мәхрүм ителгән халык иртәме-соңмы җаһилият дөньясын тудыра. Аллаһ тарафыннан илаһи кыйммәтләргә корылган рухи-илаһи җәмгыять атомар дәрәҗәдә таркала. Адәм баласы үзара талашып-үтерешеп бетмәсен өчен, игелекле басым көченә (на благонамеренное насилие) таянган, әмма илаһи һәм милли кыйммәтләрдән арынган дөньяви дәүләт системасын торгыза. Коръәндә: «Кардәшлек җепләрен өзмәгез, бер арканга тотынып, өммәтне саклагыз», – дип әйтелгән Аллаһ сүзләре инкарь ителеп, шәхес-гаиләләр, ыруг-кавемнәр, милләтләр таркала. Алар барысы сәяси халыкка, гражданнарга, электоратка, динсез-кыйбласыз массага әйләнә. Эш шунда ки, кешелек дөньясы, марксистлар раслаганча, тәрәккый үсеш (прогресс) юлыннан түгел, таркалыш (регресс) юлыннан бара. Төгәлрәк итеп әйткәндә,

** Галим, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Илдус Госман улы Әмирхановның** (1941-2018) бу мәкаләсе 2016 елның 24 декабрендә Болгар шәһәрендәге Ак мәчеттә узган XV «Кулаткы укулары»нда ясаган «Рухи җәмгыятьтә диннең, милләтнең һәм дәүләтнең тоткан урыны» исемле докла- ды нигезендә әзерләнде. Гомере буе татар дәүләтчелеге, милли мәгарифе идеяләре белән янып йөргән милләт каһарманының бу иң соңгы чыгышы, туган халкына актык мөрәҗәгате иде.*

социаль-матдәви үсеш (прогресс) рухи-инсани таркалыш исәбенә корыла. Моны раслап торасы да юк. Бөтен процесс күз алдында. Шуңа күрә дә мин һәр хезмәтемдә дин, милләт, дәүләт, җәмгыять төшенчәләренә төгәл аңлатма бирергә тырышам. Чөнки боларны бутаган җәмгыятьтә җитди дини, милли, социаль һәм сәяси каршылыклар килеп чыгуы бар. Мәсәлән, гомумкешелек кыйммәтләре арасында иң югары дәрәҗәгә дини кыйммәтләр ия. Чөнки Аллаһ кануннары барлык кануннардан да өстен. Табигать кануннарына нигезләнгән милли кыйммәтләр исә икенче урынны били. Аларны бер мәхлук та, шул исәптән табигать таҗы дип саналган бер генә кеше дә үзгәртә дә, боза да алмый. Чөнки табигать кануннары үзләре дә тулысы белән Аллаһ кануннарына буйсынган. Өченче урынны исә социаль-матдәви кыйммәтләр били. Социаль җәмгыять кануннарын, Аллаһ кануннарына һәм милли кануннарга нигезләп, төрле сәяси юллар белән (мәсәлән, парламентлар аркылы) кешеләр үзләре төзи. Әгәр дәүләт системасы милли-илаһи кануннарны инкарь итеп яки кыйммәти дәрәҗәләрен бозып социаль кануннар нигезендә генә төзелсә, ул дөньяви дәүләт дип санала һәм әкренләп җаһилияткә бата. Мондый дәүләтләр, үзара каршылыкка кереп, йә бөтенләй таркалалар яисә, көчлегә буйсынып, мәмләкәтләр (империяләр) хасил итәләр. Кыйммәтләр һәм иҗтимагый яшәү системасы, шәхси яки бер төркемнең, Ибн Халдун әйтмешли, асабиянең социаль-матдәви ихтыяҗына буйсына. Мондый җәмгыятьләрдә Патша да, имам да, парламент та, хәтта халык үзе дә бер диктатор, бер фиргавен яки бер императорга тез чүгә. Кешелек дөньясы бүген, беренче-икенче дәрәҗә кыйммәтләрне бозып, өченче-дүртенче дәрәҗә кыйммәтләр системасы эчендә яши. Татар исә, гомумән, биш гасыр инде дүртенче дәрәҗәдән чыга алмый, өченче дәрәҗә кыйммәтләр өчен көрәшә. Чөнки кыйммәтләр иерархиясен танымый. Аллаһ, милләт исеменнән дә бары тик шәхси ихтыяҗдан чыгып файдалана. Аллаһ боларның барын да күрә һәм аңардан милләт тә ясамый, дәүләт тә бирми.

Шуңа күрә татарга дөньяви дәүләт артыннан куарга түгел, ә рухи җәмгыять кору турында уйларга кирәк. Рәсәйнең үзендә генә дә иллеләп фирка бар. Аларның гакыйдәләре бер – социаль-матдәви. Диннәр нияттә Аллаһ фиркасенә керергә дәгъва итә, әмма ислам дине үзе генә дә дүрт мәзһәпкә, 73 фиркагә бүленгән. Һәркайсы үзен генә Аллаһ фиркасе дип саный. Башка диннәрне көфергә кертә. Бүтән диннәр дә нәкъ шулай. Шуңа күрә дә алар бер-берсе белән ызгышып тора. Шуларның барысы да галәмнәр хуҗасы Аллаһка түгел, ә малга-акчага ия булган, ачыктан-ачык диннән читләшкән дөньяви дәүләткә буйсына. Юк, мин патша, дәүләт, дин, түрәгә каршы чакырмыйм, бары аңга, гыйлемгә килергә генә өндим:

Алла ниятен яхшырак аңлыйк,
Белмәгән килеш фетнә ясамыйк.
Дөнья бетәрдәй бүген тоела,
Елгалар ясап, каннар коела...
Сукыр акчага иманны сатмыйк,
Аллага сылтап, фетнә ясамыйк!
Безгә җитәкче булсын чын имам,
Тик шунда булыр бездә чын иман!
Без теләмибез хаким булырга,
Телибез бары уттан котылырга!
Чөнки барыбыз тирән гөнаһлы,
Кан коймый җирдә, юуыйк гөнаһны,
Ташлап киткәнче фани дөньяны.

Үлсәк тә үлик Аллаһ юлында,
Әҗере бары аның кулында.
Татарга бирим тагы бер киңәш:
Аллаһтан башка эзләмик иптәш.

Тавыш чыгарып кысыр дәүләт артыннан куганчы, илдә хали булганчы, илаһи татар милләтен торгызырга чакырам. Моның өчен, беренче чиратта, татар милли өлгесен булдырырга кирәк, дип саныйм. Соңгы ун ел эчендә Россия Фәннәр академиясе, аның күп кенә фәнни институтлары урыс халкының (милләтенең түгел!) индификаторларын эзли, цивилизация потенциалын барлый. Әмма һаман да бер урында таптанып, империячел калыбыннан чыга алмый. Шуңа күрә таркалыш кичерә, татар да аның форваторында бара.

Татарның милли өлгесен эшләү өчен мин, беренче чиратта, ата-бабаларыбыздан килгән «кендек җиребез»дә, фикердә булса да, үзебезне хуҗа итеп сизәргә тиешбез, дигән шигарне сайладым. Чөнки, илаһи кануннар буенча, кендек җиреннән мәхрүм ителгән халык – кол халык. Андый халык Аллаһ рәхмәтендә була алмый. Һичшиксез, татарның «кендек җире» – элекке Болгар, Казан ханлыгы биләмәләрендәге Татарстан. Татар халкының милли Ватаны – Идел-Урал төбәге. Аның чикләрен шунда даими яшәгән халыклар билгели. Алар, үзара килешеп, тигез хокуклы милли субъектлардан торган, тарихи Рәсәй цивилизациясе чикләрендә Идел-Урал федерациясен төзи. Башта – фикердә, ә вакыты җиткәч, гамәлдә. Башка халыклар белән берлектә бу җирләрне татар халкының Ватаны яки саклык кальгасы, дип атарга тулы хакыбыз бар. Моны һәр татар калебенә салып куярга һәм беркайчан да онытмаска тиеш. Губернага әйләндергәндә дә, бүлеп-кушып, татар илен юк иткәндә дә... Моны этник урыс милләте түгел, урыс халкы исеменнән аның эчке дошманнары эшләве мөмкин. Шуңа күрә милләт белән дәүләтне бутамыйк.

Татар бу җирлектә рухи җәмгыять корып яши һәм шулай яшәргә тиеш. Бу җирдә шәхси ирек Аллаһ биргән ихтыяр ирекe дәрәҗәсендә йөри. Бу татарга гына түгел, анда яшәгән барлык этник төркемнәргә дә кагыла. Чикләнгән мәҗбүрият уртак килешүләр нигезендә генә була ала. Татар җирендә түрә – кол, олы һәм кече туган мөнәсәбәтләре юк, тигез хокуклы хуҗалар мөнәсәбәте генә бар.

Бу эштә татарның төп аркадашлары – Идел-Урал төбәгенең «кендек җиренә» ия булган төп халыклар: башкорт, чуаш, удмурт, мари, мукшылар белән бергә элекке тарихи биләмәләрендә үз милли ватаннарын торгызырга теләүче, мәмләкәтчелек чиреннән арынган этник урыслар.

...Җир-суыннан, җир асты һәм җир өсте мәгъдәннәреннән, милек-малыннан мәхрүм ителгән, диненнән, теленнән, имласыннан, гореф-гадәтләреннән ваз кичкән, кызларын ят кавемнәргә бирергә мәҗбүр ителгән халык милләт була алмый. Ул бары тик башка милләтләрнең колы, ялчысы, дошманны үрчетүче генә була ала. Үзенең коллыгын аңламаган халык дәүләт тә төзи алмый. Дәүләт милләтне тудырмый, ә милләт дәүләтне тудыра. Элекке татар дәүләтләрен дә милләт тудырган. Милләт таркалгач кына, дәүләтләр таркалган. Әмма элекке милләтне инде тергезеп булмый. Яңа дәүләтне төзү өчен яңа милләт кирәк. Моның өчен аның милли өлгесе, милли үзбилгеләнү, милли идарә принциплары эшләнә. Шуннан соң гына федерация һәм, ниһаять, дәүләт туа ала. Барны җимерми генә рухи ил төзик! Арбаны аттан алда куеп, без бер генә адым да алга китә алмаячакбыз. Көфер дөньясына, аның «халыкара» оешмаларына, динсез каһинәләренә, дөньяны садум гөнаһына батырган «хокук сакчыларына» ирек сорап мөрәҗәгать итүләр иблис ярдәмендә җәннәткә керергә тырышу гына. ■

Ризаэддин Фәхреддин
гыйбарәләре

• Юмартлык ирләр вә үзләре мал табучылар өчен гүзәл эш саналган хәлдә, ирләр тәрбиясендә торучы вә алар кул көче белән ризыкланып көн үткәрүче хатыннарга гүзәл холык түгел.

• Мактау вә хөрмәт сөю – олуглар өчен гүзәл холык саналмаган бу эш, яшьләр өчен гүзәл холык саналырга тиешле. Чөнки мактауны сөюче яшьләрнең, үзләренең мактауларын күрү сәбәпле, яхшы эшләр кылулары, иҗтиһадлы һәм дә гафифи вә гүзәл холыклы булулары мөмкин.

• Зиннәт сөю – бу эш яшьләр, зариф вә әдипләр, хатын-кызлар өчен гүзәл холык саналган хәлдә, галимнәр, фазыл вә кәмаләт әһелләре вә картлар өчен хурланган холык.

• Мәртәбә вә эше, дәүләт вә байлыгы булмаган кешеләрне чит милләтләр түгел, хәтта үзләренең кабыргалары янында торучы хатыннары да санга санамыйлар. Шундый кешеләр сәбәбеннән ничек итеп милләт югары күтәрелсен!? Үзләре мохтаҗ булган кешеләр ничек итеп милләт балаларын тәрбия итә алсын, мәктәп вә мөгаллимнәр асрарга куллары күтәрелсен?!

• Әхлак төзек булмаса, адәм баласының рухы сәламәт булмас, әхлак кануннарына буйсынмаган кеше инсан исемен күтәрергә хаклы булмас.

• Бездә диндарлык дәгъвасы бик очсыз. Бик күп кешеләр коры диндарлык дәгъвасы кылалар вә мөселманнарның күтәрелүләре, сәгадәтләре өчен аз гына да иҗтиһад сарыф итмиләр вә юлбашчылык кылмыйлар. Асылда, мондый кешеләр ислам дошманнарына хезмәт итмәктәләрдер. Диндарлык исеме белән дингә хыянәт итүче халыклар – шушылардыр. Болар үзләренең ахирәт кешеләре икәнлекләрен дәгъва итәләр, әмма үзләренең бөтен арзулары вә бөтен әмәлләре – дөньядыр. Болар дөньяны, бер генә сәгатькә булсын, күңелләреннән чыгарып тора алмыйлар.

• Ислам дине ялкаулыкны вә тик ятуны кабул кыла торган дин түгел.

• Фәкыйрьлек килү белән дин дә зәгыйфьләнер. Мохтаҗлыкта калган кешенең ихлас белән гыйбадәт кылуы мөмкин түгел.

• Инсан өчен кул һөнәре вә игенчелек кенә җитми, бәлки җирдә булган байлык вә хәзинәләрдән файдаланырга тиешле.

• Сәгадәт – ялкаулык катышмаган хәлдә канәгатьле вә риза булудан, сәгадәтсезлек – ач күзле булудан гыйбарәттер.

• Акча алу нияте белән Коръән уку вә Коръән укыту нияте белән акча бирү Рәсүлулла (с.г.в.) вә аның сәхәбәләре заманында булганы юк һәм моңа хаҗәт тә юк. Мөселманнарның һәрбере «Фатиха» вә «Колһуаллаһ» сүрәләрен беләләр, бик күпләре мәгънәләрен дә аңлыйлар. Кешегә кушып Коръән хәтем иттерүгә караганда, һәркемнең үзе ихлас белән «Фатиха» вә «Колһуаллаһ» сүрәсен укып, Аллаһы Тәгаләгә түбәнчелек вә бәндәчелек күрсәтүе яхшырак. ■

ӘЛМӘТ ТЕАТРЫНЫҢ АСЫЛТАШЫ

Рәдиф Сәгъди

Әлеге артистның иҗатына тукталсам, аның турында язып та, сөйләп тә бетерә алмам кебек. Олуг талант, фидакарь шәхес, кабатланмас сәнгатькәр! Илле яшендә унсигез яшьлек чибәр кызларны, яшь чагында исә өлкән яшьтәге аналарны, әбиләрне уйнап, театр белгечләрен, тамашачыларны гомере буе сокландырган югары дәрәҗәле артистлар кавеменнән ул. Шул ук вакытта, Луиза Солтанованың татар театры сәхнәсендәге хезмәтен ире – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Камил абый Вәлиевтән башка күз алдына китерә алмыйм.

Гомерләренең зур өлеше гастрольләрдә үтте... Җырдагы кебек: юллар, юллар... Озын-озак сазлы-бозлы авыл юллары! Яңгырлы-карлы һава шартлары... Иң читене, әлбәттә, ике улларын – сабыйларын айдан-айга туганнарына, дус-ишләренә калдырып китүләр. Сабыйларга ата-ана назының һәм тәрбиясенең иң кирәк чоры. Шул хәлгә йөрәкләре әрнегән артист халкы, мөмкинлек тудымы, нарасыйларын үзләре белән гастрольләргә алып чыгарга тырыша. Ул өстәмә авырлык өстәсә дә, янында кадерлеләрең булу күңел тынычлыгы китерә. Кулыңа алып чөясең, нәни кулларыннан, алсу битләреннән үбәсең, сөясең-назлыйсың! Уллары Айдар белән Айнурны да Луиза ханым белән Камил ага бөтен көчләрен биреп тәрбияләргә, үзләре белән күбрәк йөртергә тырышты, ягъни гаилә тормышы белән хезмәт юллары гел бергә барды. Тора-бара икесе дә әйдәп баручы актерларга әйләнде, зур танылу алды! Мәшһүр режиссерыбыз, СССРның халык артисты Марсель Сәлимҗанов К.Вәлиев, Л.Солтанова, Д.Кузаеваны юкка гына үз заманында башкалабызның данлыклы Г.Камал исемендәге театрына чакырып ятмагандыр. Әле әйтелеп үткән шәхесләр Россиянең теләсә кайсы театр сәхнәсен бизи алырлык драма актерлары, чөнки аларның, табигатьтән бирелгән талантларыннан гайре, югары актерлык осталыгына өйрәткән мәктәпләре дә бар! Ә менә аларның мөгаллим-остазлары кем икән? Кайсы җирлектән үсеп чыгып, шундый югары осталыкка ирешә алдылар һәм моңа нәрсә этәргеч биргән? Миңа калса, табигатьнең матурлыгына сокланып үскән, тирә-юнендәге кешеләрнең борчу-кайгыларына көенә, шатлыкларына сөенә белгән нечкә күңелле адәм балаларыннан гына затлы иҗатчылар чыга ала. Ваемсыз, битараф затлар сәнгатьтә төпләнә алмый, чөнки тоемлау чамалы була андыйларда!

Луиза Миргазиян кызы 1944 елның 18 гыйнварында Азнакай районының кечкенә генә Банки-Сукаеш авылында дөньяга килә. Афәтле сугыш дәвам иткән, ачлык-мохтаҗлык чиктән ашкан кырык дүртенче ел! Черек бәрәңге, алабута, какы, балтырган, кыр суганнарын җыеп җан асрарга тырышкан игелексез чорлар. «Дөньяны тоя, аңлый башлаганда, абый-апаларыма ияреп, колхоз кырында калган вак бәрәңге чүпләргә төнлә йөри идек! Әнкәй шуннан «кәлҗемә-боламык» пешереп бирә. Нинди генә үлән шулпалары татырга туры килмәде ул чорда. Өлкән туганнарым, урман-кырлардан нәрсә табалар – шуны җыеп кайта торган иде. Ул чакта нәрсә генә табып ашасак та экологик яктан чиста булган шул, шуңа безнең барыбызны да саклап калгандыр инде. Сугыш башланып, авылыбыз Банки-Сукаештан ир-атлар яу кырына китеп беткәч, сабыйлар тумаган. 1944 елны мин бөтен авылыбызга берүзем дөньяга килгәнмен, шуңа күрә, башлангыч мәктәбебез дә ябылган. Шул сәбәпле миңа, өч чакрым йөреп, Зур Сукаешка йөреп укырга туры килде!» – дип искә ала Луиза ханым.

1944 елны каты яралар алып комиссовать ителгән әтиләре Миргазиян ага кайтып төшә. Сәламәтлеге искитмәле булмаса да, сугыш инвалиды башта колхоз бухгалтериясендә, аннан бригадир, соңрак май заводы директоры булып эшли. Әтиләренең исән кайта алуы чиксез шатлык китерсә дә, тормыш шартлары әллә ни үзгәрми. Туйганчы ашау озак елларга хыял булып кала. Зәңгәр күзле, орчык хәтле генә чандыр кызга, мәктәп букчасын күтәреп, өч чакрым бер якка, аннан кире авылларына тәпиләргә туры килә. Күз ачып булмаслык кышкы буранда җил аяктан егардай булып искәндә, язгы-көзге яңгырлар үтәр юлларны сазлыкка әйләндергәндә дә, өстенә коеп яңгыр яуганда да бернигә дә карамыйча тешен кысып атлый да атлый ул. Югыйсә, орчык хәтле генә диярлек бер кыз! Шунысы куанычлы, Зур Сукаеш урта мәктәбендә татар мәгърифәте, татар мәдәнияте кайнап тора бу чорда. Биредә милләтенең гореф-гадәтләрен, сәнгатен, телен, иҗатын сөйгән алдынгы мөгаллимнәр белем бирә. «Әлфия апа Бакирова татар теленә, әдәбиятына, аның әдипләренә, алар иҗатына гашыйк итә алса, Ләлә апа исә эстетик тәрбия бирде! – дип сагынып искә

Г.Мөсрепов «Козы-Көрпеш һәм Баянсылу». Режиссер Г.Хөсәенов. Козы – Камил Вәлиев, Баян – Л.Солтанова

ала ул үзенең кадерле мөгаллимнәрен. – Алар чын мәгънәсендә Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән остазларыбыз иде!»

Кыз мәктәптәге укытучыларыннан ишетеп белгән Галиябану, Зөһрә, Нәфисә, Сөембикәләр язмышы өчен борчыла, уйлана, үзен дә алар урынына куеп карый. Тиз тәэсирләнүчән бала буларак, каһарманнарның язмышын үзенең нәни йөрәге аша үткәрә ул. Ун ел буена бара-кайта юл йөргәндәниләр генә уйлап бетермәгәндер инде Луиза. «Бер елны бәрәңге бакчабыз артындагы кырга колхоз кукуруз утыртты. Ул күзгә таба ерып чыгып булмастай куркыныч караурмандай тоела башлады. Аның араларында аю-бүреләр, әллә нинди әкияти куркыныч затлар бар кебек тоела, шуннан узу котны ала. Кукуруз арасындагы юлны үтеп мәктәпкә бару ярты җанны ашый башлады. Әнкәй көн дә озата чыга: «Бар, бар, кызым, курыкма, бар, карап торам!» – дип тынычландыра. Мин бар көчемә шул шомлы араны тизрәк йөгереп үтәргә тырышам! Кайбер чакта абый-апаларым озата, кайчагында авылдаш-юлдашларга да ияртеп җибәрәләр.

Мәктәп чорында кайбер атналарда безнең авылга да килеп, клубта кино күрсәтәләр иде. Шундый көннәрнең берсендә «Таһир белән Зөһрә» дигән әсәрне күрсәттеләр. Ул күренешләрдән алган тәэсир-кичерешләремне берүзем генә беләм. Шуннан соң бәрәңге бакчабыздагы ызанга чыгып, шулар булып уйныйм, елап бетәм!» – дип истәлекләрен яңарта Луиза Миргазиян кызы. Әле бу чорларда ул кайчан да булса гүзәл Зөһрәне уйнап дан казаначагын уена да кертмәгәндер. «Кая инде ул безгә – кечкенә генә Сукаештан чыккан гади авыл кызына!» – дип, хыялларын чикләгәндер. Минем үземә дә Луиза апаның Зөһрәсен күреп таң калырга туры килде! Ул сәхнәдә чакта ниндидер илаһилык, тылсым бөркелә иде тамашачыга, чөнки Луиза Солтанова уйнамый, ә Зөһрә тормышы белән яши, аның кичерешләрен йөрәге аша үткәреп, образын тудыра. Миңа да, чирләп киткән актер урынына кереп, икенче пландагы рольне башкарырга туры килгәләгән иде. Луиза апа белән беренче тапкыр уйнаган ролем

А.Гыйләҗев «Әткәй җырлый да, җылый да». Режиссер Г.Хөсәенов. Мәдәния – Л.Солтанова, Гайсә – Зәкәрия Гыйлемханов

шул дип йөри идем, юк икән! Күренекле актриса бу мәсьәләгә дә ачыклык кертте: «Син аңа хәтле В.Черныхның «Кулда власть булгач!» дигән драмасында минем егетне уйнаган идең!» – дип, хәтеремне яңартты. Ә «Таһир белән Зөһрә»дәге персонажымны хәзер хәтерләмим инде, шуны уйнап чыкканда, мөкиббән китеп, читтән генә Луиза апаны – Зөһрәне күзәтәм! Үзенең тәҗрибәле партнерлары белән тылсым тудырганына сокланам. Ә тамашачыларыбыз инде күптән кайда утырганлыкларын да оныткан-нар... борчылып, актерлар белән бергә яшәп, ихтыярсыз рәвештә яшь түгәләр. Менә, ниһаять, әкияти мәхәббәт фаҗигасе тәмам. Аптырашка калдырып, тамаша залында тирән тынлык урнаша. Гаҗәп! Халык тылсым тәэсиреннән чыга алмыйча гына утыра икән. Күпмедер вакыттан соң спектакль караучылар үз дөньяларына кайта башла-дылар. Көчле алкышлар мәдәният сараен тетрәтте. Менә ул чын сәнгатьнең сихри көче! Бүгенге көндә: «Бу әсәрне ошбу сәнгать югарылыгында тагын кайсы театр куя алды икән?» – дигән сорау туа. Юктыр, мөгаен! Хәлбуки, миңа шундый затлысын бүтән күрергә туры килмәде. Бу спектакльне шул югарылыкта үзенең шәкертләре К.Вәлиев, Л.Солтанова, С.Гайнетдинов, Г.Җамалиева, Р.Салихова, Д.Кузаева, Ф.За-рипов, Р.Ихсанова һәм башка иҗатчылар белән бөек режиссер-педагог Гали ага Хөсәенов кына куя алды. Урысчалатып әйтсәк: «Выше сверх того!».

...Ләкин әлеге югарылыкка җиткәнче, озын-озак, хәерче-мохтаҗ, бормалы-сырма-лы гомер юллары үтәсе бар иде әле Луиза туташка.

Урта мәктәпне тәмамлауга, зур гаиләдә үскән кыз алдына һөнәр алып, акчалы эшкә урнашу, рәтле-башлы киенү, адәмчә тамак ялгау, хәлдән килсә, тагын әти-әнигә дә булышырмын дигән мәсьәләләр беренче планга килеп баса. Колхозда калсаң, бу турыда уйларга да кирәкми: эшләгәнең ашарыңа да җитмәячәк. Луиза, берничә иптәш кызы белән, Лениногорскидагы һөнәр училищесына буяучы-сылаучы эшенә өйрәнергә укырга керә. Ләкин биредә дә, ни кызганыч, яшәү шартлары да мескен-неке, хезмәт хаклары да бик түбән булып чыга. Югалтыр нәрсәләре булмагач, ул,

иптәш кызларына ияреп, 1960 нчы еллар башында Чаллыга күчеп китә. Бу җирлектә күңеллерәк булса да, төзүчеләргә биредә дә начар түлиләр. Ә бит унҗиде яшен тутырып килгән кызның, матур киенеп, концерт-театрларга да йөрисе килә, шунда күңеле тарта! Дөнья күргән апалар Әлмәтне мактыйлар. Һәм менә яңадан күченү. Биредән туган авылына да якын, тормыш шартлары да чагыштырмача яхшырак! «Иң беренче хезмәт хакыма чүпрәк босоножка – җәйге аяк киеме алып кидем, өстенә хәтта күннән кисеп чәчәкләр дә ябыштырылган, шатлыгым эчемә сыймый, беренче тапкыр үзем эшләп тапкан мал бит! Шуны уртаклашырга, дип, әнкәйгә хат язып салам», – дип, шул вакытларны искә ала ул.

Ләкин, ни генә булмасын, төзелеш эшләре аның рухына, уй-хыялларына туры килмәгәнлеген тоя Луиза. Авыл, мәктәп сәхнәләрендә, хәтта башкалабыз Казан каласында да җырлап кайткан кызга, шул чагында бәхетлерәк булсын өчен, иҗат җитми. Күңелендәге нияте аны, куркуын-шикләнүен җиңәргә мәҗбүр итеп, ул вакытларда гөрләп эшләп торган Горький исемендәге мәдәният сараена китерә. Торабара һәвәскәр артистлар арасына кереп китеп, концертларда чыгыш ясый башлый ул. Әлмәт театрының элеккеге профессиональ артистлары Мөнирә Шәйхетдинова белән Шакир Габдрахмановлар, аның сәләтен күреп алып, кызга чат ябышалар – спектакль уйнарга үгетлиләр. Чөнки бу чагында Шакир ага – халык театрының режиссеры да, җитәкчесе дә һәм Луизага беренче тапкырыннан ук Галиябану ролен уйнарга насыйп була. Буй җитмәс тоелган сәнгатъ дөньясына кереп киткәндә юл башы булып чыга ул. Әнә шул Галиябану роле төптән үзгәртә дә куя сылу гәүдәле яшь кызның язмышын. Спектакльләрнең берсен Әлмәт дәүләт театрының администраторы Закир ага Мөҗипов караган була. Ул, кайтып, талантлы Луиза Солтанова хакында иҗат коллективының директорына җиткерә. Фатыйх Үтәев, эшлекле, тимерне кызуында сугарга өйрәнгән җитәкче буларак, Солтанованы шундук эзләп таба. Яңа гына нефть техникумына әзерлек курсларына кергән кыз аптырап-югалып кала. Сәбәбе дә җитди: күңеле сәнгатькә тартса да, нефтьчеләр кавеме башка хезмәт ияләре белән чагыштырганда иркенрәк тә, мулрак та яши. Фатир-торак яклары да анда тизрәк хәл ителә. Ләкин серле, могҗизалы театр тормышы да ымсындыра бит! Ул ниндидер күзгә күренмәгән көче белән үзенә тарта! Луиза шулай гасабиланып йөргәндә, хәлиткеч адымга этәргән чара була. «Миңа профессиональ артистлар Диләрә Хисаметдинова белән Рамазан Ихсановларның юбилей кичәләрен М.Горький исемендәге клубта карарга туры килде. Мондый тантанада беренче генә тапкыр булуымнанмы, аларга җиткерелгән матур-төче сүзләр, хөрмәтләүләргә исем китте. Бу кичә тамашачыларның да көчле алкышларына күмелеп барды. Менә, ичмасам, эш икән бу, дим! Авызлары бал-майда, көннәре кадер-хөрмәттә үтә икән бит! Һәм, шулай итеп, сәнгать юлына кереп кителде инде. Ләкин чынбарлык бик күпкә түбәнрәк булып чыкты. Эшкә урнашырга дип эзләп килсәм, Әлмәт дәүләт театрының конторы элеккеге башкарма комитетның кечкенә генә бүлмәсенә сыешкан икән! Гаҗәпләнүем артканнан-арта бара. Өстәвенә, репетицияләре дә кайда эләкте шунда, әйтик, сәхнә буш булса, Горький клубында, булмаса, тегенең-моның фатирында үтә икән! Шундук күңел кайтса да, әлеге тарафка хәлиткеч адым ясаган идем инде!» – дип, истәлекләрен хәтердә яңарта Луиза ханым.

Театр дөньясы бик четерекле, катлаулы организм ул! Яңа килүчеләрне биредә өнәп тә бетермиләр, төрлечә сыныйлар, кырын караучылар, кимсетүчеләр дә табыла. Баштарак үсмер Луизага да баласытып, ышанмыйчарак карыйлар, иялəшə торсын, дип, икенче вазыйфаларны үтәүне тапшыралар: костюм үтүкләүче, реквизитор да, кирәк чакта музыка бирүче дә, хәтта пәрдә ачып-ябучы да... Әйтеп киткәнемчә,

Т.Миңнуллин «Исәнмесез». Режиссер Ф.Ибраһимов. Разия – Л.Солтанова

эш вакытында труппа, бер организм кебек, бердәм эш итә. Берәрсе чирләп китсә, йә бүтән сәбәпләр аркасында эшкә чыга алмаса, шундук алмаш кирәк була. Андый хәлләр, сирәк булса да, гастрольләрдә килеп чыккалый. Шул сәбәпле, әлегә кием-салым үтүкләп кенә йөргән, сәхнәгә чыгарга хыялланган Луизага да форсат туа. Чирләп киткән Ләлә Садыйкованы алмаштырып, «Тау чәчәге»ндә – Сафия ролен (авторы – Г.Уразиков), «Балыкчы кызы»нда, Рәшидә Җиһаншина урынына, Рәинә ролен башкара. Кайбер артистлар яшь иҗатчыны сынап карар өчен дә махсус сәбәп табалар. Х.Сәлимҗановның «Ил атасы» әсәре белән авылларда йөргәндә Зәкия Туишеваны чир зәхмәте суга. Аның урынына Зөммәрәне уйнаганын шыпырт кына залдан күзәтеп утыра да, соңыннан ролен яшь кызга бөтенләйгә тапшыра Зәкия Туишева. Мондый гына очраклы хәлләр зур сәнгатькә, иҗатка омтылган Луизаны канәгатьләндерми, әлбәттә. Ул түземсезлек белән үз сәгате сукканын көтә. Ә сабырлыкка килгәндә, аның белән бер спектакльләрдә уйнаган кеше буларак, шуны гына әйтә алам: ун кешегә җитәрлек чыдамлык, түземлек бар Луиза ханымда! Менә, ниһаять, ул көннең дә алсу таңы ата. 1962 елны Г.Хөснуллинның «Зур туй» комедиясендә аңа Гөлчәчәк ролен тапшыралар. Үзенә генә хас тырышлык, үҗәтлек белән, беренче профессиональ эшенә җиң сызганып алына ул. Тамашачы алдына тәүге тапкыр мөстәкыйль рәвештә чыгып, аның игътибарын җәлеп итәргә ниятли. Ни кызганыч, драматургиясе сыек булган әлеге әсәр, уңыш китерми, репертуардан төшеп кала. Үзенең бернинди гаебе булмаса да, бик авыр кичерә ул бу хәлне. Тик ни генә булмасын, әлеге роле белән олуг иҗатка юл яра ул. Тәгәри китте йомгагым, дигәндәй, 1963 елны Сәет Кальметовның «Тамгалы йорт»ында – Илгизә, 1964 елны Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар» драмасында Гөлчирә белән күренеп, халык теленә керә башлый. Мирхәйдәр Фәйзинең 1963 елда куелган «Ак калфак» дигән затлы пьесасында, ниһаять, аңа да үзен танытырга мөмкинлек туа. Яшь актрисага Хәмдия роле тапшырыла. Мәгъруր һәм иркә морза кызы образын бөтен күңелен, тырышлыгын салып иҗат итә ул. Әлмәт театр студиясендә белем алучы шәкертләргә диплом эше рәвешендә куелган бу спектакльне тамашачы бик җылы кабул итә. Үзенең иҗаты өчен борчылып йөргән Луизага да ышаныч китерә әлеге әсәр. Халык күңеленә аерата хуш килеп, алкышларга лаек була яшь башкаручы. Шул ук вакытта сәнгатькәрләр, язучылар күзлегеннән дә читтә калмый аның уены. «Луиза-Хәмдиянең бер кул оруы егет белән кызның мөнәсәбәтендәге фаҗигане ачып бирә. Очып барганда дертләп туктап калган кошны хәтерләткән сы-

Г.Хаҗибәков «Аршин мал алан». Режиссер Р.Әюпов. Җиһан – Л.Солтанова, Гаскәр – А.Шаһимәрдәнов

мак... Аның уенында алиһәлек, әрнү, үкенү... һәм кемгәдер нәләт тә...» – дип яза гомере буе Луизаның артистлык осталыгын эталонга санап яшәгән күренекле шагыйрә Саҗидә Сөләйманова («Азат хатын», май, 1977 ел).

Әлбәттә, иң башта актерлар иҗатында беренчел рольне режиссер-педагоглар уйный. Әһәмияткә ия бер факт: Луиза Солтанованың профессиональ актриса булып җитешә башлавында театр студиясе җитәкчесе дә булган режиссер Йосыповның да өлеше зур. Беренче белемне, сәхнә серләренә төшенүнең беренче адымнарын нәкъ менә Габдулла ага ясата аларга. А.Гыйләҗевнең Йосыпов куюындагы «Яланаяклы кыз» әсәре аңа танылу алып килә дә инде. Режиссер әлеге спектакльдә яшь кызның актерлык мөмкинлекләрен ача, амплуасын билгели. Гөләндәм ролендәге Луиза халык алдына хыялый лирик хисләргә бай каһарман буларак килеп баса, ул ошбу образы, сәхнә сөйкемлелеге белән тамашачыларның күңелен шулкадәр яулый ки, соңыннан инде аны «яланаяклы кыз» дип кенә йөртә башлыйлар. Әлеге роле белән халык күңеленә тирән уелып кала ул. Авылларга спектакль килсә: «Теге «яланяклы кыз» килдеме, ул да уйныймы?» – дип кызыксыналар. Бу әсәр белән зурдан кубып танылганнан соң, аңа инде теләсә нинди рольне дә ышанып тапшыра башлыйлар. Луиза үзенең остазларының өметләрен көткәннән дә ныграк аклый.

Ул: «Бермәлне өлкән актриса Камилә апа белән квартирга йөрибез. Администратор килеп, колхозның икешәр тавык биргәнлеген, шуны барып хәзер үк алырга кирәклеген хәбәр итте. Камилә апа: «Луиза сеңлем, минекен дә берьюлы алып кайт инде!» – дип озатып калды. Кайтсам, кем суйды соң, дип сорый. Керәшен Борисы, дим. Камилә апа җәт кенә киенде дә, икәүләшеп кире чабабыз. Килеп җитүгә: «Борис, ничек суйдың соң?» – дип бәйләнә башлады бу. «Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр! – дип эш кылдым инде», – дигән җавапны ишеткәч кенә тынычланып борылып кайтып китте. Кабарынкы ана күркәгә ияргән бәбкә кебек, артыннан мин дә атлыйм!» – дип искә ала яшьлек елларын.

Ләкин яшьлек тә, еллар да, бер урында тормый, туктатып булмаслык рәвештә алга

чаба. Аларга ияреп, иҗат иткән рольләре дә арта бара. «Көзге ачы җилләрдә» әсәрендә – Гәндәлиф (1965 ел), «Зөбәйдә – адәм баласы»нда – Сәрия (1966 ел), «Зәңгәр шәл»дә – Мәйсәрә (1966 ел), Л.Леоновның 1967 елда куелган «Фаҗига» әсәрендә – Ольга (сәхнәгә куючысы – С.Өметбаев), И.Эвольдның «Батыр йөрәклеләр»ендә – Соня (1967 ел), М.Горькийның «Васса Железнова»сында – Рошель (1968), Ә.Атнабаевның шул ук елны сәхнәләштерелгән «Адашкан йолдыз»ында Сафия образлары аның биографиясен бизәп тора.

Ләкин Луиза Солтанованың иҗат юлын гаҗәеп талантлы Камил Вәлиевнекенә бәйләп күрсәтмәсәм, әйтеп киткәнемчә, зур хилафлык булыр иде. Ике яшь артист 1965 елны куелган «Утлар яна учакта» дигән спектакльдә (авторы – Г.Ахунов) партнерлар буларак кавышалар. Луиза Солтанова белән Камил Вәлиевләр – сәхнәдә бер-берсен өзелеп сөйгән ярлар. Яратышу, кочаклашу-үбешү, туйлар үткәрү, аңлашылмаучылыклар – барысы да бар биредә. Пьеса драматургия ягыннан «социалистик реализм» ягына басым ясап язылса да, ике яшь, матур артистның уены тамашачылар күңелендә җылы хис калдыра. Шулай итеп, Әлмәт дәүләт театрында да гашыйк геройларны уйнарлык талантлар пәйда булганлыгы ачыклана. Камил белән Луиза һәрвакыт диярлек төп рольләрдә хәзер. «Җирән чәч»тә – Гүзәл һәм Булат, (авторы – М.Садыйкова); «Бай һәм хезмәтче»дә – Гафур белән Җәмилә (авторы Х.Ниязи); «Чаткылар»да – Гаяз һәм Маһисәрвәр (Т.Гыйззәт), Г.Мөсрепов әсәрендә Козы-Көрпеш һәм Баянсылу рольләре нефть чыккан якларда гына түгел, Татарстан киңлекләрендә дә танылу китерә. Озак та үтми, Казаннан үз эшенең фанатигы Гали ага Хөсәеновның баш режиссер булып килеп төшүе иҗат ягыннан колективка зур сикереш, этәргеч бирә, яңа мөмкинлекләр тудыра. Театрның яңа эрасы – алтын чоры башлана. Гали ага театр училищесында да институтлар да бирә алмаган осталыкка өйрәтә актерлар составын. Әлеге сәбәпле, 1981 елның мартында Гали Кәримович исән чагында осталыгыбызны чарларга хыялланган, яңа гына театр училищесын тәмамлаган бер төркем яшьләр (Коля Юкачев, Раушания Юкачева, Рәис Галиев, Рәдиф Сәгъди һәм башкалар) үз теләгебез белән Әлмәт дәүләт театрына китеп бардык. Шул чорда миңа Луиза апа, Камил абый белән бергә тагын бер әсәрдә – «Әткәй җылый да, җырлый да» дигән спектакльдә (авторы – Аяз Гыйләҗев) агроном Сөнгатьне уйнарга туры килде. Луиза Солтанова әле күптән түгел генә «Таһир белән Зөһрә»дә Зөһрәне уйнап сокландырган булса, бу әсәрдә инде ул бала кайгысыннан чәчләренә чал йөгергән ана ролен башкарды. Әсәрдәге каһарманнарның берсен Камил ага уйный һәм ул финалда мәкерле рәвештә үтерелә. Ләкин халыкның тетрәнеп елавы, кайберләрен ашыгыч ярдәм күрсәтү машиналары белән алып китүләр ешайгач, Гали ага Хөсәенов төп геройны автор белән телефоннан сөйләшеп, каһарманны исән кала торган итеп үзгәрттерә. Тамашачы спектакль беткәннән соң да артистларны сәхнәдән чыгармыйча унар, егермешәр минут алкышлый. Уенчылар кабат-кабат баш ияләр. Шулар арасында яңа гына профессиональ сәхнәгә аяк баскан мин дә бар! Үзем эчемнән генә: «Шундый яхшы спектакльгә тәҗрибәм чамалы булу сәбәпле хилафлык китермәдемме икән? – дип борчылам. Төп рольне уйнаган остазым Дамирә Кузаева: «Үзеңне тагын да кыюрак, тәвәккәлрәк тот!» – дип, киңәшләрен бирә. Луиза апаның исә: «Молодец, булдырдың!» – диюеннән күңел күтәрелә. «Димәк, салып таптарлык булмаган икән!» – дип уйлыйм. Камил ага да: «Ничего-ничего, энекәш, болай булгач була инде ул!» – ди. Чөнки бу рольне уйнаган кеше театрдан китү сәбәпле, ике-өч көн генә репетиция ясап рольгә кергән яшь иптәш кенә әле мин. Талантлары ташып торган иҗатчылар белән уйнау оешып җитмәгәнлегемне күрергә мөмкинлек тә бирмәгәндер тамашачыга! Чөнки тирә-ягымда, терәк булып, даһи Гали

Л.Солтанова, К.Вәлиев «Намус һәм тугрылык» номинациясендә «Тантана- 2016» республика премиясе лауреатлары

Кәримовичның олпат шәкертләре уйный. Чыннан да җитмешенче елларда коллективка баш режиссер итеп билгеләнгән шәхес татар театр дөньясын шаккаттыра-шаулата башлады. Сәбәбе – иҗади үсеш төп юнәлеш итеп билгеләнә, рольне – актер җаны, актер йөрәге аша үткәреп, сәхнәдә яшәү таләп ителә. Күренекле остаз бөтен көчен, бар белемен шәкертләренә бирергә тырышып хезмәт куя. Әлмәт театры әлеге елларда нефть чыккан төбәкләрдә генә түгел, Казан, Уфа кебек зур калаларда да, бу җирлекләрдәге авыл һәм шәһәрләрдә дә сагынып көтеп алынган иҗат коллективы иде.

«Луиза Солтанова татар театрының нәфислек алиһәсе диясе килә. Ул – Әлмәт театрының иң могтәбәр, олы абруйга ия булган актрисасыдыр, якты яшел төстәге асылташы – фирүзәседер. Аның уенына моңсу яктылык хисе, шигъри югарылыкка омтылу хас!» – дип язып калдырган күренекле тәнкыйтьче, театр белгече Дания апа Гыймранова үзенең «Мәдәни җомга» газетасының 1998 елның 25 сентябрендә чыккан санында.

«Якты яшел төстәге фирүзә!» Яшәү төсе, яшәү символы! Луиза апа да бөек остазларының эшен Камил ага белән берлектә дәвам итте. Бу шәхесләр сәхнәдә кыланып уйнамадылар, ә геройларының тормышы белән яшәделәр. Аллага шөкер, алар әле бүгенге көндә дә арабызда! Мин бу олуг шәхесләр белән эшләп калуыма горурланып яшим.

(Истәлек «Әлмәт татар дәүләт драма театрына 50 ел!» дигән китаптан (1994 ел) файдаланып язылды).

РЕДАКЦИЯДӘН: *Луиза Миргазиян кызы Солтанованың гыйнвар аенда гомер бәйрәме. Аны шул уңайдан ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек белән хәерле озын гомер телибез!* ■

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ АСЫЛ ЗАТЫ

Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге коллективы Марсель Хәернас улы Бакировны олы бәйрәме – сиксән биш яшьлек юбилее белән ихлас тәбрик итә!

Күренекле галим, педагог буларак, Марсель Хәернас улы, киңкырлы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, профессор, филология фәннәре докторы, күренекле фән эшлеклесе, Россия Гуманитар фәннәр академиясенең академигы, Россия Федерациясенең югары профессиональ белем бирү өлкәсенең мактаулы хезмәткәре дәрәҗәсенә лаек була. Ул озак еллар буе, Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультеты мөгаллиме буларак, Татарстанда мәгариф һәм фәнне үстерүгә мөһим өлешен кертә. 2018 елның 10 декабрендә 85 яшьлек зур юбилеен билгеләп үткән аксакал галим гомеренең алты дистә елдан артыграк өлеше чын мәгънәсендә фидакарь фәнни-педагогик эшчәнлектән гыйбарәт.

Казан (Идел буе) федераль университетында педагогик һәм фәнни эшчәнлек алып бару белән беррәттән, Марсель Хәернас улы Бакиров инде гомеренең 27 елдан артык өлешен Татар фольклорын җыю, саклау, өйрәнү һәм пропагандалау үзәгенә, хәзерге Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәгенә багышлый. Биредә ул татар халкының традицион мәдәниятен өйрәнү һәм популярлаштыру өлкәсендә киңкырлы эшчәнлек алып бара. Күренекле галим татар фольклористикасы тарихында, халкыбыз иҗатын, төрки-татар шигърияте тирәнтен өйрәнгән олпат галим буларак, үз урынын яулый. Аның фәнни җитәкчелегендә фән кандидатлары, филология фәннәре докторлары һәм профессорлар гыйлем дөньясына юл ала. Искиткеч кешелекле, мәрхәмәтле, олы йөрәкле, шул ук вакытта нәфис сүз серләренә төшенгән остаз буларак, ул хезмәттәшләре, укучылары һәм республика җәмәгатьчелегенең хөрмәтен казана.

Марсель Хәернас улына чын күңелдән озын гомер, нык сәламәтлек, иҗат уңышлары, күңел күтәренкелеге, бәхетле һәм шатлыклы көннәр телибез!

Фәнзилә Җәүһәрова,
Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге директоры,
ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, филология фәннәре кандидаты ■

Җәнҗал агачы

Айдарбәк Сарманбәтов

Язучы, тәрҗемәче һәм журналист Айдарбәк Имангази улы Сарманбәтов 1953 елның 8 июнендә Кыргызстанның Ыссык Күл районында туа.

26 әдәби китап авторы. Ул тәрҗемә иткән әсәрләрдән торган 100дән артык китап дөнья күргән.

Әсәрләре Төркиядә һәм Кытайда да китап булып нәшер ителгән.

Әдип – Төркиянең «Мәхмүт Кашгари» (2008, 2012 еллар), Казакъстанның «Мәңгелек дуслык» (2010 ел), Кыргызстанның күп санлы премияләре лауреаты.

Айдарбәк Сарманбәтов бүгенге көндә «Литература тюркского мира» әдәби журналының баш мөхәррире һәм Халыкара поэзия иҗтимагый академиясенең гендиректоры вазыйфаларын башкара.

Редакциядән

– Бабай! Безнең агачны кисәләр! Теге... кем... Әхмәт кисә! Мышкылдап килеп кергән онык, көтмәгәндә, бөтен өйне аякка бастырды. Залның илтер-бәрән тиресе салынган түр өлешендә кырын яткан килеш кенә китап укыган Биктәр карт малайның өзек-өтек сүзләреннән берни аңламады, шуңа күрә аптыраулы карашын оныгына төбәде:

– Ни турында сөйлисең син? Кем?.. Нинди агач? – Ул, сизелер дәрәҗәдә борчылып, башын күтәрә төште.

– Теге... уртадагысы...

Нindidер күңелсезлек булганын сиземләгән Биктәр, китабын читкә куеп, көч-хәл белән генә торып басты һәм, итекләрен киеп, тышка чыкты.

Дөрес сиземләгән икән. Өйдә яткан чакта үзе дә урамда яңгыраган балта тавышын ишеткән иде. Бермәл, нинди тавыш килә соң, дип тыңлангандай да иткән иде. Бактың исә, моңарчы ике ишегалды арасындагы чик ролен үтәп торган корыган агачны күршеләре Әхмәт чабып маташа икән. Күр әле үзен, канәгать кыяфәттә, зур эш майтарырга җыенгандай, җиңнәрен сызганып, күлмәкчән басып тора. Җитмәсә, бәдбәхет, үзенең иске башлыгын якындагы алмагачның бер ботагына элеп куйган. Кәефе күтәренке, әйтерсең үз агачын чаба!..

– Кара син аны... Моның өчен бит... бабаларың... Ни эшлисең син, ахмак? – дип, Биктәр, җәһәт-җәһәт атлап, күршесенә якынлашты. Тегесе исә аңа бөтенләй игътибар бирмәде. Хәтта сыңар керфеге дә селкенмәде. Бәлки ул Биктәрнең сүзләрен ишетмәгәндер, чукрак, дисәң, хәтере калыр, колакка катырак, диләр бит үзен... Җитмәсә, нәкъ шул вакытта ишегалды янындагы олы юлдан бер-ике йөк машинасы бер-бер артлы гөрелдәп узды.

– Әй, саңгырау колак! Синнән сорыйм, нишләп кисәсең бу агачны? Рөхсәт-мазар сорап тору юк, мин сиңа әйтим!

Тураеп басып, агачка балтасы белән кизәнүе сәбәпле, Әхмәт күршесенә игътибар итмәде. Җен ачуы чыккан Биктәр бар көче белән аның җилкәсенә китереп сукты. Тегесе, мондый хәлне көтмәгәнгәдерме, бераз чайкалып торды да, бер якка янтаеп төште. Янтаеп кына төшү түгел, гөрселдәп ауды. Өйдән чыгар алдыннан гына ул ваклап кыздырылган ярмалардан әзерләнгән чүпрәсез салкын ачытманы шактый күп эчкән иде, шуңадырмы, Әхмәтнең кабарган бүксәсе быгыр-быгыр килеп алды, балтасы кулыннан ычкынды – ул, кулларын як-якка җәеп, аңсыз кеше кебек, җирдә таралып ята иде.

– Каравыл, үтерәләр! – Күрше ишегалдыннан хатын-кызның йөрәк өзгеч тавышы берничә мәртәбә кайтаваз булып яңгырады. – Үтерә бит ул аны, кабахәт! Ә, бәлки, үтергәндер дә инде!..

Коточкыч тавыш иясе – Әхмәтнең хатыны Зөһрә иде. Кара корым төсле калын тиреле, кыскасы, зәһәрнең дә зәһәре. Авылда аның кебек әрепләшерлек, аның белән талашырлык бүтән хатын заты юк. Менә ул, чәчәкле киң күлмәк итәген уңлы-суллы болгап, каз шикелле бер яктан икенче якка янтая-янтая, ир-атлар тарафына йөгерде.

Күршесенең «җиңелчә» орынуыннан яңа гына борын төртеп килгән чирәмле җиргә гөрселдәп ауган Әхмәт, әлегә берни аңламыйча һәм урыныннан тора алмыйча кырын яткан килеш, ачулы карашын Биктәргә төбәде. Картлык – картлык шул инде... Өстәвенә, аның корсагы да алагаем зур иде. Кырын яткан җиреннән аз гына калкына төшеп, чирәмгә таянып, Әхмәт еш-еш сулыш алды. Тирә-якка карады. Йөзе киеренкеләнде, берара җир төсенә кереп алгандай булды. Ул һаман да берни аңламый иде әле. Биктәр каян килеп чыкты да, кай арада ул, яман кычкырып, аны аяктан екты. Әхмәтнең менә шуңа отыры ачуы чыкты. Биктәр исә, үз чиратында, җиңелгән күршесен тотып ашардай булып, аңа ярсулы карашын ташлады. Әхмәт җирдән тора гына башлаган иде, Биктәр бөгелгән бармагы белән аның җилкәсенә каты гына төртеп алды да:

– Каһәр суксын синең бабаңнарны! Әйт әле, ни өчен син минем агачны кисәсең, ә?! Миңа хәбәр биреп, кисәткән булып, берәр сүз-фәлән әйткән булыр идең хет, ә?! Вчүтеки, бу агачның хуҗасы бит мин!.. Әйтерсең син утырткан аны... Тукта яхшы чакта! Бабаларың каберләрендә әйләнеп яткыры!..

Шул сүзләрен әйтеп, Биктәр кабат Әхмәтне төртеп аударды.

Ул гына да түгел, башын селки-селки кыргыйларча акырып, Биктәр көтмәгәндә күршесен янә аяктан екты, менә хәзер, балалар кебек, җилкәсенә суккалап, аны кабат агач янына җәеп салды; аның бу гамәле Әхмәтне чыгырыннан чыгарды.

– Сиңа миннән ни кирәк? Мин синең кәҗә сакалыңнан курыкмыйм!.. Әгәр мин сиңа өлкәннәргә хөрмәт белән караган кебек карыйм икән... нәрсә, бу үзеңне шулай тотарга кирәк дигән сүзме?! Ник син мине төртеп ектың?!. – Кызган хуттан ул күршесенә менә-менә ташланыр төсле иде. – Мин бит сиңа кагылмадым... Ә син үзеңне әллә кем урынына куеп...

Аның ачу китергеч кыланышы гадәттә тыныч холыклы һәм кешегә үч саклый белми торган Биктәр картны тагы да ярсытыбрак җибәрде.

– Бабаларыңны с-с-сагынасы! Нәрсә сөйлисең син? Корсакка узган кыз анасын куркытып маташамыни, кара син аны! Минем агачны кисүе җитмәгән, әле сүгенеп маташа, хәерсез! Нәрсә, мине ашыйсың киләме? Кара аны... – Биктәр, башына кан йөгерүдән һәм ярсудан, әйтәсе сүзләрен әйтеп бетермәс хәлгә килде, сөмсере элеккегә караганда да коела төште. Болай ул – салкын канлы кеше. Сирәк-мирәк кенә котыру чигенә килеп җитә. Ул чакта инде бик авырлык белән генә тынычлана. Ул шашынса, үлгәнче сугыша. Шул характерын белгәнгәдерме, дуслары аны үзе югында «контуженный» дип йөртә.

– Нәрсә инде бу, әкә!.. Ни кылануыгыз? – Әхмәтнең хатыны әрепләшүчеләр арасына кысылырга булды. – Чүт үтермәдегез бит аны! Безнең гаеп нидә? Ә бит без Сезгә нинди хөрмәт белән карый идек...

Ярсыган картлар Зөһрәнең сүзләренә бернинди игътибар бирмәде. Әхмәт Биктәрдән дүрт-биш яшькә кече иде. Өстәвенә, алар аталары ягыннан туган да тиеш әле. Шуңа күрә Зөһрә күршесенә әкә дип олылап дәште дә.

– ...Нишләп бу агачны кисәсең, дип сорыйм мин синнән?! – Биктәр имән бармагы белән Әхмәтнең маңгаена төртмәкче иде, тегесе башын борып өлгерде. Биктәр авыр хәрәкәтләнүчән, әмма көчле кеше иде. Аның имән бармагы, маңгайдан узып, күршенең баш түбәсенә килеп төртелде. Авыртуга чыдый алмыйча, Әхмәт кычкырып җибәрде:

– Ан-наңны... с-с-сатып җибәрәсе! – Гадәттә, ул гел шулай сүгенә. Әмма бу юлы аның әлеге сүзләре Биктәрнең күңеленә тиде. Ярасына кемдер тоз сипкәндәй хис итте ул үзен.

– Ни сөйлисең син? Аллаһ каргышы төшсен үзеңә!!! – Биктәр, адашкан пуляны тоткандай, урынында сикергәләп алды. – Ничек шулай әйтергә мөмкин, ә?! Син бит минем әниемнең кулыннан ризык алып үстең, ә үзең әлләниләр әйтәсең, бабаларың каберләрендә әйләнеп яткыры!.. – Биктәр, бөркет кебек, Әхмәтнең җилкәсеннән эләктереп алды һәм күршесен кинәт этеп җибәрде.

– Коткарыгыз! Үтерәләр!.. – Әхмәтнең хатыны, бөкшәйгән һәм ыңгырашкан ирен капларга тырышып, ачы тавыш белән кычкырып җибәрде. – Кеше-ләр! Котка-рыгыз!.. Үтерә-лә-әәр!

– Кара син аны, ә! Минем әнине искә төшергән була. Юньсез! Синең үзеңне кем тудырды? Анаңмы, фәләнме, хайван?!

Әхмәт, үзе дә сизмәстән, нинди ахмаклык эшләп ташлавын аңлады. Шуңадырмы, каушап калды хәтта. Ничек шундый сүзләр чыгып ычкынды соң аның авызыннан, шайтан алгыры?! Бер караганда, ул бу сүзләрне дусларына, балаларына карата әллә никадәр әйткәне булды, ә менә хәзерге хәл-халәттә бу бөтенләй кирәкмәс нәрсә иде. Менә шул сүгенү аркасында низаг-ызгыш отыры көчәйде.

Мәрхүмә әнисе мыскыл ителгәнгә кәефе аеруча киткән Биктәр, бөтен көчен җыеп,

Әхмәтнең күкрәгенә типмәкче булды. Тегесе исә баядан бирле, бөгәрләнеп, җирдә ята иде, ярый әле вакытында хатыны килеп өлгерде һәм ирен аяусыз һөҗүмнән коткарып калды. Ничек кенә коткарып калды әле! Әгәр кырык бишлене үк булмаса да, кырык дүртенче үлчәмле аяк киеме кигән ике метрлы, зур сөякле пәһлеванның итеге нәкъ кирәкле ноктага барып кадалсамы... Моның ахыры җүнле бетмәс иде. Кабыргалар сынмаса да...

Шулвакыт арага Биктәрнең ашыгып килеп җиткән хатыны керде. Ул җегәрле иде. Хатын, килә-килешкә, картының кулыннан эләктереп алды һәм аны өйләренә таба өстери башлады:

– Җитте, карт, булды!.. Үзеңнең абруеңны өлкәннәр һәм яшьләр алдында төшермә! Кешеләр ни әйтер!..

Кәефе кырылган карт, карчыгы белән килешмичә, һаман кайнарлануында булды:

– Аның кыланмышына түзәрлекмени, минем агачны кисүе җитмәгән, әнине мыскыл итеп маташа... Бабалары каберләрендә әйләнеп яткыры!.. Синең килеп кысылуың гына кирәк иде... Гарьлек! Кагылма агачка!

– Булды, карт, оял ичмасам... Килен ни әйтер, улыбыз ни дияр... Иртәгә адәм гыйбрәте итеп сөйләмәгәйләре...

– ...Нәрсә булды? Байтактан бирле әвәрә киләсез! Берәр күңелсез хәл килеп чыктымы әллә? – Кинәт яңгыраган тавышны ишетеп, бөтенесе дә койманың теге ягыннан күренгән, атка атланган Туктамәмбәт аксакалга таба борылды. Низаг аркасында беркем дә аксакалны һәм аның тирәсендә берөзлексез бөтерелгән җирән этне шәйләмәгән иде. Күрәсең, җирән эт хуҗасы урамнан ук тавышны ишетеп килгән һәм бирегә кереп чыгарга булган. – Тавышыгыз бөтен тирә-юньгә яңгырый. Берегездән-берегез уздырып кычкырышасыз... Берәр бәла-каза булмагандыр бит?..

Сирәк сакаллы, май сеңгән ак башлыклы Туктамәмбәт картны күргәч, Биктәрнең эченә җылы йөгерде: «Барысы турында да менә кемгә сөйләргә кирәк!» – дип уйлады ул.

– Шулай эшләргә мөмкинме инде? Нәсел-нәсәпсез менә бу кеше... Миннән рөхсәт сорамыйча агач кисүе җитмәгән, минем әнине мыскыл итеп маташа... Мин дә аның бабаларын тиешле урынга җибәрдем... Бу агачны минем әти утыртканын Сез бик яхшы хәтерлисез дип беләм... Сугыштан кайткач... – Биктәр бу юлы да: «Бабаларың каберләрендә әйләнеп ятсын!» – дип өстәмәкче иде, тукталып калды: «Мин аларны тиешле урынга җибәрдем», – дип кенә чикләнде. Йөзе агарган Әхмәтнең авызыннан бер сүз дә чыкмады. Аның каравы, хатыны котырына башлады:

– Ни сөйлисез, әкә, мин бит үз күзләрем белән күреп тордым: йөгереп тә килдегез, иремне бәреп тә ектыгыз... Әгәр ташка барып төшсә, нәрсә булган булыр иде? Беткән булыр иде!.. Әгәр очлы ботак кадалган булса? Ә?

– Бернәрсә дә җимерелмәгән бит әле, хәтта Аллага да кирәк түгел ул... Мондый аңгыра баш аңа ниемә хаҗәт, ватылсын, чәрдәкләнеп бетсен шунда!..

– Әһем, әһем... Ямьсез гамәл кылынган, ызначит... – диде Туктамәмбәт, тынлыктан файдаланып. Әле кулындагы камчысына карады, әле атның ялларын сыйпаштырган булды, совет заманы активы буларак, нидер әйтергә тиеш иде ул. Кирәк бит, ә, тиешле сүз аның башына килергә җыенмады.

Һаман да тынычлана алмаган Биктәр, кулларын болгый-болгый, әйтеп салды:

– Мин әле бала чагымны яхшы хәтерлим. Кыргызлар койма тотмый иде ул чакта. Әти бу агачны нәкъ менә ике арадагы чикне билгертеп торсын дип утыртты! Бу турыда бөтен авыл белә! Ә хәзер – ана назы күрмәгән нәрсә, тик торганда әлеге агачны кисә! – Карт һаман тынычлана алмый иде.

– Мин бит чикне менә бу арык аңлата, дип уйладым.... Җитмәсә, агач безгә якын-

рак тора... – дип мыгырданды Әхмәт, көтмәгәндә теле чишелеп. – Аяктан екмыйча гына әйтеп булмый идеме шуны... – Ачуы чиктән ашкан иде аның.

Биктәр, Әхмәтнең тагын нидер әйтергә җыенганын күреп, сүзен әйтеп калырга өлгерде:

– Мин сиңа берничә тапкыр әйттем, ә син ишетмәдең, саңгырау колак! Нәрсә, агачның ауганын көтеп торырга кирәк идемени миңа?! Бу арыкны да мин казыдым. Башта ук агач яныннан казымакчы идем дә, синең кәкрәеп каткан атаң каршы килде. Аңа бер терсәк җир кызганыч иде... – Биктәрнең түбәнсетеп әйткән сүзләре Әхмәтнең күңеленә ук булып кадалды.

– Җитте! Минем әти турында андый сүзләр әйтмә! Үзең кәкрәеп катмагаең! – Әхмәтнең кызганнан-кыза баруын аның йөзендәге сакал төкләре тырпаюыннан да шәйләп була иде. – Әтинең рухын тынычлыкта калдыр!

Моңарчы үзенә болай каршы төшүчене күргәне булмаган Биктәр отыры җәеләсе итте:

– Кара син аны, үпкәләгән булып, атасын яклап маташа... – Хәзер ул хатынын да тыңламас халәттә иде: – Бабаларың каберләрендә әйләнеп яткыры!.. Кара син аны, ә! Ул минем кәкрәеп катканны көтә! Күрсәтәм мин сиңа хәзер кәкрәеп катуны!..

– Син бит үзең башладың... Минем әтине...

– «Син»гә күчтең, ә? Минем бишекне тибрәткәнсең, ахрысы... Сугыш вакытында үлемнән коткарып калдым мин сине. Корчаңгыдан үлә идең. Юындырдым, киендердем, ашаттым – шулай түгелме әллә?! Соңыннан сарык чалдым, менә бу хатын белән кавыштырдым. Ул чакта синең бетәшкән кәҗәң дә юк иде бит... Хәтерсезгә әйләндеңме хәзер? Туклыктан җенең котыра, берни күрмисең! Йолкыш!

Гауга өр-яңадан башланды. Ике ир-ат акырыша – берсен-берсе тыңлаучы юк. Күптән вафат булган бабайларны кабат-кабат искә төшерделәр. Мөгаен, ул бабайлар, чынлап та, каберләрендә әйләнеп яткандыр. Әйе, ямьсез кыландылар күршеләр. Арттырып җибәрделәр хәтта. Мондый чакта бер кыргыз да тыныч кына карап тора алмас иде. Туган тиешле күршеләр, акылдан шашкан кебек, бер-берсенең якасына ябышты, хатыннары исә, бик яман кычкыра-кычкыра, такмаклап елаша-елаша, ирләрен читкә тарткалады. Кем әйтмешли, мавыгып китеп, берзаман кочаклашкан да булырлар иде; сүз арты сүз китеп, ахырда, тагы да зуррак җәнҗал килеп чыкты. Халык җыела башлады. Гадәттә үзен тыйнак тоткан, туганына беркайчан да каршы килмәгән Әхмәт акыра-бакыра башлады:

– Синең ул агачыңнан тәмам гарык булдым, яса шул агачтан үзеңә табут, анаңны сатып җибәрәсе! – Әхмәткә хәзер барыбер иде.

Биктәр дә җавапсыз калмады:

– Үзең ясат табутны! Зәһәр телле, хәйләкәр, намусын саткан сөйрәлчек хатыныңа ясат! Бу миннән сезгә хәер булыр!.. Анаңны!.. – Ачудан ул үз-үзен тыя алмады, һаман да йөз кызартуын дәвам итте. Аның элекке килене, моңарчы үзен тыйнак тотарга тырышкан Зөһрә – Әхмәт хатыны, хәзер инде ул да читтә калмады, чәчрәп чыкты:

– Сине кабердә күрергә язсын, күгәрек, черек, килбәтсез колга... Синең башыңа... язсын берүк! Минем сөйрәлчек булганымны кайчан күрдең, җир бит? – Ул оятын бөтенләй югалтты. Бары тик Биктәр карчыгы гына аны тынычландырып маташты. Ярый әле ул тыелып кала белде, сүз бәрелешенә кысылмады. Әгәр кысылган булса, ирләр канга батканчы сугышкан, ә хатыннар бер-берсенең чәчен йолкый-йолкый тарткалашкан булыр иде. Бу бер дә яхшыга алып бармас иде билгеле.

Тавыш-гауганы ишетеп җыелышкан унлап ир-ат һәм хатын-кыз ишегалдын-

да кайнаша. Туган-тумача үз кардәш-ыру вәкилен яклаган булып кылана, ул арада, үзләре дә сизмәстән, низагка кушылып китә.

– Ярар инде, Зөкәй, кызма ул хәтле. Тукта, зинһар...

– Кабахәт, ничек ул шулай дип әйтә ала?! – Зөһрәне яклаучылар Биктәрне битәрләде: – Хур булсаң иде!..

– Нишләп сөйрәлчек булыйк без?!

– Тыегыз ирегезне, югыйсә...

Берсен дә туктата алмаячагына төшенгән Тутамәмбәт аксакал, кинәт камчысы белән каты итеп атының арт санына китереп сукты да, ызгыш кырыннан китеп барды.

– Әй, Әхмәт, нигә син өлкән туганыңны хөрмәт итмисең? Нинди хәл бу? Аннан башка сине яклаучы туганнарың бүтән юк бит!

– Биктәр дөрес эшләдеме әллә? Әгәр шулай икән, аны тизрәк суытыгыз!

– Анаңны! Саңгырау колак! Яп авызыңны, югыйсә...

– Нәрсәгә төрткәлисең мине?!

– Төптән алма, гадәттә ул төш черек була... – Кемдер әле һаман да басып торган агачны янә кисү мәсьәләсендә шундый киңәш бирә иде: – Әйе, төптән чабарга синең хәлеңнән килмәячәк...

– Чапканда сак булырга кирәк, ялгыш өй түбәсенә килеп төшүе бар...

– Өстән кран белән эләктерергә кирәк...

– Каһәр суккыры!..

– Килбәтсез колга, теге чакта, минем бәрән аның ишегалдына кергәч, шуның аягын сындырды бит тәки! Хәтерлисезме? – монысын Качкын – Биктәрнең ике йорт аша күршесе кычкырды. Элеккке үпкәләрне искә төшереп, ул, форсаттан файдаланып, әйтәсен әйтеп каласы итте. Аны Кәкре Хәсән җөпләде:

– Узган ел, сибәсе су аркасында минем улым белән бәхәсләшеп, аның кәтмәнен тартып алган иде. Тәки бирмәде. Бир хәзер үк!

Кешеләр төркем-төркем булып баскан иде. Биктәр күршесенең күршеләре һәм аларның күршеләре; ә урамның теге башында ук яшәүче Аманай белән Баешбай, маңгайга-маңгай килеп, әтәчләнә үк башлады:

– ...Минем белән нәрсә эшли аласыз, ә? Ашыйсызмы?

– Әхмәт белән икегез теге ишәк өчен түләгез хәзер үк!..

Бактың исә, Аманай моннан биш-алты ел элек югалган ишәген исенә төшергән икән. Әхмәт көтүче булган икән ул чакта. Менә шул үпкә өскә калкып чыкты хәзер. Басу капкасы янында йөргән ишәкне Әхмәт белән Баешбай читкә сатып җибәргән икән, дип, халык сөйләнгән иде шул. Алар бер мәктәптә укыды, гел дустанә мөнәсәбәттә булдылар. Мондый чакта ниләр генә искә төшми...

Вакыйга барышында ике-өчкә бүленгән ирләр һәм хатыннар төркеме, бер-берсе белән эткәләшә-төрткәләшә, мәгънәсез сүз көрәштерүне дәвам итте. Беркем беркемне тыңламый иде. Элекке үпкәләрне искә төшереп, алар шушы минутта хакыйкатьне ачыкларга маташты. Ыгы-зыгының корыган агачтан башланганын күпләр онытты да инде. Хәтта бермәлне Биктәр белән Әхмәтне дә оныттылар. Еллар буе җыйналып килгән шик-шөбһәләр, үпкәләр әйтелеп бетте. Кешеләр һаман да берберсен тыңламый. Кыскасы, кем дә булса бу мәхшәрне туктатырга теләсә, бу эш һич барып чымас иде. Беркем бернәрсә тыңламый. Яңа кешеләр пәйда булуга, аларны кемнәрдер үз төркемнәренә сөйрәп кертә һәм сүз көрәшен өр-яңадан башлап җибәрә.

Вчүтеки, туган-тумачаны туганнар яклый барыбер. Бөтен авыл кешесе әтисе яки әнисе ягыннан кардәш тиешле. Кыскасы, авылда чит кеше юк иде. Көндез башланган җәнҗал кичен дә тәмамланмады. Мал-туар һәм балалар, ашау-эчү һәм көнкүреш

хезмәтләре – барысы да онытылды... Сыерлар мөгрәве, сарыклар бәэлдәве бөтенләй ишетелмәс булды...

Әллә сүз көрәше туйдырды, әллә башка нәрсә шунда, кыскасы, кешеләр хәрәкәткә күчте: хатын-кызлар тырмаша-тырнаша, ир-атлар чын-чынлап сугыша башлады. Нәкъ шул вакытта бер тавыш яңгырады:

– Акылыгызга килегез, Алла җәзалаячак бит! – Туктамәмбәт аксакалның кинәт әйткән әлеге көчле тавышы яңгырамаса, кем белә, бу гауга ни белән беткән булыр иде икән?!

Аксакалның, үз эшен күптән тәмам итеп, өенә кайтып барышы иде. Аның көндез юкка чыгып торганын беркем сизмәгән иде.

– Син монда нәрсә югалткан идең, җүләр! Бар, хәзер үк өйгә кайт! – Туктамәмбәт, үзенең тешсез карчыгын күреп, аңа камчы белән кизәнде, тегесе, куркып кына якягына каранып, бөтенләй юкка чыкты. – Син генә җитмәгән идең монда! Кара син аны!..

Әлегәчә дәрт-җегәрен югалтмаган Туктамәмбәтнең тавышы тамак төбеннән үк чыга башлады – кайчандыр бригадир булган кеше шул ул, чыкмас җиреннән чыгар тавышы!

Кешеләр бәхәсләшүдән туктады, кемне-кемне, әмма Туктамәмбәтне алар хөрмәт итә иде. Кем белгән, бүгенге дуамал ахмаклар тагын ниләр кыланмас иде. Ким дигәндә, бер-берсенең башларын ярган булыр, ә хатын-кызлар исә тырмашып-тырнашып бетәр иде. Акылдан язган Әхмәт әле генә үзенең өлкән туганына – Биктәргә кизәнеп маташты. Ара ерак булу сәбәпле, ярый әле йодрыклар тиешле урынга барып җитмәде. Аннары хатыннар ирләрен җәһәт кенә артка сөйрәп өлгерде. Әгәр йодрык үз эшен эшләгән булса, тешләр һәм кан коелыр иде... Менә нәрсәгә китерә дошманлык! Әхмәттән беркем дә моны көтмәгән иде!

– Ходай күрсәтмәсен бүтән! Җитте, соңга калганчы, акылыгызга килегез! Карагыз үзегезгә: ирләр – хатыннарга, хатыннар хайваннарга охшап калган... – Туктамәмбәт, канәгатьсезлеген белдереп, халыкка карап алды. Аның ачуы килде хәтта. Халык төркеме шулчакта гына, артык кызып киткәнен аңлап, тынып калды.

– Бер корыган агач аркасында бөтен туганлык җепләрен өзәргә телисезме?! – дип дәвам итте Туктамәмбәт. – Намусыгызны тәмам югалткансыз бит! Оятның ни икәнен белмисез! – Ул, җәнҗал һаман да шул корыган агач аркасында бара, дип уйлаган иде. Ә бит ызгыш сәбәпләре хәзер үткәндәге үпкәләргә күчкән иде. Боларны, әлбәттә, Туктамәмбәт каян белсен! – Бу агач, нәрсә, сезнең гомерегезне озайтамы әллә? Иртәме-соңмы, барыгыз да әби-бабаларыбыз янына китәчәк. Һәм бернәрсәне дә үзегез белән кабергә ала алмаячаксыз! Әмма сездән соң сүз калачак: бер черек агач аркасында җыен туган-тумача оятка калды, диячәкләр! Мондый хәлнең кайда булганы бар?! Сезнең буын балалары гаепсездән гаепле булачак, гомергә хурлыкка дучар ителәчәк! Туктагыз! Бу бары тик безнең арада гына калырга тиеш. Аңладыгызмы? – Туктамәмбәт, камчысы белән ат муенына кундырып алды да, курка-курка гына гына өенә элдерткән карчыгы артыннан ыргылды. – Таралыгыз! Тораташ булып катып тормагыз! Юньсезләр!

Кыяфәтен китерик, дип булса да, беркем дә аксакал белән кешечә саубуллашмады. Элекке шаулы бәрелештән айнып җитмәгән иде әле алар. Беркем дә урыныннан кузгалмады.

– Юлыңда бул, син генә акыллы баш инде! – диде кемдер.

Бу сүзләрне әйтүченең Туктамәмбәткә үпкәсе бар иде шикелле. Шуңа ул аны, аксакал артыннан булса да, әйтеп каласы итте.

Беркемнең дә урыныннан кубасы, кузгаласы килми иде. Барысы да товарын сата алмаган спекулянт кебек басып торуында булды. Биктәр белән Әхмәт тә һаман да киеренке халәттә иде әле. Беркемнең дә яклаучысыз каласы килмәде...

Бөтенесе дә торaташ булып басып торган мәлдә, нидер мыгырдана-мыгырдана, атка атланган Таштан пәйда булды. Ул дөм исерек иде. Акылы томанланган булу сәбәпле, үзенең кая барганын, нишләгәнен белми иде Таштан. Аның туры аты, хуҗасын екмаска тырышып, өенә таба салмак кына атлый иде. Таштан иртәдән бирле, дуслары белән бергә, кибеттән чыкмыйча, барлык акчасы беткәнче эчте. Алар ике көн элек кенә үгез саткан иде. Таштанның кәефе юк, ул яман ачулы иде. Менә ул Биктәр ишегалдында өелешеп торган кешеләрне күреп алды. Шулчак:

– Эһем-ммм... Ыйк! – дип очкылык тотып алды аны. Беравык ул бу хәтле кешенең нигә җыелганын аңышмыйча торды. Иярендә борылып утырган килеш, ул һәркемгә караш ташлап алды. Томан эченнән сарык эзләгән шикелле, кемнең кем икәнен ничекләр генә чамаларга тырышмасын, нәтиҗә күренмәде.

– Нәр-сә бул-ды? Берәр-се ү-үлд-деме әллә?

Шуннан соң аның күзенә кем беләндер бәхәсләшеп торган хатыны чалынып алды. Кемдер аның хатынына начар сүз әйткән кебек тоелды. Исерекнең башына кан йөгерде. Ул бит сөекле хатынын якламаслык кеше түгел.

– Чү! – дип фәрман бирде ул атына. Камчының авырлыгын тойган ат, куркынып, урыныннан купты һәм ишегалдына барып керде, чүт халык өстенә менмәде.

– Әй, анагызны шулай итим!.. Нишләп әле сез... ми-минем хатынга бәйләнәсез, ә?! – Таштан камчысын уңга-сулга болгады. – Мә сиңа, мә сиңа! Кара син аларны... Минем хатынга бәйләнеп маташалар. Җыелганнар, имеш...

Камчы эләккәне дә, эләкмәгәне дә, карчыгадан качкан тавыклар төсле, төрлесе-төрле якка чаба башлады.

– Коткарыгыз!

– Үтерә бу!

– Бу бит – Котырган, тагы төтен булганчы эчкән!..

– А-а!!!

Беркем дә Таштанга каршылык күрсәтмәде. Хәер, барыбер файдасы булмас иде. Хатыннарын яклап килгән ирләр, җанашларын онытып, кайсы-кая таралып бетте. Котырган кушаматлы Таштан белән беркемнең дә алышка кергәне юк иде. Исерек чагында Таштан әтисен дә танымас иде. Теләсә кемне үтерергә мөмкин, чөнки ул үзе үлемнән курыкмый. Менә ул хәзер, йөгәнне тоткан килеш, кем туры килсә – шуны камчысы белән кыйный. Аның хатыны үзенең шашынган ирен яхшы белә иде, шуңа күрә, беренчеләрдән булып юкка чыкты. Камчы эләккән хатыннар бар көчләренә акыра иде. Камчыдан качып өлгергәннәр исә, кайсы-кая качып беткән иде. Бер җүләр ун акыллыга тора, шулай булып чыга түгелме соң бу?!

Урамда бик тиз тынлык урнашты. Җәнҗал агачы да, аңа бәйле барлык бәхәсләр дә авыл халкының башыннан чыгып очты. Биктәр белән Әхмәт, шулай ук хатыннарын ташлап, беренчеләрдән булып «сугыш кыры»ннан качкан иде. Котырганга беркем дә түгел алар! Әй, кадалып ла китсен теге агач!..

Урысчадан ***Ләбиб Лерон*** *тәрҗемәсе.* ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2019

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

ТӨРКИ ТЕЛДӘ СӨЙЛӘНГӘН ХӨТБӘ ҺӘМ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТКӘН БЕР ОФИЦЕР

Бер җомга көнне Харбинда җомга намазын укырга дип мәчеткә киттем. Мин килгәндә, имам Гыйнәятулла әфәнде михрабта халыкка вәгазь сөйли иде. Имам әфәнде 24 яшьлек күркәм холыклы яшь кеше икән. Гаҗәеп төзек, ачык тел белән сөйли. Вәгазен тәмамлаганнан соң, җәмәгатькә мөрәҗәгать итеп: «Олы кунагыбыз Габдерәшит Ибраһим әфәндедән үтенәбез: безгә бүген төрки телдә хөтбә укып, җомга намазыбызны кылдырсын иде. Безнең өчен гомеребез буенча хәтеребездән чыкмаячак бер ядкәр булыр иде», – диде. Һәммәсе бергә: «Үтенәбез», – дигәч, мин кабул итәргә мәҗбүр булдым. Мөнбәргә күтәрелдем. Мәзин азан әйткән арада, мәчетнең урта ишеге янында, рәтләрнең иң ахырында басып торучы ике кешегә күзем төште. Өсләренә кигән киемнәреннән берсенең – офицер, икенчесенең исә сәүдәгәр икәнен аңларга була. Мин хәмдәлә[1] белән салвәләне[2] һәм *«уд»у илә сәбили*

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

[1] Хәмдәлә – «әлхәмделиллаһ»ны кыскартып әйтү. Татар сөйләм телендә «Фатиха» сүрәсен «Әлхәм(д)» сүрәсе дип атап йөртү дә бар (тәрҗ. иск.).

[2] Салвәлә – Пәйгамбәребез галәйһиссаләтү вәссәламгә укылган салават һәм дога (тәрҗ. иск.).

раббикә... [Раббының юлына чакыр...] (Нәхл: 125) дигән мәшһүр аятьне укыганнан соң, мәгънәсен төркичә аңлатып бирдем, шуңа бәйләп вәгазь сөйләдем, нәсыйхәт бирдем. Рәтләр артында торучы теге офицер белән иптәше зур ихтирам күрсәтеп тыңлыйлар иде. Офицер, ахрысы, күңеле тулып, кулъяулыгы белән ара-тирә күзләрен дә сөртеп алды. Җомга намазыннан соң, мин тагын кыска гына вәгазь сөйләп алдым. Теге кешеләр икесе дә, баскан җирләрендә хәрәкәтсез калгандай, ихлас күңел белән тыңлап тордылар. Аннары бер гашер[3] укылганнан соң, гадәт буенча бөтен җәмәгать мәчеттән чыга башлады. Без имам әфәнде белән икебез иң ахырга калдык. Мин чыгып барганда, әлеге офицер баш иеп сәламләде. Янына килеп, күрешергә кулымны суздым, гадәткә туры китереп исәнләшкәннән соң, офицерга: «Безнең гыйбадәтебез сезгә ничек булып күренде?» – дип сорадым. «Мин электән беләм», – дип җавап бирде.

Имам Гыйнәятулла әфәнде бу офицер турында сөйләп бирде. Рус офицеры икән, 40 яшьләр тирәсендә, ихлас күңеле белән Исламга кергән, хөкүмәт каршысында мөселманлыгы әлегә рәсми рәвештә кабул ителмәгән, ләкин моны рәсмиләштерергә дигән фикере нык икән. Дәүләт эшендәге рәсми кеше булуына карамастан – мәҗбүри түгел – ихлас вөҗдан омтылышы белән мөселман булган, Ислам динен кабул итүе турында ачык белдереп, рәсмиләштерәчәк. Бу рәсмиләштерү эшеннән соң, шунда ук гаскәрдән куылуы, ач калуы бик мөмкин. Шундый куркыныч янавын белә торып, күкрәк киереп каршы баруы, Ислам диненә омтылу Рус илендә җиңел эш түгел. Менә шулай: Раббының һидаяте кешегә килеп ирешсә, теләсә нинди фидакарьлекне башкарта ала. Менә, кардәшләр,



Стѣны въ Старомъ Харбинѣ.
Kharbinne.

бу – рус офицеры. Һәркем өчен ачык билгеле: бу кеше өчен бернинди дә мәҗбүрилек юк. Шулай булгач, болай дип уйланырга кирәк: ни өчен мөселман булган? Русия тиранлыгы бу офицерны таптап изәргә дә мөмкин, ләкин аңа да исе китми, һәрнәрсәгә әзер. Бу хәлнең шаккатыра торган ягы нәкъ менә шул да инде.

КЫТАЙ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ НӘЗАКӘТЕ

Беркөнне Харбинда Кытай почтаханәсенә кердем. Бу илдә почта эшләре бик яхшы тәртипкә салынган. Теләсә нинди хатны кабул итәләр, акча җибәрү эше дә көйләнгән.

Биредәге почтаханәдә алты хезмәткәр бар: берсе – инглиз кешесе, башкалары – кытайлар. Озын чәчле, милли киемнәрен кигән кытайлар русча, инглизчә, французча язылган хатларны кабул итәләр. Бер кеше хатларны да кабул итә, почтага эше төшкән башка кешеләрнең сорауларына да җавап бирә иде.

Мин дә, бу кытай кешесенә мөрәҗәгать итеп:

---

[3] Гашер – Коръән-е Кәримнең ун аятьтән торган бер өлешен уку (тәрҗ. иск.).

– Кытай илендә бераз яшәячәкмен, биредән Русиягә хат җибәрергә теләсәм, конвертының тышына нинди телдә язарга кирәк? – дип сорадым.

– Кытайда кайларга китәчәксез? – дип, зур ихтирам белән кызыксынып сорады.

– Язган булса, бөтен ил буйлап гизәргә телим.

– Бик гаҗәп, курыкмыйсызмы?

– Куркыныч нәрсәләр бармы әллә?

– Булуы ихтимал, аврупалылар куркалар, шуңа әйтүем...

– Мин аврупалы түгел.

– Яхшы, кая гына барсагыз да, шәһәрләрнең барысында да почтаханә бар. Нинди телдә язарга теләсәгез, шул телдә яза аласыз.

– Төрекчә дә мөмкин булырмы?

– Хатыгыз Төркиягә китәсе булса, төрекчә дә яза аласыз. Тик конвертта французча яки инглизчә «Төркия» дигән сүз язылган булырга тиеш.

– Сезнең почтагыз һәркөн китәме?

– Зур шәһәрләрдә һәркөн китә, ләкин авыл җирләрендә алай ук түгел. Тик бик тиздән почта эшләре авылларда да тәртипкә керәчәк.

– Зур шәһәрләрдә телеграф та бармы?

– Шәһәрләрнең күбесендә бар, берничә елдан Кытай илендә бөтен җирдә – авылларда да – почтаханәләр һәм телеграфханәләр ачылачак.

– Телеграфлар кытай телендә кабул ителә аламы?

– Һәр телдә кабул ителә ала. Тик инглиз хәрефләре белән язылырга тиеш. Кайбер җирләрдә гадирәк сүзләр кытай хәрефләре белән дә кабул ителә, ләкин бик хаталы булып чыга.

Мин, бу почта хезмәткәре белән шулай сөйләшеп алганнан соң: «Вакытыгызны алдым, гафу итегез!» – дидем. Ул исә: «Сөйләшү минем өчен дә файдалы булды, әңгәмәгездән бик канәгать калдым, тик эшем күп, гафу итегез...» – дип, мине ишеккә кадәр озата килде.

Менә бу – «вәхши» кытайларның почтаханәсендә, без «хунхоз»[4] дип белгән кыргыйларның мөгамәләсе. Шул ук Харбинда рус почтаханәсенә дә кер-

[4] Китапта «хунхоз» рәвешендә язылган булса да, бу сүзне *хунхор* дип укырга тәкъдим итәбез. Гарәп язуында з һәм р хәрефләре бик охшаш, алар з хәрефенең өстендә нокта булу белән генә аерылып торалар. Бу сүз *хунхоз* рәвешендә ялгыш язылган «кансыз, рәхим-шәфкатьсез» мәгънәсендәге *хунхор* сүзе булырга тиеш. Фарсы теленнән алынма сүз булган *хунхор* уйгыр телендә дә киң кулланыла *(тәрҗ. иск.)*.

дем. Утыз-кырык хезмәткәр бар. Бу хезмәткәрләрнең мөгамәләсе:

– Нәрсә кирәк?

– Хат җибәрергә марка кирәк иде.

– Сал башыңнан кәпәчеңне!

Тагын әлләниләр... Хурлаулар, түбәнсетүләр. Өч тиенлек марка биргәнче, алты тапкыр кимсетергә өлгерә.

Бу хәлләргә инсаф белән якын килгән очракта, теге вәхши (!) кытайлар белән менә бу мәдәни (!) русларны чагыштырып карамыйча мөмкин түгел. Бераз гына башында уйлау сәләте булган кешене кытайларның мөгамәләсе сокландырмый калмас: «Чын кешелек менә бу!» – дияргә мәҗбүр итәр. Ләкин, кызганыч ки, кешеләрнең уйсызлыгы, сукырлыгы шул дәрәҗәгә җиткән ки, бичара кытай кешесенең озын чәче белән озын күлмәген күрүгә, «кыргый, вәхши» дигән нәтиҗә ясыйлар. Кытай кешесе никадәр генә кешелекле булса да, файда юк. Әмма руслар, аврупача киенгәнгә күрә, никадәр кешелексезлек күрсәтсәләр дә күрсәтсеннәр – алар барыбер мәдәни!..

КЫТАЙЛАРДА МИЛЛИ ХИСЛӘР ҺӘМ УЯНЫШ

Харбинда көннәр буе шәһәр карап йөри идем. Русча белгән берәр кеше очратсам, шунда ук берәр нәрсә сорый торган, форсат чыккан саен сөйләшергә тырыша идем.

Шулай беркөнне Ван-Куан исемле кытай сәүдәгәренең кибетенә кергән идем. Арабызда шундый сөйләшү булды, мин сораулар бирдем, Ван-Куан җавап бирде:

– Кытайлар бүгенге хәлләреннән канәгатьме?

– Адәм баласы җаһиллегеннән канәгать була аламы?! Ләкин, шулай да, без канәгать, чөнки әле күзебезне ачканга да күп вакыт үтмәде.

– Русия белән сугышта кытайлар күргән зыян зур булдымы?

– Зыяны никадәр генә күп булса да, файдасы аннан да күбрәк булды. Кешеләребез һәлак булды, әлбәттә, әмменә матди зыяны рухи файдасы янында әһәмиятсез булып калды. Әле янына рус-япон сугышын да кушсак, матди һәм рухи мәнфәгатебез бик күп тапкыр артык икәне күренә. Ник дигәндә, өч йөз – биш йөз мең кешебез һәлак булды, әмма илебезне гомерлек әсирлектән коткардык. Шулай булса да, җан ачысы бер зыяныбыз бар – үч алганчыга кадәр йөрәкләребездәге ярасы гомербакый яшәячәк – Амурда без дучар ителгән хурлык. Менә бу зыян инде, нәселдән-нәселгә тапшырылып, киләчәк буыннарыбызның йөрәкләрендә дә урын алачак.

– Бу дәрәҗәдә зур зыян ул нидән гыйбарәт?

– Русларның Благовещенскида безнең кытайларны хурлыкка төшерүләре, Амур елгасында батырылган кешеләрнең каннары...

– Ул нинди вакыйга? Ничек булды?

– Ничек башкарган булсагыз, шулай булган инде, шулай дип тә кабул итегез. Ләкин бер генә тарих та үчсез калмый.

– Без – мөселманнар. Без үзебез дә гаделсезлекләргә дучар милләт.

– Сез гаделсезлекләргә дучармы-юкмы – анысы безгә мәгълүм түгел, сугышларның һәр икесендә дә без сезне күрдек, бөтен әһәмиятле урыннарда сез булмый калмый идегез. Пекин сараен талаганда да сезнең татарлар бар иде. Руслар белән үз исәбегезне үзегез күрерсез, ләкин без сезне, бер үк илдән булганга, алар белән бер саныйбыз.

КЫТАЙ ҺӘМ ЯПОНИЯ

Мин сүзне борырга мәҗбүр булдым, ник дигәндә, аның бу сүзләренә җавап бирерлек хәлдә түгел идем. Японнардан сүз башлап, болай дидем:

– Японнарга карашыгыз ничек?

– Яңа милләт, эшлекле кешеләре күп, мәдәнилеккә дә аяк бастылар. Әгәр сугышта да җиңә алсалар, мәдәни дөньяда үз урыннарын таба алачаклар.

Окр. Харбина. № 12.
Главная дорога ведущая въ Фу-ди-дянь.

Ләкин шул ук вакытта, икътисадка булган ихтыяҗлары гомер-бакый калачак.

– Японнар белән кытайларның берләшү ихтималы бармы?

– Японнар белән кытайлар берләшә алмаслар. Без – кытайлар бервакытта да әсирлеккә күнегә алмаганбыз. Үз хакимият көчләрен бар итү өчен, кытайлар соңгы сулышларына кадәр көрәшәчәкләр. Шик юк: японнар да үзләре казанган дәрәҗәләрен саклап калырга тырышачаклар. Тик шулай да, японнар белән кытайларның Аврупага каршы тору, үзләрен саклап калу өчен берлек килешүе төзи алулары бик мөмкин. Әгәр моны башкара алсалар, милли намусларын саклап кала алачаклар. Бу – бик мөһим мәсьәлә. Безнең кытайларны аврупалылар бер унбиш ел тынычлыкта калдырсалар, без аннары үзебез белән үзебез идарә итә алыр идек. Без сугышсыз, тыныч вакытларда, бар нәрсәдән дә бигрәк, икътисадка игътибар бирәбез. Тик безгә яңа кораллар җитештереп, аларны куллануның җаваплылыгын да үз өстебезгә алырлык вакыт кирәк. Без хәзерге көндә менә шул уңайлы вакыт килгәнен көтәбез.

КЫТАЙДА АВРУПАГА КАРАТА ҮЧ АЛУ ХИСЕ

Безнең сөйләшү шулай дәвам итте:

– Сез моны үзегез булдыра алмыйсызмы әллә?

– Аврупа сәясәтчеләре, Көнчыгышта яшәүче милләтләргә мондый мөмкинлекне бирмәс өчен, һәрвакыт бер сылтау табып торалар. Һич тә булмаса, берәр миссионерны корбан итеп җибәрәләр дә, шуның артыннан ук хәрби флот та килеп җитә.

– Кытайда христианлык җәелә алырмы?

– Христианлыкның ни икәнен белеп, үзе сайлап һәм риза булып христианлыкны кабул иткән кытай кешесе юк. Ләкин, миссионерның явызлыгы тимәсен, дип, христианлыкны кабул итүчеләр күп.

– Аврупалылар арасында бөек кешеләр бар, кешелеккә хезмәт итүчеләр дә күп. Бигрәк тә менә бу XX гасыр гыйлем ияләре арасында кешелеккә хезмәт фикере алга киткән.

– Аврупа кешелеклелек турында сөйли, вәхшилекне эшли. Эш ягыннан, кешелеклелек белән аврупалылар арасында мөнәсәбәт юк. Безнең гөнаһсыз

кытайларны руслар Амур елгасында батырып үтергәндә, елга өстендә мәетләрдән күпер салынган кебек иде. Бер генә мәдәни аврупалы да, чыгып, русларга: «Сез нишлисез?!» – димәде. Хәтта анасының кочагындагы гөнаһсыз сабыйларны да елгага аттылар. Бөтен бу хәлләр аврупалыларның күз алдында булды, кешелеклелек хакында кайсы сүз әйтте? Аврупа газеталарының кайсы ике юл гына булса да хәбәр язды? Үзләренең бер миссионерының борыны гына канаса да, шунда ук, кешелеклелек хакы дигән булып, күтәрелеп чыгалар. Амур елгасы өстендә кытай кешеләренең мәетләре өч көн буе күпер кебек өелеп ятты, ә аврупалылар Амур елгасының ярларында берничә көн мәет ауладылар. Елга буйлап агып барган мәетне тотып ярга сөйрәп чыгаралар, өстен-башын тикшереп, акчасымы, нәрсәсе булса, барын алып, мәетне кире суга аталар иде. Инсаф итеп уйлап карагыз, моннан соң да кешелеклелек дип сөйли аласызмы?

Мин инде моннан соң сүзне озайтмадым, шулкадәре белән чикләнеп, саубуллаштым. Ван-Куан, бик мөлаем елмаеп: «Артыграгын да сөйләдем, кичерегез!» – диде, кулларымны кысып саубуллаша-саубуллаша, ишеккә кадәр озата барды.

Бу кеше белән сөйләшкәндә мин шуңа игътибар иттем: аның рус теле минекеннән күпкә яхшырак иде, бик җиңел, төртелми-нитми сөйләште.

Бу исә кытайларның сәләтле булуын күрсәтә. Безнең Русия татарларының русларга буйсынганнарына инде 300 ел булса да, шушы көнгә кадәр русча белүчеләребезнең саны бик чикле. Кытайларның исә, переворот артыннан ук, мөкәммәл дәрәҗәдә русча сөйләшә, укый-яза белә торган кешеләре күбәйгән. Кытайлар Маньчжуриянең һәр тарафында рус товарлары белән сәүдә итәләр. Сәнгать әһеле дә – кытай, мал иясе дә – кытай, һөнәр иясе дә кытай – бөтен эштә кытай кешесе. Икътисадка да бик зур әһәмият бирәләр. Кытай кешесе, никадәр бай булса булсын, үз милли киеменнән башка киемгә күз дә салмый, хәтта милли киеме белән горурлана да. Ә инде ул теге ат койрыгы кадәр чәчен изге нәрсә дип санагандай саклый.

Дәвамы бар

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

КӨНЕҢ ӨЧЕН ЯШӘМӘ...

Ләлә Мортазина

Аның исемен белмәгән, «Беренче мәхәббәт» спектаклен карамаган татар кешесе, мөгаен, юктыр.

Театр дигән серле дөнья 1918 елның 20 декабрендә хәзерге Биектау районының Мәмдәл авылында дөньяга килгән Габделхәй Каюм улы Вахитовны (Хәй Вахитны) кечкенәдән үк үзенә тарта, сихерли. Шуңа күрә егет, авыл мәктәбен тәмамлап килү белән, Казан театр техникумына юл ала. Театр ул сүз сәнгате генә түгел, музыка белән дә юлдаш. Җыр, музыка, төрле уен кораллары белән кызыксыну Вахитовлар гаиләсендә күптәннән килә. Хәй Вахитның якын туганы, гомере буе Мәмдәл авылында яшәгән авылдашым һәм күршем Габдрахман абый Вахитов та скрипкасын соңгы көннәренә кадәр кулыннан төшерми, татар халык көйләрен бик яратып, моңланып, эчке тәэсирләнү белән уйный иде. Хәй Вахитның музыка училищесына, соңыннан Казан дәүләт консерваториясенә укырга керүе, музыка белгече һөнәрен үзләштерүе дә әлеге балалык, яшьлек чорыннан килгән бер кайтаваз булгандыр, мөгаен. Шулай да әдәбият дөньясы үзенә күбрәк тарта Габделхәйне. Мәскәүдә Югары әдәби курсларны тәмамлап кайтканнан соң, Х.Вахит үзен тулаем әдәбиятка багышлый. Әмма музыкага булган мәхәббәте беркайчан да кимеми, ул аның әсәрләрендә – җырларында, пьесаларында чагылыш таба.

Тукай клубында очрашу. 1967 ел, 11 декабрь

Хәй Вахит – балалар өчен хикәяләр, халкыбыз арасында яратып кабул ителгән җырлар һәм либреттолар авторы. Шулай да, аны иң танытканы, әлбәттә, үлемсез драма әсәрләре. Драматургның 1960-1970 елларда татар сәхнәсендә аеруча зур уңыш белән барган спектакльләре әле бүген дә куела, татар тамашачысында зур кызыксыну уята. Димәк, ул әле дә безнең арабызда, әсәрләрендә яши.

ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршындагы Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә (Мирасханә) Хәй Вахитның махсус фонды бар. 1991 елда И.Еникеев тарафыннан тасвирланган әлеге фондта барлыгы 354 эш тупланган. Анда күп санлы фотосурәтләр, драматургның хатлары, язылачак әсәрләренең план-конспектлары, басылып чыккан әсәрләренә, спектакльләргә бәяләмәләр, газета-журналлардан алынган мәкаләләр, Х.Вахитның көндәлекләре, хатлары һәм башка документлар урын алган. Бу материаллар арасында әлегәчә укучыга таныш булмаганнары, драматургның тормыш юлы һәм хезмәт эшчәнлегенә беркадәр яңалыклар, өстәмәләр кертерлекләре дә

Хөснул Вәлиуллин һәм Хәй Вахит. 1941 елның 26 сентябре

бар. Архивтагы материаллардан Хәй Вахит әсәрләренең татар сәхнәсендә генә түгел, илебезнең башка театрларында да куелуын һәм зур уңыш белән баруын күрергә мөмкин. Әйтик, 1976 елда Дагыстандагы Авар музыка-драма театрында Х.Вахит әсәре буенча «Чужая вина» спектакле куела, ул алга таба да зур уңыш белән бара. Бу турыда шул елның 13 маенда «Советская Татария» газетасында мәкалә дә басылып чыга[1]. Мирасханәдә шулай ук авторның әсәрләренә, дөнья күргән спектакльләргә карата «Правда» һәм «Социалистик Татарстан» газеталарында, «Азат хатын» журналында басылып чыккан күп санлы бәяләмәләр белән дә танышырга мөмкин.

Архивтагы материаллар арасында Х.Вахитның көндәлекләре, куен дәфтәрләре аеруча кызыксыну уята. Аларда тупланган язмаларда драматургның аерым проблемаларга багышланган, төрле елларда теркәгән уй-фикерләре чагылыш таба. Кайбер үрнәкләрне журнал укучылары игътибарына да тәкъдим итәбез.

Х.Вахитның куен дәфтәреннән[2]:

***

Җүнле атадан җүнсез бала туа. Мин үземнең җүнсез булганыма сөенеп тә куям. Балаларым җүнле булыр.

***

Дуңгызларга бүреләр һөҗүм итсә, дуңгызлар бер-берсенә артлары белән (берләшеп), бүреләргә һәрберсе аллары белән каршы баралар.

***

Көнең өчен яшәмә, динең (иманың) өчен яшә.

***

Тәнкыйтьчеләргә:
Берсе күреп, калган биш-алтысы аңа ияреп өрә.

***

Алга бару өчен, артка барып карау да кирәк.

***

Элек киленне алганда ашатып карап алганнар. Яхшы ашаса, алганнар. Яхшы эшли, дип. Хәзер, киресенчә, аз ашаса алалар.

***

Ханның малае мәдрәсәдә укый икән. Хан аңа бер колы аша көн дә ашарга җибәртә икән. Беркөнне бу кол авырган. Хан икенче колга илтергә кушкан.

– Малаеңны белмим ич, – дигән кол.

Хан:

– Иң матур малайга биреп кайт, – дип барган.

Кичен малай кайта да әйтә:

– Нишләп ашарга илттермәдең?

Хан, чакырып, колыннан сорый.

[1] 103 фонд, 2 тасв., 57 эш.
[2] 103 фонд, 1 тупл., 295 эш.

– Илттем, – ди кол. – Иң матур малайга бирдем. Ул минем малаем иде.

...Һәркемгә үз әсәре якын.

***

Шаһ төш күргән, имеш, авызыннан бөтен теше төшеп беткән, бары бер теше генә калган. Иртәгесен шаһ чакырткан звездочетларын. Сораган, карагыз, дигән.

– Бөтен туганнарың үлеп бетә, берүзең каласың, – дигән берсе.

Шаһ аны палачка тапшыра. Икенчесе:

– Син бөтен туганнарыңнан соң да яшәрсең, – дигән.

Шаһ аны күтәргән.

Хикмәт – ничек әйтүдә!

***

Марс Шабай редакциягә хикәя биргән. Басмыйча сузганнар. Хамматов аңлаткан моңа:

– Нишләп кырынмый йөрисез?

«Самат» операсы авторлары: М.Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет академия театрының баш режиссеры Нияз Даутов, композитор Хөснул Вәлиуллин, либретто авторы Хәй Вахит

«Самат» операсының премьерасыннан соң, Нияз Даутов белән. 1977 ел, 6 ноябрь

СССР язучыларының IV съезды делегатлары. Мәскәү, 1967 ел, 22 май. Уңнан бишенче – Хәй Вахит

– Хикәямне басып чыгармыйча кырынмаячакмын. Күпме үсәр икән.

...Икенче көнне үк басканнар.

***

Солдат разведкага бара. Аланда тукталып җиләк җыя. Күтәрелеп караса, каршында – немец. Икесе дә куркып калалар, икесе дә кабурга ябышалар. Икесе дә тукталалар. Аннан бер-берсенә карашып торалар.

Язучы Гариф Гобәй белән

– Закурить нет?

– Есть.

Закурили. Әмма бик саклык белән. Бер-берсеннән шүрлиләр.

– Капкаларга юкмы?

Ашыйлар. Артык сөйләшә алмыйлар. Аннан, чигенә-чигенә, бер-берсеннән бик сакланып, үз юлларына китәләр.

...Солдат, үз частена кайтып, бу хәлне сөйли. Бөтен орденнарын кире алалар.

***

Ата баласының дневнигын карый:

– Язу – 2;

– Арифметика – 2;

– Табигать – 2;

– Җыр – 5.

– Ах, сукин сын, гел икеле ала торып, әле җырлыйсыңдамы? ■

«Самат» операсының премьерасыннан соң. 1977 елның 6 ноябре

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ ТӨЗЕЛҮЕНӘ – 85 ЕЛ!

Киләчәккә йөз тоткан берлек

ТАРИХИ ЧЫГЫШ

85 ел... Бу чор аралыгында көч-куәте белән дөньяны дер селкеткән Советлар Союзы таркалды, ни кодрәтле партия-фирка юкка чыкты. Шөкер, Татарстан Язучылар берлеге мөстәкыйльлеген, бердәмлеген һәм эшкә сәләтен тулысынча саклап кала алды. Чөнки татар язучысының иҗат белән янәшә торган һәм гаять әһәмиятле тагын бер вазыйфасы бар. Ул – халык белән бер сулышта булып, милли рухның, милли матбугатның һәм туган телнең сакланышы вә үсеше өчен җаваплылык! Соң шулай булмыйча, әгәр дә милләтең, телең юкка чыга икән, язганнарыңны киләчәктә кем укыр?!

Инде тарихка күз салыйк, 85 ел элек, 1934 елның 17 августында Мәскәүдә Союзлар йортының Колонналы залында совет язучыларының I Бөтенсоюз оештыру съезды ачыла. Гәрчә СССР Язучылар союзының төзелү тарихы шушы датадан исәпләнсә дә, аның башлангычы ВКП(б) Үзәк Комитетының 1932 елдагы апрель ка-

Съездда катнашучылар: беренче рәттә сулдан уңга – Кави Нәҗми, Алексей Толстой, Максим Горький; икенче рәттә – Ләбиб Гыйльми, Хәсән Туфан, Гомәр Толымбай, Фатих Сәйфи-Казанлы, Галимҗан Нигъмәти. 1934 ел

рарына нигезләнә. Шул елның маенда ук Татарстан совет язучыларының Бердәм союзын булдыру буенча Галимҗан Нигъмәти җитәкчелегендә оештыру комитеты эшли башлый. 1934 елның 25 июлендә исә, ниһаять, Казанда Совет язучыларының I Бөтентатар съезды ачыла. Ул, Татар дәүләт академия театры бинасында башланып, Мәгариф хезмәткәрләре йортында дүрт көн дәвам итә һәм 29 июльдә тәмамлана. Әлеге җыенда Татарстан Язучылар союзының беренче идарәсенә тугыз әдип сайлана – Кави Нәҗми (рәис), Кәрим Тинчурин, Гомәр Толымбай, Гомәр Гали, Хәсән Туфан, Вадим Красный, Гаяз Ризванов, Ләбиб Гыйльми һәм Кәшшаф Төхфәтуллин (сәркатип). Мәскәүдәге Бөтенсоюз җыенына унике вәкил җибәрергә карар кылына. Шушы унике делегатның тугызы әле саналган идарә әгъзалары булса, калган өчесе исә идарә әгъзалыгына кандидатлар: Ибраһим Гази, Галимҗан Нигъмәти һәм Фатих Сәйфи-Казанлы.

Совет язучыларының I Бөтенсоюз съездын, оештыру комитеты рәисе һәм, дөньякүләм танылган абруйлы язучы-шәхес буларак, Максим Горький ачып җибәрә. Соңрак төп чыгышны да ул ясый. Әлеге тарихи чыгыш күренекле шагыйребез Равил Фәйзуллинның «Татарстан Язучылар берлеге»* дип аталган китабында гаять тәфсилле тасвирлана. Аңа сүз бирик әле: «...*М.Горький докладын һәркем өчен, бигрәк тә язучы өчен, бүген дә кызык һәм гыйбрәтле. Бөек язучы күтәргән кайбер мәсьәләләр бүген дә бик актуаль. Әйтик, ул Көнбатыш әдәбиятчыларының күп әсәрләрендә кешенең түбән инстинктларын уята торган мотивларны: үтерү, көчләү, талау, зина кылу фонында каһарман итеп сурәтләнгән персонажларны тәнкыйтьли (Дәрдемәнд әйтмешли, «нә дәригъ», бүген китап базарларыбыз шундый әсәрләр белән тулган!), дөнья барышының үзәген тәшкил иткән гади хезмәт кешесен олыларга өнди. Докладның иң төп тезисларыннан берсе – игътибарны халык иҗатына юнәлтү. Һәр әдәбиятның нигезендә фольклор ята, дип саный М.Горький. (...) Ул үзенең бу докладында да, милләтләр турында сөйләгәндә, татарларны һәрдаим искә ала. СССРдагы 4-5 милләтне санаган чакта, татарны телгә алмый калмый. Бер татар язучысы менә нәрсә язган, дип, докладында өзек тә (ул үзе машинкада 1,5 бит булыр) укып күрсәтә. Йә, хәзер кайсы рус язучысы безнең хакта дөньякүләм трибунадан шулай әйтер икән?! Юк, берсе дә әйтергә охшамаган*».

Татарстан Язучылар берлегенең, татар әдипләренең канлы репрессия елларындагы, сугыш чорындагы хәл-әхвәле вә язмышлары белән исә журналның киләсе саннарында танышырсыз.

Язманы журналга Татарстан Язучылар берлегенең әдәби консультанты
***Марат Закир** әзерләде.* ■

* Равил Фәйзуллин. «Татарстан Язучылар берлеге». – ТКН: 2016. – 223б.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2019

Уттан сау чыккан хәтер-хатирә

(Фронтовик әтием язмалары)

Рөстәм Мәһдиев

Әтием (уңда) хезмәттәше белән. Житомир, 1946 ел

СҮЗ БАШЫ

Бөек Ватан сугышы башланганда аңа 23 яшь була. Мәгълүм булганча, әлеге сугыш зур кайгы-хәсрәт, югалтулар, биниһая сынаулар алып килә. Йөрәкләре, җаннары якты хыяллар, өмет-ашкынулар белән тулы шушы яшь буынга тәкъдир коточкыч зур авырлыклар әзерләп куйган икән. Шушы буынның иң кадерле, иң гүзәл яшьлек елларын «сугыш аждаһасы» йотарга язган икән...

Хуш исле шомыртлар күбекләнеп чәчәк аткан Җиңү көнен Өченче дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнгән сапер-минер, кече сержант Рәшит Сөнгатулла улы Мәһдиев

Чехословакия башкаласы Прагадан 60 чакрым ераклыктагы Хомутов шәһәрчегендә каршы ала...

Әтием 1918 елның 2 гыйнварында Арча районының Гөберчәк авылында мулла гаиләсендә туа. Аңа 14 яшь чакта, ягъни 1933 елда Сөнгатулла хәзрәт беренче тапкыр кулга алына. Нәтиҗәдә, үсмер бала гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителә һәм «халык дошманы малае» дип тамгалана. Аңа белем алуын дәвам итү, сайлауларда катнашу катгый тыела, эшкә урнашу мөмкинлеге чикләнә.

Моны дәлилли торган бер тарихи документ сакланган. Ул 1934 елның 11 апрелендә Арча районының Сикертән авыл советы тарафыннан бирелгән 108 нче белешмә. Анда акка кара белән: «...аерым хуҗалык алып баручы Гөберчәк мулласының малае Мәһдиев Габдерәшиткә бирелүе раслана...» – дип язылган. Әлеге сүзләрнең мәгънәсе ул чор өчен хөкем карары булып яңгырый. Аерым хуҗалык! Мулла малае!

15 яше тулар-тулмас, урысча бер авыз сүз белмәгән авыл малаена Казан төрмәләреннән әтисен эзләп йөрергә туры килә. Сөнгатулла абзыйның исән-имин булуын белергә һәм өйдән әнисе биреп җибәргән ризыкны тапшыру йөкләнгән була аңа. Байтак каңгырып йөргәч, малай авылга кайтып егыла. Гаилә башлыгын берничә айдан азат итәләр. Вакытлыча «кара эш»кә ялланып күпмедер акча юнәтеп, гаиләсен, кече туганнарын ризык белән тәэмин итүгә керешә ул. Акча эшләү юллары да чамалы була. Шуларның берсе – урманнан чыршы ботаклары җыеп, калага алып барып сату. Кәсеп итүнең бу ысулы «өлкән агай»ның дини бәйрәмнәре (раштуа, хач ману, пасха) көннәренә туры килгән. Урман каравылчысыннан җәберләнүләр, чи ылыс тутырылган капчыкның авырлыгы, тимер юл станциясенә менеп, ул капчыкны вагонда яшерү изасы, билет тикшерүче ревизорларның җикеренүләрен һәм кыерсытуларын сөйләп тә, язып та бетерерлек түгел...

Сөнгатулла бабай 1938 елда икенче тапкыр кулга алынгач, тормыш арбасы яңадан Рәбига абыстай белән Габдерәшит җилкәсенә төшә. Салым, төрле займнар түләү – барысы да язмыш сынавына әверелә. Үз вакытында түли алмаган өчен алар җәмәгать эшләренә – тимер юл төзелешенә һәм башка төрле мәҗбүри хезмәткә тартыла.

Әлбәттә, «мулла малае» булуы аркасында аны, яше җитүгә карамастан, армиягә дә алмыйлар...

– Ниһаять, 1941 елның маенда безнең ишеләргә дә чират җитте, – дип искә ала иде әти. – «Хокуксызлар»ның наборы икән бу. Шунда сөенгәнемне күрсәгез: мин дә кеше рәтендә, янәсе! Көннәрдән беркөнне безне «тревога» белән күтәреп, мал йөртә торган вагоннарга төяп, көнбатышка алып киттеләр. Атна буе баргач, 2 июньдә Будслав[1] шәһәрчегенә китереп, поляк армиясенең ат абзарына кертеп тутырдылар...

Әти, гомумән, сугышта күргән-кичергәннәре турында еш искә ала иде. Хатирәләрен кәгазьгә төшергәнен дә күргәләдем, әмма язганнарын туплап бастырырга ул, ничектер, җөрьәт итмәде. Күптән түгел аның архивын күздән кичергәндә сугыш турындагы истәлекләренә тап булдым һәм аларны, беркадәр эшкәртеп, укучыларга тәкъдим итәргә булдым.

КЫРЫК БЕРНЕҢ ЭССЕ ҖӘЕ...[2]

Безнең бер мең ике йөз солдаттан торган эшче батальон 1941 елның май ае азакларында Казанда оештырылды. Подразделение, нигездә, шәхес культы елларында «халык дошманнары» балаларыннан тора иде. Алтынчы июньнән егерме икесенә чаклы, карьердан китерелгән дәү ташларны кувалда белән ваклап, шуңа ком һәм цемент кушып, ахыр чиктә хасил булган бетонны тигез итеп җәя идек. Биредә хәрби аэро-

[1] Бүгенге көндә Беларусьның Минск өлкәсендәге шәһәр.

[2] Алдагы текст, беркадәр кыскартылып, автор редакциясендә тәкъдим ителә. – Редакция.

дром буласы икән. Хезмәтебез гаять авыр иде. Бу вакыйгалар СССР җитәкчеләренең һөҗүмгә әзерлек алып барулары турындагы имеш-мимешләргә беркадәр ачыклык кертәдер. Советлар тарафыннан әле яңа гына басып алынган Көнбатыш Украина территориясендә хәрби аэродром төзү ошбу планнарны дәлилли.

22 июнь таңында «тревога» белән уяндык һәм марш ясап, кояш чыгышына таба атладык. Күктән – биектән, карга өередәй кубарылып, дошман самолетларының беренче дулкыны килә. Канатлары белән кояшны каплардай булып, көнчыгышка агылалар. Тавышлары – хәтәр, яман, хәвефле, баштарак хәтта тын алырга да кыймый торасың. Гүя тегермән ташыдай ниндидер авырлык сине һәм иптәшләреңне, бар дөньяны бастырып китәргә тели... Чигенү ачысы шулай башланды. Әле привал, әле сафка тезелү, алҗу-йончуны әйткән дә юк. Ул аягөсте йоклау һәм иң гаҗәбе – төш күрү! Шулай да була икән... Көн-төн чигенү фашистларның ут һәм ядрә яңгыры астында дәвам итә. Көтмәгәндә-уйламаганда, дошман самолетлары килеп чыга да хәрби колонналарны утка тота башлый. Алар шул дәрәҗәгә җиттеләр ки, шасси-тәгәрмәчләре белән сытардай булып, сугышчылар өстенә ташланудан да курыкмыйлар иде. Моторның үкерүе теш казналарына, үпкәләргә хәтле үтеп керә, йөрәкне талкый кебек. Тимер тырнакларын ыржайткан корыч кош күкне кыйгачлап аска томырыла, юлында очраган барлык тереклекне пулемет уты белән коендыра. Әйләнә-тирәне эре яңгыр бөртекләредәй бәргәләп, тетеп-чәрдәкләп бетерә. Бу хәвефле мизгелдә гомереңне секундлар хәл итә: йә берәр нгытма артына посып, яшеренеп исән каласың, йә, өлгермәсәң, бетәсең. Җимерек шәһәр һәм авылларны, күкрәп үскән иген кырларын дошман кулына калдыру бик аяныч иде. Әлбәттә, җан әрни, фашистка каршы нәфрәт көчәя. Чигенә барсак та, гитлерчыларга үлем әзерләп калдыра идек без. Саперлар җиргә күмеп калдырган һәм миналаган күпер, юллар дошманның байтак тере гаскәрен һәм техникасын күккә чөеп ташлады. Сапер бер генә ялгыша, диләр. Бу эштә кыюлык, төгәллек, салкын канлылык, сабырлык кебек сыйфатларга ия булсаң гына уңышка ирешәсең.

Атлый торгач, шактый ара үтелгән, Витебск-Орша арасында әрәмәлектә төн кундык. Иртәгесен, әле таң атмаган иде, батальон политругы Шаповалов безнең подразделениегә «145 нче аерым инженер-сапер батальоны» дигән исем бирелүе турында приказ укыды. Хәрби ант кабул иттек. Безнең төп бурычыбыз түбәндәгеләрдән гыйбарәт иде: оборонада торганда дошман кинәт үтеп кермәсен өчен чәнечкеле тимерчыбыктан киртә кую, миналар урнаштыру, гаскәрләребез чигенгәндә дошман тоткарлансын өчен юлларны миналау, күперләрне шартлату, һөҗүмгә күчкәндә су-елгалар аша күпер салу, дошман куеп калдырган миналарны эзләп табып зарарсызландыру, пехота, танклар һәм бөтен төр техника үтү өчен шартлар булдыру. Шуңа да карамастан, кулыбызга автомат яки винтовка бирергә ашыкмадылар. Әллә инде ышанып бетмәделәр? Һәрхәлдә, сугышның беренче айларында кулдан – лом, көрәк, чүкеч, балта ише эш кораллары аерылмады.

Безнең төп эш урыныбыз да нейтраль полоса иде. Алдыбызда – дошман позицияләре, тылда – НКВДның сак гаскәре (халыкта аны «заградотряд» дигән даны чыкты). Уртада без – саперлар мина кырлары ясыйбыз, гитлерчыларга тозак корабыз. Тылга таба чыгу катгый тыела. Шунда ук тотып атачаклар. Шулай бервакыт, иптәшебез яралангач, медсанбатка озата барырга, дип, бер юаш кына сугышчыны җибәргәннәр иде. Яралыны тапшырып частька кайтып барганда, бичара, заградотрядка очрап, харап булган. Командирыбыз аны эзли, кая югалуын ачыклый башлагач, югарыдагыларның берсе мәсьәләне куертмаска боерган.

Сугышның беренче айларында бик авыр мизгелләр күп булды. Аңлашылмаган чаклар да булгалады. Дошман техникасын үткәрмәс өчен, аның һөҗүм итү

юнәлешләрендә көрәк белән тирән котлованнар казыттылар. Эш шулчаклы авыр, хәтта ашаган ризык кире килә иде. Чокырның немец килә торган ягы – сөзәк, каршы ягы туксан градуска текә. Дошман танкы шул текә ярга килеп төртелеп туктап калачак, имеш. Әмма немец, безнекеләр уйлаганча, дивана түгел икән шул. Һөҗүм башланыр алдыннан фашист бомбардировщигы без атна буе газапланып казыган чокырның нәкъ уртасына бомба китереп сылый да, шартлау дулкыны белән күтәрелгән балчык аны тигезләп тә куя.

Июльдә батальон составында җимерүче-шартлатучылардан торган дүртенче рота сугышчылары Смоленск тирәсендә камалышта харап булды. Безне, ягъни беренче, икенче һәм өченче роталарны, машиналарга төяп, тылга күчерергә өлгерделәр. Шулай итеп исән калдык.

Кырык бернең июль-август араларында Умань шәһәре тирәсендә Көньяк фронтның 6 нчы һәм 12 нче армияләренең гитлерчылар корган тозакка эләгүе турында хәбәр иреште. Күп еллар узгач, «Умань чоңгылында» алты корпус һәм 17 дивизия, шул исәптә 18500 сугышчы һәлак булуы, йөз мең кызылармиячене әсирлеккә төшүен белдем. Менә шул коточкыч вакыйгалардан соң, Башкомандование «Хәрби хезмәттәгеләрнең әсирлеккә төшүе һәм дошманга коралларны калдыруы турында» 270 нче боерык чыгара. Аны Сталин, Молотов, Буденный, Ворошилов, Тимошенко, Шапошников һәм Жуков имзалый. Әлеге шомлы боерыкта сугыш кырында хәрби дәрәҗәләрен күрсәтүче билгеләрне җуярга ниятләгән командир һәм политработникларны, тылга дезертирлык кылучы һәм дошманга әсир төшүчене антын бозган һәм туган иленә хыянәт иткән, дип санарга, аларның гаиләләрен кулга алырга, диелгән иде. <...> Әлеге документ гади солдатны да, командирны да хәвефләндереп, коточкыч курку упкынына томырды. Бу куркыныч һәр гамәлеңне уйлап, аның нинди нәтиҗәләргә китерәчәген чамаларга өйрәтте.

БАШКАЛА ОБОРОНАСЫ...

Мәскәү янына кадәр чигендек. Волоколамск юнәлешендә ныклы оборона сызыгы булдырылды. Безнең подразделение Истра елгасы буенда һәм шул исемдәге кала тирәсендә оборонага урнашты. <...>

Оборона сугышларының кызган көннәрендә күктә дошманның моңарчы күренмәгән бер очкычы пәйда булды. Хикмәтле генә самолет иде бу. Крестьян ызбасының нәкъ тәрәз йөзлеге инде менә. Әлеге очкычны хезмәттәшләр «рама» дип бик урынлы атадылар. Менә шул коточкыч югарылыкта, артиллерия ала алмаслык биеклектә очып баручы «рама»дан бермәлне ак «яфраклар» коела башламасынмы! Алар безнең позициягә турылап җибәрелгән иде һәм берзаман тирә-юньне тутырды. Дәфтәр бите зурлыгындагы бу листовкаларда шигъри юллар укып алдык:

Слева – молот, справа – серп,
Это ваш советский герб.
Хочешь – жни, хочешь – куй,
*Все равно получишь х*й!*

Әлбәттә, әлеге листовкаларны кулга алырга да, укырга да катгый тыела иде. Политруклар аларны җыеп алып юкка чыгарырга ашыкты.

1942 елның яз-җәй айларында генерал Рокоссовский җитәкчелегендәге 16 нчы армия контрһөҗүмгә күчте. Бу чорда подразделениенең составы бик нык сирәгәеп калган һәм шуңа күрә яңа көчләр белән тулыландырылган иде. Батальонга сәясәткә мөнәсәбәте булмаган статьялар буенча хөкем ителеп, хәзер азат ителгәннәрне, шулай ук «төрмә стажы» шактый булган уголовникларны китереп тутырдылар. Ара-

ларында курку белмәс, «ташбаш» юлбасарлар да байтак булды. Алар үтеп баручы йөк машинасы әрҗәсенә сикереп менеп андагы товарны «үзләштерүдән» дә, юлда очраган крестьян хуҗалыгын «чистартып» чыгудан да тайчанмыйлар, ә инде әсирлеккә төшкән немец солдатын сугып егу, аның ранецын умырып алып «әрчү» – алар өчен пүчтәк бер гамәл иде. Шулар белән бергә, взводта бер бәндә пәйда булды. Аның кадәр алама, шапшак, тәртипсез адәм баласы да булыр икән, әйтерсең яңа гына чытырмандагы куыштан, җәнлекләр арасыннан якты дөньяга чыккан. Өстендәге гимнастеркасы, пилоткасы каралып-керләнеп беткән, аягындагы итекләре җир сөргән, диярсең. Кырынмаган-юынмаган чырай, сабын-мунчала күрмәгән муен-куллар – җирәнгеч инде! Авызын ачса да сүгенүдән башка сүз ишетмәссең. Хезмәттәшләр арасында да моның дәрәҗәсе бик түбән. Аның белән аралашу-сөйләшү түгел, янында торырга да риза булганнар сирәк иде. Шулай бервакыт привалга – ял итеп алырга туктадык. Мондый вакытта кем нәрсә белән мәшгуль: берәүләр ут ягып нәрсәдер ашарга әмәлли, берәүләр өйдәгеләренә хат яза, башкалар өс-баш киемен тәртипкә китерә, кайберәүләр чирәмгә сузылып черем итә. Тынлыкны кош сайраган тавышлар гына «боза». Менә безнең взвод урнашкан аланга ике сакчы (сугышчы) килде. Яннарында коралсыз-нисез, ләкин ыспай киемле япь-яшь немец солдаты бар. Озын буйлы, сары чәчләре таралып киткән, соры матур күзләрендә курку катыш билгесезлек белән мәрхәмәт сорап ялвару чагылган. Егетләрнең берсе:

– Менә каршыбызга кулларын күтәреп үзе килеп чыкты. Тентегән идек, коралын ташлап калдырган, кемнең «ауга» чыгасы килә? – дип сорады.

«Ау» дигәннәре – әсирне читкәрәк алып китеп атып үтерү... Штабка алып барып, тиешле документ-фәлән тутырып мәшәкатьләнгәнче, әсирләрне шулай җиңел юл белән генә «хәл итү» гадәти күренеш иде. Берәү дә бу эшкә катышырга җөрьәт итмәде. Һөҗүм вакытында, сугышта дошман белән күзгә-күз килгәндә бер хәл, ә монда... Ләкин теге вәхшигә шул җитә калды: сикереп торды да, винтовкасын алып, әсирне алдан куалый-куалый агачлар арасына алып китте. Күпмедер вакыттан мылтык тавышы дөньяны дертләтте. <...>

Сугышчылар арасында төрле халык бар. Үзенә бикләнеп – йомылып, беркем белән дә аралашмый йөргәннәр дә, шук холыклы, мәзәкчән егетләр дә юк түгел. Бер грузин малае бар. Хәрби әзерлек ягыннан әллә ни сәләте күренми моның, вәләкин артистлану, шамакайлану дигәндә коеп куйган сәхнә кешесе инде. Буш вакыты булдымы, берәр мөгез чыгармыйча калмый. Бервакыт бу туган якларыннан посылка алган, имеш. Кулында – картон тартма. Аны янтайткан иде, сыекча саркый башлады. Грузиядән чача[3] җибәргәннәр, янәсе! Шешәсе ачылып киткән дә, әрәм булмасын, дип, авызын чүмечләтеп чөмерә дә чөмерә бу. Соңыннан тартманы ачып караса, көчек килеп чыкты. Халык тәгәрәп китеп көлә, грузинның да түбәсе күккә тия язды.

Бервакыт гаскәребезгә бертөркем чит-ят кешеләр китереп куштылар. Сәер генә кавем иде бу. Урысча сөйләшсәләр дә, сөйләмнәре башкачарак, үз-үзләрен тотышында да сәер гадәтләре бар. Коралга – винтовка булсын, патрон булсын, граната – орынмыйлар. Урысның борынгы дин тотучылары, ягъни староверлар булып чыкты болар. Аларга сугыш коралына кагылырга диннәре кушмый икән. Сугышта аларны, нигездә, йөк ташучы итеп файдаландылар. Алтмыш-җитмеш килолы авыр пулеметның ыстаннарын аркаларына тагып куялар, шуны берсүзсез күтәреп баралар, тәмам хәлдән тайганчы, привалга кадәр йөртәләр, әмма анда да җилкәләреннән төшермиләр, шулай аскан килеш кенә берәр агачка сөялеп хәл алалар иде...

Командирлар арасында да төрлесе бар иде. Күбесе чын мәгънәсендә кайгырту-

[3] Чача – грузиннарның спиртлы милли эчемлеге.

чан, мәрхәмәтле, кешелекле иде, әмма араларында күрәләтә адәм баласын утка кертә торганнары да булды. Шул уңайдан, бер вакыйга истә калган. Кышкы айларның берсендә туң җирдә дошман куеп калдырган миналарны эзләп, зарарсызландырып йөрибез. Күптән түгел генә батальонга яңа сугышчылар килде. Алар әле тәҗрибәсез. Бездән ничек эш итәргә икәнен өйрәнеп киләләр. Сапер бер генә тапкыр ялгыша, дигән мәкальне отып алдылар үзе. Минаны саклык белән генә чистартып, боз-кардан аралап, запалын борып алырга, таба зурлыгындагы корпусын кубарып, зарарсызландырырга кирәк. Минаны «оя»сыннан чыгара алмаган очракта, токасына озын тимерчыбык бәйләп, үзебез ераккарак китеп, шартлатырга мәҗбүрбез. Шулай берзаман табылган минаны чыгара алмыйча бимазаланып ятканда, яңарак кына безгә билгеләнгән кызу канлы командирларның берсе:

– Вакыт әрәм итеп, нәрсә маташасыз анда,– дип җикеренде. – Кая әле, менә болай эшлиләр аны! «Таба»га ябышкан кантарга кулындагы сапер көрәге белән орынуы булды, дөнья коточкыч шартлауга күмелде. Биш-алты сугышчыбызның җаны күккә очты. Үзен дә өлешләп җыеп алып җирләдек. <...>

АДӘМ БАЛАСЫ САБЫР ДА, ЧЫДАМ ДА...

1942 елның июль башларында оборона тотканда фашист бомбардировщигы безнең гәскәр торган районга һөҗүм итте. Һәлак булучылар байтак иде. Рота парторгының гәүдәсен дә таба алмадык. Янныбыздагы бер таза гына егетнең (Башкортстаннан иде бугай, фамилиясе истә калмаган) сул аягы төптән үк өзелгән иде. Без аны плащпалаткага салып, медсанбатка алып киттек. Яралы шок хәлендә, берни булмагандай, безнең белән сөйләшеп бара:

– Егетләр, менә мин котылдым инде, сезнең дә шушы мәхшәрдә исән калуыгызны телим.

Бичара, шул хәлдә дә безне кайгырта бит! Күңелемнән аның исән-сау туган якларына кайтуын теләдем.

Кеше нинди генә мохиткa эләкмәсен, гаҗәп дәрәҗәдә түземлек, сабырлыкка ия икән. Моны үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм. Снаряд шартлау, пуля яңгыры бер нәрсә, һава шартларының кырыслыгы – җилле-яңгыры булсын, чатнама суыгы-эссесе булсын – адәм баласы барысына да яраклаша, чыдый икән.

Аллаһның рәхмәте, биш ел эчендә чирләмәдем дә, ныклап хаста да булмадым. Хәтеремдә 1942 ел. Сталинград даласында – кыш, тирә-юнь – кар көртләре. Буран, көчле дала җиле үзәкләргә үтә. Өстә – сырма телогрейка, бүрек, киез итек. Ашарга кирпеч ипи өләштеләр. Аны пычак белән кисәрлек түгел – боз булып каткан. Аптырагач, аркылы пычкы белән кисәбез дә, кайнар суда җебетеп ашыйбыз.

Төн кичәргә кирәк. Ачык кырда сиңа берәү дә урын-җир түшәп куймый. Кар көртен казып, плащ-палатка җәеп, шуңа сузылдык, өскә шул ук плащ-палатка яптык. Төнлә безне кар күмеп киткән. Иртән кар астыннын көчкә табып казып алганнар. Ничекләр исән калганбыз: колак ишетә, гәүдә үзе юк шикеллерәк – җылысы беткән. Өстерәп чыгардылар. Карда әвәли торгач, җан керде тагы. Иң гаҗәбе – аннан соң ник беребез төчкерсен!

Йокы мәсьәләсе дә гаять мөһим. Кайвакыт ару-талу шул дәрәҗәгә җитә иде ки, гәүдә, әгъзаларың сиңа буйсынмый башлый. Марш-бросок вакытында сафта барган шәпкә күзләр йомылып, йоклап киткән һәм нәкъ шул мизгелдә төш күргән чаклар да булгалады. <...>

Ахыры киләсе санда ■

Истә, һаман да истә!

Драматург Галиәсгар Камалның тууына 140 ел

Татар әдәбияты классигы, драматург, шагыйрь, публицист, җәмәгать эшлеклесе, Хезмәт Батыры (1923) Галиәсгар Галиәкбәр улы Камал (Камалетдинов) 1879 елның 6 гыйнварында (искечә 1878 елның 25 декабрендә) хәзерге Арча районының Сикертән авылында туа.

Сабый вакыты әнисе Мәүгыйзәнең туган җире Түбән Масра дигән авылда (Татарстанның хәзерге Арча районы) әби-бабалары тәрбиясендә уза.

1898 елда «Бәхетсез егет» дип исемләнгән тәүге драмасын яза. Күп тә үтми, «Өч бәдбәхет» дигән икенче пьесасын да иҗат итә.

1912 елның көзендә Балкан берлеге дәүләтләре (Болгария, Греция, Сербия, Черногория) белән Төркия арасында тарихта Икенче Балкан сугышы дип йөртелгән низаг башлангач, «Йолдыз» газетасы идарәсе Г.Камалны Төркиягә үзенең махсус мөхбире итеп җибәрә.

Үзе исән чагында Г.Камалның ике томнан торган әсәрләр җыелмасы нәшер ителә.

1939 елдан татарның төп – Татар академия театры драмтургның абруйлы исемен йөртә башлый.

Г.Камал 1933 елның 16 июнендә 54 яшендә Казанда вафат була.

Рәссам Фәрит Суюровның тууына 80 ел

Күренекле рәссам, график, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2007), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Бакый Урманче исемендәге премиясе лауреаты, Россия Сәнгать академиясенең алтын медале иясе Фәрит Габдрахман улы Суюров 1939 елның 7 гыйнварында Казан шәһәрендә туа. 1962 елда Казан сәнгать училищесын, 1969 елда исә Чуашстан дәүләт институтын тәмамлый.

1992 елдан Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы.

2009 елда «Туган як табигате» рәсемнәр шәлкеме (2007-2008) өчен Ф.Суюровка Татарстан Мәдәният министрлыгының Бакый Урманче исемендәге премиясе бирелә.

Фәрит Габдрахман улының картиналары Төркия, Финляндия, Голландия, Бөекбритания галереяларында саклана.

Рәссам 2016 елда вафат була.

Безнең мирас №1 гыйнвар 2019

Шагыйрь Фатих Кәримнең тууына 110 ел

Совет чоры поэзиясенең күренекле вәкиле, шагыйрь Фатих Әхмәтвәли улы Кәрим (Кәримов) 1909 елның 9 гыйнварында Россиянең элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязе (хәзерге Башкортстан Республикасының Бишбүләк районы) Ает авылында мулла гаиләсендә туа.

1925-1926 елларда Казан җир төзелеше техникумында укый. Әдәби иҗат белән җитди шөгыльләнә башлавы да шушы студентлык елларына туры килә.

Ф.Кәрим – 1934 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Әдип 1942 елның февраленнән 1945 елның февраленә кадәр фронтның алгы сызыгында була, ике тапкыр яралана, шәхси батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә.

Ф.Кәримнең сугыш тынган араларда солдат землянкалары, окоп ышыкларында иҗат иткән лирик шигырьләре, «Гөлсем» (1942), «Идел егете» (1942), «Кыңгыраулы яшел гармун» (1942), «Үлем уены» (1942), «Партизан хатыны» (1943) һәм «Өмет йолдызы» (1944) дигән поэмалары, «Тимер һәм тимерче» кебек балладасы (1942), Муса Җәлилнең Моабит циклы шигырьләре белән бергә, сугыш чоры татар поэзиясенең иң югары ноктасын тәшкил итә.

1945 елның 19 февралендә Көнчыгыш Пруссиядәге соңгы сугышларның берсендә утыз алты яшьлек шагыйрь дошман пулясыннан һәлак була.

Актер һәм режиссер Хөсәен Уразиковның тууына 125 ел

Күренекле актер һәм режиссер, ТАССРның халык (1945), РСФСРның атказанган (1950) артисты, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Хөсәен Ибраһим улы Уразиков 1894 елның 19 гыйнварында Сарытау губернасы Дергачев өязенең (хәзерге Сарытау өлкәсенең Дергачев районы) Сәфәр авылында туа. Ул Самара хәрби округы каршындагы татар музыка-драма студиясен беренчеләрдән булып тәмамлый (1920).

Мәскәү консерваториясе каршында ачылган татар студиясендә Газиз Айдарский, Сара Садыйкова, Гөлсем Камская һәм Асия Измайловалар белән бергә укый.

Хива, Бохара, Ташкент, Верный (Алма-Ата), Пишпек (Бишкәк), Ырынбур, Мәскәү һәм Әстерхан татар театрларында эшли.

Хөсәен Уразиков 1930 елдан – Казандагы Татар академия театрында. 1944-1948 елларда режиссер вазыйфасын да башкара.

1936-1965 елларда Казан театр укуханәсендә укыта.

1977 елда Казанда вафат була.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Кереш

Кышкы салкын кич. Авыр кара болытлар арасыннан ара-тирә генә тулган ай һәм якты йолдызлар күренеп китә...

Берничә йөз елларга сузылган шушындый салкын, җансыз төннәрдә халкыбызның ачы язмышын курай, кубыз, гөслә, думбыра һәм тагын бик күп музыка уен кораллары уртаклашты. Алар еладылар, чеңләделәр, сындылар, изелделәр, әмма үлмәделәр, ачы язмышларына буйсынып, чорма-чоланнарда, халык хәтерендә озак еллар тынып тордылар. Моңлы кылларын сыйпап, «тән»нәренә җан өреп, халкыбызның мәңге үлмәс Ялчыголлары, Габәшиләре, Исмәгыйльләре[1], Фәйзуллалары, Ифратлары[2] һәм тагын бик күп каһарман шәхесләребез кадерләп саклап калды аларны...

[1] Галим һәм әдип Таҗетдин Ялчыгол, беренче профессиональ композитор Солтан Габәши, курай остасы Исмәгыйль Мусин.
[2] Гармунчы Фәйзулла Туишев, курай ясаучы Ифрат Хисамов.

***

Мин Арча районының Симетбаш авылында туып үстем. Авылыбыз кечкенә булса да, аның кешеләре бик кызыклы һәм талантлы. Әлегәчә хәйран калып искә алам. Алар миңа никадәр тормыш гыйлемен, халык иҗатын өйрәткәннәр. Истә, һаман да истә: алты-җиде яшьлек чагымда, иртәнге караңгыда кулыма намазлык тотып авыл буйлап гает буласы урынны эзләп йөрүләр (авылда мәчет юк иде), көтү көткәндә саламнан камыл курай, тал ботакларыннан сыбызгы ясап сызгырту, каз өмәләрендә куык кабарту, каурыйдан сыбызгы ясау (мин аны кемнәндер күреп үзләштергәнмен ләбаса), аулак өйләрдә яшьләрнең кызык, тапкыр сүзләре, үз-үзләрен тотышлары, Сабан туйларында, бәйрәмнәрдә гармун уйнап урам әйләнүләр... Авылда берничә малай, ярыша-ярыша, гармунда уйнарга өйрәндек. Әти унике сумга Арчадан өр-яңа тальян алып кайтып бирде. Әй аңа куанулар!..

Иҗатымның чишмә башы туган ягымнан башланды, дисәм дә, ялгыш булмас. 1975 елда мәдәният институтын тәмамлап, Арча районы мәдәният йортына эшкә кайттым. Халык музыка уен кораллары оркестры җитәкчесе булып эшли башлагач, инде онытылган яисә халык оныта барган уен коралларын эзләп табарга, оркестрда кулланырга керештем. Алар ул вакытта бу тирәдә сирәк-сорак булса да очрый иде әле.

Шулай итеп, төрле зурлыктагы концерт гармуннары, мандолина, гөслә, ятаган, капчыклы куш сорнай, сорнай, көтүче быргысы, курай, камыл курай, чыгыр, кырлы бәләк, думбыра кебек уен кораллары белән бик якыннан танышырга, хәтта күбесен үземә дә ясап карарга туры килде...

1983 елда Казанга күченеп, Республика фәнни-методик үзәгендә фольклор секторы мөдире булып эшли башлагач, мине татар дөньясында милли музыка уен коралларының бик аз булуы гаҗәпсетте. Фольклор музыка сәнгатендә ул елларда баян, тальян гармун, курай, кубыздан башка уен кораллары кулланылмый иде. Берничә меңьеллык тарихы булган татар халкы курай-кубызда гына уйнамагандыр ләбаса?!.

Шундый уйлар мине эзләнүгә этәрде...

Татар халкының музыка уен кораллары әле бүген дә бик аз өйрәнелгән. Фәнни хезмәтләрдә дә, көндәлек матбугат битләрендә дә алар турында гомуми мәгълүмат кына бирелә яки исемнәре генә әйтеп кителә. Гомумән, элек-электән бу төр уен коралларының торышы милләтпәрвәр музыкантларның эшчәнлегендә генә чагылыш тапкан. (Бу хәл хәзер дә шулай дәвам итә.) Әйтик, фольклорчы галимнәр Таҗетдин Ялчыгол, Солтан Габәши, Рәгъде Халитов, данлыклы гармун осталары – бертуган Вараксиннар, Фәйзулла Туишев, Ринат Вәлиев, курай осталары – Солтан Габәши, Исмәгыйль Мусин, Ифрат Хисамов, Рафаил Гайзетдинов һәм тагын байтак шәхесләребез дәүләттән бер тиен дә матди ярдәм алмыйча иҗат итте. Шулай да, аларның хезмәтләре бүгенге һәм киләчәк галимнәр өчен әйтеп бетергесез зур нигез булып тора. Киләчәктә аларның иҗатларына дөрес бәя бирелер әле.

Фәнни-методик үзәктә эшләгәндә миңа күп фольклор фестивальләре оештырырга, төрле авылларга барып эшләргә туры килде. Шунда абый-апалар белән кич утырулар, аларның яшь вакыттагы җырлы-биюле уеннарын, яшьлек хатирәләрен искә төшерүләр күпме булды! Никадәр рухи байлык тупладым мин ул елларда! Бу эш миңа киләчәктә эшләү өчен әйтеп бетергесез тәҗрибә бирде. Шул елларда гына да халыктан инде онытыла барган 200ләп җыр язып алдым. 1982 елда Казандагы Сәүдә хезмәткәрләре мәдәният йорты каршында оешкан «Сорнай» ансамбле ул җырларның барысын да тамашачыга җиткереп торды. Чөнки алар – халыкның үзенеке, үз бәгыреннән өзелеп чыккан җырлар иде: «Ай, дубыр-дубая», «Нигә яна

йөрәгем?», «Әнә шул сүзең», «Әңгер-гер-гер, күә-күә», «Әннәги»... Дистәләгән йола күренешләре, алар арасында «Болгар хатирәсе», «Уңыш теләү», «Сөрән сугу», «Нәүрүз», «Бәрмәнчек», «Нардуган», «Чир куу», «Хан кызы», «Кыз озату», «Кыз елату», «Мәңгелек күк», «Болан кыз риваяте», «Кичке уен», «Аулак өй», «Төйдереп бию» кебек әсәрләребез Татарстан радиосы һәм телевидениесе фондларында саклана һәм әледән-әле эфир аша яңгырап тора.

Тагын горурланырлыгы: «Сорнай» фольклор ансамбле кыска гына вакыт эчендә үзенең репертуарына татар халкының алтмышлап традицион музыка уен коралларын туплады! Думбыра, саз, гөслә, ятаган, кылкубыз, сорнай, тел курае, мөгез, аучы быргысы, таш сыбызгы кебек уен коралларын сәхнәгә иң беренчеләрдән булып «Сорнай» ансамбле алып менде һәм бүген дә аларны пропагандалау белән шөгыльләнә. Әлеге уен коралларының байтагы хәзерге көндә урта һәм югары махсус уку йортларында, үзешчән һәм профессиональ ансамбльләрдә файдаланыла, өйрәнелә.

***

Татар тарихында төрле чорлар булган... Илнең чәчәк аткан чоры да, дәүләтчелеген югалткан чоры да. Тын океаннан алып Дунай буйларына кадәрле җирләрдә сибелеп, бер урыннан икенче урынга күченеп яшәгән ул. Әлбәттә, яшәү урыны һәр халыкның мәдәниятенә, яшәү рәвешенә нык тәэсир итә. Шуңа да татар музыка уен коралларының исемнәрендә дә, формаларында да, ясау өчен материал сайлаганда да, уен алымнарында да гомум төрки һәм төрки булмаган күрше халыклар уен коралары белән зур охшашлыклар бар. Дөньяда бер генә халыкта да: «Бу безнеке генә!» – дип, күкрәк сугарлык уен коралы юктыр. Шуңа күрә, минем фикеремчә, думбыра – казакътан, гармун – алманнан, саз – Ираннан, гөслә – тагын әллә кайдан килеп кергән, дип вәсвәсәгә бирелергә кирәкми. Меңнәрчә ел дәвамында теге яисә бу уен коралыннан файдаланган һәрбер халык әлеге уен коралларын авыз тутырып үзенеке дип атарга хаклы.

Безнең ата-бабаларыбыз музыка уен коралларын табигатьнең үзеннән алганнар. Әйтик, каз каурыен кыеклап кисеп, сыбызгы ясаганнар, җәяне чиертеп, көй чыгарганнар, кура үләне алар кулында курайга әверелгән... Заманалар уза торган саен, музыка уен кораллары да камилләшә төшкән, яңалары барлыкка килгән, шул ук вакытта, искеләре дә онытылмаган...

Музыка уен коралларының килеп чыгышын күп очракта дин һәм сугыш белән бәйлиләр. Бәрмә, кыллы уен кораллары иң беренче чиратта төрле дини йолаларны үтәү өчен кулланылган. Аннан соң гына, аерым төрләре барлыкка килеп, алар күңел ачу чарасына әйләнгәннәр.

Музыка белгечләре һәр халыкның музыка коралларын берничә төргә бүлеп өйрәнәләр. Татар инструментлары өчен ул бүленеш моннан гыйбарәт:

а) кыллы уен кораллары: думбыра, саз, гөслә, ятаган, кылкубыз;

б) тынлы уен кораллары: курай, сорнай, быргы, таш сыбызгы;

в) телле уен кораллары: кубыз, гармун, баян;

г) бәрмә уен кораллары: чыгыр, кырлы бәләк, барабан, бубен.

Һәр халыкны халык итеп таныткан музыка уен коралы – ул, әлбәттә, кыллы уен кораллары. Көчле милли аңлы булу өчен, милләткә – тел, дин, моң гына җитми, аның милли уен кораллары да булырга тиеш. Игътибар итсәгез, һәр мөстәкыйль дәүләтнең үз милли оркестры бар. Оркестрның нигезен, күп очракта, кыллы уен кораллары тәшкил итә. Шуңа да мин татар халкының, беренче чиратта, кыллы уен коралларын тирәнтен өйрәнеп, дәүләт күләмендә милли уен коралларыннан гына тор-

ган оркестрыбызның булуын теләр идем. Татар милли уен кораллары оркестрының үзәген саз, думбыра, кылкубыз, гөслә кебек уен кораллары тәшкил итә алыр иде...

Алда искәртелгәнчә, татар халык музыка уен коралларының күбесе кулланудан күпмедер вакытка төшеп, онытылып торган. Сакланып калганнарының исә ясалу технологиясе бик гади һәм аларда уйнау традицияләре дә искиткеч түгел. Ни өчен? Беренчедән, музыка уен коралларын сыйфатлы итеп ясау өчен, күптөрле махсус эшкәртү әсбаплары, аерым детальләрне җыйнау өчен, төрле җайланмалар, калыплар кирәк. Ничекләр генә терсәгеңне тешләргә теләсәң дә, андый уен кораллары мөстәкыйльлеген җуйган татар иле осталарында була алмаган. Вакытында татар йортларында пычак тотарга да рөхсәт ителмәгән, юкса. Шуны онытмыйк! Тик моңа да карамастан, халык осталары, ничек тә җаен табып, бик үк сыйфатлы булмаса да, музыка уен коралларын ясый, аларда уйный белгәннәр...

Җөмләдән, урыс халкының үзендә дә музыкага битараф булмаган фидакарьләр XIX йөз ахырларында гына күренә башлый. Беренче балалайканы коми остасы С.И.Налимов, 1895 елда В.В.Андреев биргән сызымнар буенча, коми халкының өч кыллы «ас вочом» дип аталган уен коралы нигезендә ясый. Сер түгел: В.В.Андреев Россиянең урыслар яшәгән бөтен төбәкләрен кичеп, балалайкага охшаган уен коралын таба алмый. Кылларының көйләнелеше дә (соль-ре-ре) коми халкының «сигудок» дигән уен коралыннан алынган. Соңрак, 1896 елда әлеге С.И.Налимов, шул ук В.В.Андреев биргән сызымнар буенча, беренче урыс домбрасын ясый. Аның үрнәген дә В.В.Андреев – Нократ, Идел буенда яшәүче халыклардан,ягъни татар, нугай думбырасыннан ала.

Шул ук елларда, Европадан кергән гармоника нигезендә, урыс осталары төрле гармуннар, хромка, баян ясый башлыйлар. Соңга табарак әлеге музыка уен коралларында, теләсә-теләмәсә дә, СССРда гомер кичергән барлык халыклар уйный башлый. Шулай итеп, татар тормышында думбыраны – балалайка, сазны – мандолина, кылкубызны – скрипка, сорнайны – жалейка, курайны – свирель, тарны – гитара («гитара» сүзе шулай ук төркидән алынган: «ги» – «ике», «тар» – «савыт» дигәнне аңлата) алыштыра. Совет хакимияте елларында балаларны, көчләп диярлек, музыка мәктәпләрендә, югары уку йортларында әлеге инструментларда уйнарга өйрәтәләр, укыталар, бу коралларны пропагандалыйлар. Ләкин СССР таркалгач, урыс халкының үзенә дә мондый уен коралларының кирәге калмады. Сүз дә юк, әлеге уен кораллары эшләнелеше, тавышының көче, уйнау мөмкинлекләре буенча бик яхшы уен кораллары, әмма аларны халык үз итмәде, алар халыкныкы түгел. Алар хәтта урысныкы да булып чыкмады. Гомумән, бик күп халыклар Совет чорында милли уен кораллары белән бихисап экспериментлар ясады. Аннары, озак еллар адашып йөргәннән соң, алар барыбер үзләренең традицион уен коралларына әйләнеп кайттылар...

Шул ук вакытта, Россиядә безнең белән иңгә-иң яшәгән халыклар да бүген бу өлкәдә җиң сызганып эшли. Мәсәлән, күрше башкорт халкы (беренче чиратта Башкортстанның дәүләт җитәкчеләре), шул ук совет чорында, конкрет бер уен коралын – курайны, вакытында күреп, сайлап алдылар. Бик акыллы рәвештә, шауламыйча гына, курай ясаучыларны, уйнаучыларны кызыксындырдылар (әйтик, фатир яисә дәрәҗәле исем юнәтү белән). Иң зур сәхнәләрнең түрендә курайга урын бирелде. Балаларны музыка мәктәпләрендә Башкортстан Мәгариф министрлыгы төзегән махсус программа нигезендә укыттылар. Югары сәнгать уку йортларында курай класслары ачылды. Нәтиҗәдә, курай – башкорт халкының горурлыгына, дөнья халыкларын сокландырырлык милли музыка уен коралына әверелде. Башкортстанда мондый ярыш хәзер дә дәвам итә. 1992 елда Уфа дәүләт сәнгать институты каршында музы-

ка уен коралларын ясау буенча махсус остаханә оештырылды. Анда хәзер дә башкорт думбырасын, кылкубызны, әле тагын байтак кына музыка уен коралларын торгызу эше алып барыла.

Тыва Республикасының эшләренә дә сокланырлык. Биредә халык музыка уен коралларыннан гына торган 60 кешелек милли дәүләт оркестры төзелде. Әлеге оркестрның беренче җитәкчесе бүгенге көндә мәдәният министры булып эшли. Республикада алдагы елларның берсе милли уен коралы хөрмәтенә «Игил елы» дип игълан ителде. Инструментка нинди хөрмәт, күрәсезме?!

Якут халкының хезмәте дә олы хөрмәткә лаек. 1988 елда фольклорчы галим Иван Егорович Алексеев дөнья халыкларының хомуз һәм шуңа охшаган уен коралларын җыя, бергә туплый башлый һәм дөньяда иң зур хомуз музеен хасил итә. Ул беренче тапкыр хомуз уен коралының концепциясен төзи, аны ясау һәм башкару мәктәбен булдыра. Аның башлангычында Якутск каласында, СССР Композиторлар берлеге белән берлектә, хомузчыларның Беренче Бөтенсоюз конференциясе үткәрелә. Шул ук вакытта, И.Е.Алексеев, Якутиядә яшәгән иң оста хомузчы виртуозларны бергә туплап, хомузчылар ансамбле төзи. Нәтиҗәдә, сыйфаты буенча да, уйнау осталыгы буенча да дөньяда тиңе булмаган хомуз уен коралы торгызыла. Менә бу, ичмасам, республика җитәкчеләре тарафыннан да, фидакарь музыкантлар тарафыннан да музыка уен коралына карата күрсәтелгән игътибар, батырлык! Бүген хомуз – якут-саха халкының милли горурлыгы. Минем бу сүзләргә ышану өчен, Якутия-Саха Җөмһүриятенең «Аййархан» хомузчылар ансамблен генә күрү яисә тыңлау да җитә...

И, адәм баласы!..

Әгәр дә син нинди дә булса музыка уен коралын яңадан халыкка кайтарырга, аны ясарга ният кылгансың икән, бу – бик мәртәбәле эш, Аллаһ Тәгалә тарафыннан бирелгән вазыйфа, дип кабул ит. Шушы уен кораллары аша син күпме кешенең күңел түренә үтеп керәчәксең, аларның зәвыгына тәэсир итәчәксең! Шуңа күрә дә син ясаган инструмент затлы, сыйфатлы булырга тиеш.

Күкләрдән бирелгән сәләт булмыйча торып, «мин фольклорчы, музыка белгече яисә артист булам», дип, никадәр генә белем эстәсәң дә, тәгаен, берни барып чыкмаячак. Су өстендә йөзеп йөргән йомычкалар кебек, бу мавыгулар вакыт белән агып бетәчәкләр. Һәр профессияне сайлаганда да шул ук хәл күзәтелә. Мин бу урында татарга аеруча файда китерерлек сәләтле, белемле белгечләрне күздә тотып әйтәм. Алар уен коралларының тарихын да, җырлы-биюле уен йолаларын да, башкару үзенчәлеген дә бик яхшы белергә, халыкка, аерата яшьләргә дөрес фольклор үрнәкләрен тәкъдим итәргә, үзләрен аңлый торган артистларны, осталарны туплый, ияртә алырга, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр белән уртак тел таба белергә һәм алар алдына мәсьәләне кирәкле дәрәҗәдә кискен итеп куя белергә дә тиешләр. Шушы сыйфатларның берсе генә үтәлмәсә дә, уңай нәтиҗә чыкмаячак.

***

Безнең әби-бабаларыбыз борын-борыннан ук уен кораллары ясарга, оста итеп уйнарга, җырларга омтылганнар. Булган йорт-җирләрен, бердәнбер атын, сыерын сатып музыка уен коралы алган очраклар күпме тарихта?! Беркем дә аларны мәҗбүр итмәгән. Соклану яусын аларга!

Бернинди тыюлар, авырлыкларга карамастан, татар үзенең рухиятен өстен куйган. Иң авыр елларда да суфый музыкантларыбыз, уен коралларын шәрык илләреннән кайтарып булса да, уйнаганнар, халыкка тыңлатканнар. Мисал итеп Акмулла, Утыз Имәни иҗатларын гына искә төшерү дә җитә.

Хәтта фашист концлагере тоткыннарының, җәлилчеләрнең дә консерв банкасыннан думбыра ясап уйнаганнары билгеле...

Аллага шөкер, бүген дә уйныйбыз. Талантлы гына яшьләребез дә бар. Яхшы сыйфатлы уен кораллары да табып була. Күп булмаса да, андый уен коралларын ясаучы осталарыбыз, кызыксынучы белгечләребез бар. Мин дә, үз чиратымда, татар халкының музыка уен коралларына битараф булмаган яшьләргә чак кына булыша алсам, бик бәхетле булыр идем. Шул теләктә әлеге хезмәтемне тәкъдим итәм.

Бу язмам фәнни эш буларак түгел, ә музыка уен коралларына кызыксыну уяту, аларны көндәлек тормышта куллану, үзлектән ясау, уйнарга өйрәнү һәм яшьләргә өйрәтү максатыннан кулланма буларак тәкъдим ителә...

Татар милли уен коралларын тирәннәнрәк өйрәнүне максат иткән яшь белгечләргә мин, беренче чиратта, мондый сорауларга төгәл җавап табудан башларга киңәш итәр идем. Син кызыксынган уен коралы хактан да татар музыка уен коралымы? Һәм аны нинди чыганакларга таянып исбатларга мөмкин? Ошбу хезмәтемдә мин дә әлеге сорауларга булдыра алган кадәр җавап бирергә тырыштым.

Татар халык авыз иҗаты әсәрләрендә (әкият, дастан, табышмак, җыр һ.б.) нинди уен коралларының исемнәре телгә алына һәм аларны ничек күзалларга? Фәнни һәм әдәби чыганакларда да уен кораллары, аларның исемнәре турында күп белешмә алып була. Әйтик, X гасырга караган Әбү Насыйр әл-Фәраби хезмәтләре, XIII гасырга караган «Кодекс Куманикус» («Команнар мәҗмугасы»), борынгы Болгарга килеп киткән сәяхәтчеләр Ибн Фадлан, француз монахы Рубрухвис язмалары, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре, «Идегәй» дастаны һәм тагын күп кенә чыганакларда шул чорларга караган уен коралларының исемнәре телгә алына, аларның нинди максатларда кулланылганнары да тасвирлана. Аннан да зур байлыгыбыз – күренекле галимнәребезнең, этнограф-фольклорчыларыбызның төрле елларда берәмтекләп җыйнап, туплап чыгарган фәнни хезмәтләре, билгеле.

Бу хезмәтемдә мин «Сорнай» ансамбленең үз көче белән 40 ел эчендә туплаган тарихи, фәнни эзләнүләрдән туган хезмәтләрен, репертуарын (бигрәк тә музыка коралларына кагылышы булганнарын) күрсәтергә тырыштым. Без аларны төрле елларда халыктан, төрле әдәби, тарихи чыганаклардан язып алдык, тамырын өйрәнергә тырыштык, үзебез ясап карадык һәм күбесен ансамблебезгә туры килерлек итеп сәхнәләштердек. Кайбер урыннарда төгәлсезлекләр дә китәргә мөмкин, анысын сез, хөрмәтле укучылар һәм Тарих галиҗәнаплары кичерсә иде, чөнки бу – безнең туктәлмас эш процессы. Аннары, күп кенә музыка уен коралларын тарихи яктан өйрәнү, аларны дәлилләү, уйнау алымнары, тагын да камилләштереп ясау технологиясе (формасы, үлчәмнәре, ясар өчен материал сайлау) әле дә дәвам итә. Шуңа да уен коралының кайбер өлешләренең ясалу тәртибен бик тәфсилләп узмаска тырыштым. Үзегез ясарга теләсәгез, курыкмагыз: эзләнегез, үзегезчә ясап карагыз! Чөнки һәр оста гомер-гомергә музыка уен коралын хәленнән һәм осталыгыннан килгәнчә ясаган...

Хәерле сәгатьтә!

Ринат Гыйләҗев,
«Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

Дәвамы бар ■

ӘХӘТ ГАФФАРГА – 70 ЯШЬ!



Хикмәтле хатлар



Кайчагында, элеккеге кәгазьләр арасыннан берәр кирәге чыкканын эзләгәндә, онытылып беткәннәре дә килеп чыккалый. Арада инде сагындырганнары да булгалый. Кулга алгач, ирексездән, истәлекләргә дә бирелеп киткәлисең. Шундыйлардан, менә, театр режиссеры Гали Кәрим улы Хөсәеновның үземә язган хатлары шактый ук кызыклы булып тоелды әле.

Ул – Гали ага Татарстан радиосында, телевидение, театрларында күп спектакльләр куйган күренекле иҗади шәхес иде, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Драматурглар А.Гыйләҗев, Т.Миңнуллин белән ифрат күп аралашты, эш итте. Иҗаты, асылда, Станиславский һәм Немирович-Данченко, МХАТ театры калыбынчарак иде. Заманында МХАТ, бөтен Советлар Союзындагы театрлар өчен өлге сыйфатында булып, бүтәнчәрәк әсәр икән, сәхнәләштерелгән сурәттә дә репертуардан тиз көндә төшереп калдыру очраклары шактый еш булды. (Әйтик, шулай Аяз абый Гыйләҗевне шактый тинтерәттеләр.)

Гали ага, исемдә калганча, кешелекле, олы җанлы, зыялы зат иде. Аның ошбу сыйфатлары тәкъдим ителә торган хатларында да ап-ачык беленеп, хәтта күренеп үк, дигәндәй, байтагыбызга – яшь каләм ияләренә аеруча – үрнәк сыйфатында ярылып ята. (Дөрес, аларда хакыйкатькә туры килеп бетмәгән бәхәсле урыннар да бар).

Укып карыйк әле: 40 елдан соң күренекле татар режиссеры Гали Кәрим улы Хөсәеновның мирасы ниндиерәк икән? Ә ул телсез күке түгел иде, һич түгел!

Әхәт Гаффар

I / II-78

Исәнмесез!

Әхәт, Сезгә бик күп сәлам белән Гали абыегыз. Сездән пьеса көтә идем. Шуңа күрә һәр көнне истә идегез. Кичәге «Соц. Татарстан» газетасында «Сәхнәне ярату» дигән мәкаләгезне (Р.Хәйретдинова турында) укып, пьесаны көтүне тагын ашыктырды. Шаять, шушы көннәрдә алырмын, дип уйлыйм.

Мәкаләгез ошады. Ләкин моннан алда язганнарыгыздан С.Шәкуров турында язганыгыз күбрәк ошаган иде. Ул үзәнчәлекле язылган, моңа кадәр газеталарда күренгән портретлардан бик нык аерылып тора иде. «Соц. Татарстан» газетасындагы «Сәхнәне ярату» дигән мәкаләнең авторына тагын бер тапкыр күз төште. Карасам, ул икенче авторныкы, ягъни икенче Гаффарныкы икән, гафу итегез.

Әхәт, бәлки тагын бер кеше портретына игътибар итәрсез. Дөрес, аның мактаулы исеме юк. Кайчак, чәче белән җир себерсәләр дә, кайбер кешеләр андый исемнәр алу бәхетенә ирешә алмыйлар. Юк, сәбәп лаеклы булмаудан түгел, кешенең характерындагы кайбер сыйфатларның җитәкчеләргә ошамавыннан да була. Йөзенә карап әйтү, туры әйтү һ.б. һ.б. Ә туры әйткән туганына да ярамаган, диләр. Кыскасы, ул кеше – Зәйтүнә ханым Хәлиуллина. Мин аны

Сезнең мәкаләне укыгач, искә төшердем. Аның белән 50 нче елларда Күчмә театрда эшләгән идек. Аның 1918 нче елда туганын беләм. Кайсы айда туганын гына хәтерләмим. Ул ярлы крестьян семьясында дөньяга килгән. 3 яшьтә әтисез калган (шахта басып үтергән). 6 яшьтә әнисе дә вафат булган. Башта Чистайда, аннан Уралда Губаха шәһәрендә балалар йортында тәрбияләнгән. Театр училищесын тәмамлаган. 3,5 ел Бөек Ватан сугышында булган (зенитчица), 25 ел республика Күчмә театрында артистка булып эшләде. Соңгы 8 елында Академия театрында спектакльләр текстын рус телендә укып баручы булып эшләде. Аннан, сәламәтлеге начар булу сәбәпле, пенсиягә чыкты. Хәзер Казанда (420021. Казань-21, ул. Татарстан, 52, кв.173) ялгыз яши, беркеме дә юк. Сугыш аның сәламәтлеген, яшьлеген, мәхәббәтен урлаган. Күчмә шартларда 25 ел буе эшләү дә тәэсир иткәндер.

Хезмәте зур булган ул кешенең. Шуңа күрә газета битләренең берсендә аны искә алу гөнаһ булмас иде, дип уйлыйм. Бәлки сәламәтлегенә дә дәва, фаҗигале язмышына якты нур булыр. Кеше өчен күп нәрсә кирәкми бит, кайчагында бер җылы сүз дә җитә!

Бәхетле язмышлы кешеләр турында күп сөйлибез, бәлки, бәхетсез язмышларны да телгә алырга кирәктер. Кеше үз-үзен аямыйча эшләгән, Ватан куркыныч хәлдәге елларда иң хәвефле җирдә – сугышта булган, бар эшен дә чын йөрәктән бирелеп эшләгән!

Менә, Әхәт, бәлки бу кешегә дә игътибар итеп, тагын бер изге эш эшләрсез.

Газетагыз битләрендә безнең театрга игътибарыгыз өчен барлык иптәшләргә бик зур рәхмәтебезне белдерүегезне үтенәм. Спектакльләрдән күренешләр (фотолар) җибәрә торган гадәтебез бар иде. Шул фотолар да күренсәләр, без тагын да шат булыр идек.

Тагын бер тапкыр кайнар сәлам, тирән ихтирам белән,
эшегездә зур-зур иҗади уңышлар теләп калучы,
Г.Хөсәенов.

5 / IV-78

Исәнмесез!

Әхәт, Сезгә бик күп сәламнәремне һәм иң изге теләкләремне юллыйм.

«Пәрәвезле күз читендә» исемле драмагызны укып чыгып, фикер алыштык. Мин үзем Сезнең иҗатыгызның икече җимеше белән таныштым. (Җәмилә Кумысниковадан алып, Күчмә театр куячак – ул вакытта Күчмә театр куймаган иде әле. – *Ә.Г.*) «Иртәгә улың булырмын» дигән әсәрегезне укыган идем. Ул әсәрегез дә образлылык, подтекстлар, характерлар төрлелеге, тирән фикерле булуы белән сокландырган иде. Бу әсәрегезгә карата да шул ук сүзләрне кабатлый алам. Кызганычка каршы, әнә шулай (нәкъ сәнгать таләп иткәнчә!) язылган әсәрләр буенча куелган спектакльләр тамашачыларыбызга бик үк барып җитми. Моңа әле күпчелек тамашачыларыбызның (авыл җирләрендә бигрәк тә!) зур интеллектуаль булмаулары комачаулый. Безнең – сәнгать работникларының, артистларның андый әсәрләрне ачу сәләте җитмәү дә билгеле бер рольне уйный билгеле. Менә хәзер безнең репертуарда Аяз Гыйләҗевнең «Без унике кыз идек» драмасы бар. Ул әсәр дә нәкъ шундый диярлек. Әсәр яхшы, спектакль дә алай начар түгел кебек. Ә авыл тамашачысы авыр кабул итә. Ә район үзәге тамашачысы яхшырак, шәһәр тамашачысы тагын да яхшырак кабул итә. Менә бу Сезнең без укыган әсәрегез буенча куелган спектакль дә шулай булачак, дип уйлыйм. Мондый әсәрләргә нечкә зәвыклы, шигъри йөрәкле, образлы фикер йөртә ала торган тамашачының булуы шарт.

Әхәт, әсәргә бу хәлендә кайбер киңәшләребез, фикерләребез дә бар. Менә алар:

1. Драманың I кисәге бик озын, кабатлаулар да бар. I бүлектә динамика түбән, теманы эшкәртү сүлпән.

2. Әсәрне куйган очракта безнең театрлар эшли торган шартларда куяр өчен II бүлектә оформлениеләр бик күп һәм еш алмашына. Бу нәрсә практикада бик күп уңайсызлыклар тудыра, спектакльнең идея-художество дәрәҗәсен төшерә торган нәрсәләр китереп чыгара.

3. Әсәрдә конфликтның эшләнеш мәсьәләсендә. Урыны-урыны белән конфликт чишелү дәрәҗәсенә килеп җитә, йомшара. Аннан тагын алынып китә. Шуңа күрә әсәр берничә җирдә менә бетте, дигән фикер тудыра. Бу хәл булганда безнең тамашачы ахрын күтеп тә тормый, торып өенә йөгерә башлый.

4. Әсәрдә вакыйгалар азрак төсле. Булганнарның да кайберләре вакыйгаларга куелган таләпләргә җавап бирерлек түгел була. Хәтерлисезме, Станиславский: «Событие двигает действие вперед, меняет его направление», – ди.

5. Колхоз председателе образы. Моңа бәйләнәчәкләр. Председатель бик берьяклы күренә. Каты, тупас итеп әйткәндә, ул бары арка юып йөрүче булып кына кала. Колхоз председательләре үзләре үк аңа риза булмаячаклар. Ә бит безнең кебек театрлар председательләргә бәйле. Бензин җитми – председатель! һ.б. Аның кешелеклелеген аңлыйлар, дип уйлыйсызмы?! Алар анысы турында уйлап та тормаячаклар, өстән генә сөрәчәкләр. Әнә шулай өстән сөрә торган тамашачылар (алар аз түгел!) председательләрен яратмасалар, ул көлү объектына әвереләчәк.

6. Һәм соңгысы, монысы принципиаль түгел. Әсәрдә ирләр күбрәк (6), ә хатын-кызлар азрак (4). Хәзер бөтен күчмә театрларда укомплектовать итүдә бер җитешсезлек бар. Ирләр – аз, хатын-кызлар – күп. Ә дөрес укомплектовать ителгән театрларда ирләр иҗади составның өчтән-ике өлеше булырга тиеш. Кадрлар җитми! Училищелар да артистларны аз чыгара. Бетереп чыкканнарын театрга килгәч тә армиягә алалар. Ә армиядән соң күбесе театрга кире әйләнеп кайтмый. Тормышка җайланалар. Сәнгать уку йортларына күбрәк башка уку йортларына керә алмаганнар керә, кызганычка каршы. Шуңа күрә кулга тотарлык чын ирләр-артистлар бик аз. Күбесе – бөгелеп-сыгылып йөрүчеләр.

Менә Сезгә шуларны хәбәр итәргә булдым.

Пьесагызның бер экземплярын хәзергә үзебездә калдырырга рөхсәт итегез, бер экземплярын Сезгә юллыйм.

Тирән ихтирам белән, зур уңышлар теләп,
Г.Хөсәенов.

18/V-78

Исәнмесез!

Әхәт, акыллым, хатыгызны алдым. Озак хат килмәгәч, үпкәләде микән әллә, дип борчыла да башлаган идем. Шул ук вакытта Күчмә театрда, Минзәлә театрында да яңа әсәрләре куела, вакыты юктыр, дип үземне тынычландырып та куя идем. Бар да нормаль икән, бик яхшы.

Хатыгыз өчен рәхмәт!

Хәзер турыдан-туры хатыгызда кузгалтылган мәсьәләләргә күчәм.

Сезне кызыксындырамы ул пьеса, юкмы? Оригиналь әсәр кайсы театрны гына кызыксындырмый икән?!

Бер театрда да оригиналлар тулып ятмый бит әле. Андый көнгә килеп җиткәнебез юк!

Киңәшләребезгә карата мөнәсәбәтегез дә уңай булгач, эшләргә кирәктер билгеле.

Әгәр киңәшләр бирелсә, димәк, әсәр кызыксындыра, дигән сүздер ул. Мин шулай аңлыйм. Юкса: «Әсәрегез безгә бик ошады, ләкин, кызганычка каршы, репертуарда бу теманы чагылдырган бер әсәр бар инде, шуңа күрә репертуарга ала алмыйбыз», – дип тә җавап бирергә мөмкин бит!

Сез: «Репертур планына кертелсә, конкрет эшкә керешергә мөмкин булыр иде», – дип язасыз. Әсәр кулда булмыйча, репертуар планына ничек кертергә соң аны?! Бу нәрсә бер театр эчендә өч театр булган коллективта (безнең театр бер үк көнне өчәр параллель – өч бригада уйный торган театр. Ул бит стационар театр түгел!) мөмкин түгел. Без репертуар планын төзегәндә үк ул әсәр кайсы бригада составында бара, кайчан куелырга тиеш, ул бригада репертуарында жанр ягыннан тагын шул ук жанрдагы әсәр туры килмиме (артистлар өчен бу да бик әһәмиятле, чөнки рәттән берүк жанрдагы әсәрләр уйнау артистларны туйдыра башлый) һ.б. һ.б. сорауларны хәл итәргә кирәк.

Шулай итеп, алдан уйланып куелган, хәл ителгән булса да кайчак репертуарга кергән әйбер дә вакытында куелмыйча кала. Менә быел Ю.Сафиуллин әсәре белән шулай булды. Репертуарга кергән иде. Эшли-эшли, әсәр үзгәрде. Нәтиҗәдә, ул куелачак бригадада аны уйнарлык артистлар булмады. Шул бригада көчләренә яраклы башка әсәр сайларга туры килде. Шулвакытта Сезгә дә мөрҗәгать иткән идем. Вакытында пьеса бирә алмады бер генә драматург та. Бу Ю.Сафиуллинның «Ни булган бу ирләргә?!» дигән сатирик комедиясе куелмый кала дигән сүз түгел, кую вакыты кичектерелә дигән сүз. Шулай булгач, югарыдагылардан чыгып, репертуар планына кертү өчен әсәрнең кулда булуы, аның театрны, министрлыкны канәгатьләндерерлек булуы төп шарт. Яхшы пьеса гына булсын, куелмыйча калуы мөмкин түгел. Барыбыз да ач бүреләр кебек ыжгырып торабыз.

Хәзер әсәргә кайбер теләкләребез турында тагын тукталып үтәсем килә.

Әсәр 2 бүлектән генә торсын. Хәзерге тамашачы 3 пәрдәле спектакльне авыр карый. Күптән түгел Минзәлә театры «Гомер узмый заяга» дигән драма куеп китте. Карап утыруы бик авыр булды. Спектакль 3 сәгатьтән артык бара. Никадәр яхшы әсәр булса да, хәзерге тамашачыны 3 сәгать утырту мөмкин түгел. Зөлкәрнәйләр ишегалды һәм шунда ук Гальериларның бер почмагын ничек күз алдына китерәсез сез? Безнең театр зеркаласы – 5 метр, тирәнлеге 3 метр булган сәхнәләрдә дә уйный. Анда ишегалдын да, өй почмагын да ничек сыйдырырга? Ә ресторанны бер өстәл чыгарып кую белән хәл итеп буламыни? Әйе, тамашачы шартлылыкка күнеккән. Без «Анам кыры»н шартлы рәвештә куйдык. Сезнең әсәр ул шартлылыкны бик үк кабул итми бугай. Уйлап карагыз. Картина аралары 1-2 минуттан артмаска тиеш. Ресторанга күчәр өчен, 1-2 минутны берничә тапкырлауга туры килер. I кисәк белән II кисәк арасында, пожалуйста, теләсә нәрсә эшләргә мөмкин. Мин боларны практикадан чыгып әйтәм. Шартлы булса булсын, мин шартлылыкка каршы түгел. Ләкин ул драматургик материалда булырга тиеш.

Вакыйгалар азлыгы турында. Хәзерге театр мөмкин кадәр вакыйгаларның күп булуын, информацияләрнең, фактларның муллыгын таләп итә. Әйе, «драматургия – характерлар көрәше, сюжет белән мавыктыру түгел». Монда Сез үзегезгә каршы киләсез бугай. Вакыйгалар булмагач, характерлар көрәше ничек туа соң? Вакыйгалар – драматургиянең нигезе, характерлар шул вакыйгаларда ачыкланалар, туалар. Станиславскийны искә төшерегез. «Событие двигает действие вперед, меняет его направление», – ди бит. Ул әнә шундый вакыйгаларны сайлап алырга куша. Юкса, безнең татар драматурглары әсәрләрендә вакыйгалар бик йомшак, хәрәкәтнең юнәлешен үзгәртү түгел, аңа артык этәргеч тә бирмиләр. Менә шуңа күрә кулга то-

тарлык характерлар да тумыйлар. Драматург ниндидер теманы эшкәрткәндә мавыктыргыч (мин туры мәгънәсендә генә әйтмим) вакыйгалар тезмәсе кора алмаса, нинди характерлар бәрелеше тудырырга мөмкин!

Әйе, геройларның яшәвен анализлау белән җәлеп итү дә кызыклы. Ләкин аны конфликт чишелә башлаганда яки чишкәннән соң эшләргә кирәкмидер инде. Мин шулай уйлыйм, практика шуны күрсәтә, татар тамашачысының үзенчәлеге шуны раслый. Рус тамашачысы рәхәтләнеп утырганда безнең татар тамашачысын тотып кара! Төп вакыйга булганнан соң, чишелеш 2-3 минутка сузылса, безнең тамашачы хәзер торып йөгерә. «Геройларның яшәвен анализлап» утырганны көтеп утырмый ул.

Председатель образы белән һич тә килешә алмыйбыз. Бәлки шулайдыр да ул. «Кешенең кемлеген иң матур итеп әйтергә тырышудыр». Ләкин председательнең башка бер эше дә тоелмый. Председатель образы аша кайнап торган колхоз тормышы күз алдына килеп басарга тиеш. Ә Сезнең әсәрдә бер эше дә булмаган колхоз председателе күз алдына килә. Нигә аны председатель итәргә? Бәлки, башка хезмәт кешеседер. Уйларга кирәк. Мин председательгә дә каршы түгел. Ләкин бу хәлдә түгел.

РЕДАКЦИЯДӘН:
Күренекле прозаик, драматург, шагыйрь һәм публицист ***Әхәт Гаффарның (Габделәхәт Габдрахман улы Гаффаровның)*** *гыйнвар аенда гомер бәйрәме. Аны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек белән хәерле озын гомер һәм укучыларын, тамашачыларны әле озак еллар буе яңа әсәрләре белән сөендереп яшәвен теләп калабыз!*

Пьесаның бездә булган нөсхәсен җибәрәм. Бернинди мәшәкатьләү юк. «Театрга килгән-киткән кешеләр күз алдында тормасын иде, әллә ничек, уңайсыз», – диюегез гаҗәпләндерде. Нигә аңа уңайсызланырга?! Бер генә драматург та диярлек театрга әзер әсәр биргәне юк әле. Бөек драматурглар да әсәрләрен әллә ничәшәр тапкыр эшкәртәләр, килгән-киткән кешеләргә үзләре укыганнар, укытканнар. Бөек сәхнә мастерлары үзләренең спектакльләрен башта килгән-киткәнгә күрсәткәннәр. Минем профессор мәрхүмә О.И.Пыжова: «Ничек уйнавыңны син билетершалардан яки швейцардан сора», – ди торган иде. Алар шулай эшләгәнне, безнең кебекләр, киресенчә, кат-кат укып, укытып ниндидер фикер алудан бер дә уңайсызланмаска тиешләр. Бер баш – бер баш ул, ике баш – ике баш!

Әхәт, Сез мине дөрес аңларсыз, дип уйлыйм. Дөрес аңламасагыз, Сез булган саф күңелемне рәнҗетү булачак.

Сезгә кайнар сәламнәремне юллап,
ихтирам белән, Г.Хөсәенов. ■

Безнең мирас №1 гыйнвар 2019

Телнең киләчәге – безнең киләчәк!

Әхмәт Гадел
(1942-2012)

Гаҗәеп матур безнең туган телебез – татар теле! Аның кабатланмас гүзәллеге, татар авыллары, татар төбәкләре сөйләмендә генә түгел, классик язучыларыбызның әсәрләрен укыганда да ачык күренә. Алар чиксез бай телебезнең фәлсәфи тирәнлегенә, мантыйкый үсешенә зур йогынты ясаганнар, төрле мәгънәви төсмерләр, сурәтле бизәкләр белән буыннан-буынга баетылып, камилләштерелеп килгәннәр.

Гасырлар буена кысылган, изелгән булуына, дөнья мәйданына чыга алмыйча чикләнеп яшәвенә карамастан, ул үзенең алмаздай үткенлеген, куәтен һәм җегәрен әле бүген дә җуймаган, яңа сынауларга, яңа көрәшләргә чыгарга әзер тора кебек. Ана телемнең моңы, аның аһәңе, яңгырашы әле дә сокландыра, куандыра һәм горурлык хисе уята.

Мин татар телендә радиотапшырулар тыңларга, телевидение программаларын карарга яратам, концертларда, спектакльләрдә еш булам.

Өлкән яшьтәгеләр радио дикторлары Вәсвикамал Саттарова, Эльс Гадел, Айрат Арслановның милли аһәң белән сугарылган ягымлы тавышларын, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Рәшит Ваһаповларның чын татарча моңлы җырлавын әле яхшы хәтерлидер. Театрыбызның күренекле артистлары Хәлил Әбҗәлилов, Хәким Сәлимҗанов, Празат Исәнбәт, Шәүкәт Биктимировның, театр сәхнәсеннән булсын, радио-телевидениедән булсын, – телебезнең бөтен нечкәлекләрен тоеп сөйләве, чыгыш ясаулары шулай ук кемнәрне генә таң калдырмагандыр! Кызганыч, ләкин алар белән ул заманның гаҗәеп гүзәл теле-сөйләме дә китеп бара кебек...

Заманында татар теле Азия белән Ауропаны тоташтырган-дуслаштырган, алар арасында мөнәсәбәтләр урнаштыручы илче булган.

Бу телдә урыс империясенең дипломатик корпусы сөйләшкән, бу телдә рәсми кәгазьләр язылган. Татар телен Рәсәй гимназияләрендә, лицей һәм югары уку йортларында укытканнар. Татар теле урыс, латин, грек, фарсы, гарәп телләре белән бер үк дәрәҗәдә хәрби уку йортларында да мәҗбүри укытылган. Бүген күпләр сөйләшергә тарсынган татар теле менә нинди абруйлы булган!

Кызганыч, бүген без ни урыс, ни татар булып калдык, ярымйорты урам телендә аңлашабыз һәм аралашабыз. Хәтта берничә чит телне яхшы белгән белгечләребез дә үз телебездә иркен сөйләшә алмый. Моны күбесе эш теленең урысча алып барылуы белән аңлата. Хәзер театр, радио, телевидение, аеруча эстрада теле шактый саекты. Нигә болай булды? Ник без үз сөйләмебезне шундый хәлгә китереп җиткердек? Нигә без меңәр ел саклап, баетып, чарлап килгән газиз телебезне куркыныч астына куйдык, фаҗигале язмышка дучар иттек? Нигә без «младописьменный»лар рәтенә төштек? Нигә без азәриләр, әрмәннәр, гөрҗиләр, Балтыйк буе халыклары, үзбәк, таҗиклар кебек телебезне горур яшәтә алмыйбыз? (Ә бит сан ягыннан без әле дә алардан әллә ни ким түгел.) Нигә кайберәүләр һаман да, янәшәгә бер урыс килеп басса, туган телендә сөйләүдән туктый? Әйе, күп гасырлар җәбер күргән халыкның генетик куркуы бу. «Не говори по-татарски – каля-баля», – дигәнгә кан җавабы. Менә ни өчен без

Әрмән язучысы Геворг Әминнең «Әрмәнстан халкының җиде хикәяте» дигән китабында мондый сүзләр әһәмияткә ия: «Без, әрмәннәр, үзебезне милләт буларак саклап калу өчен, үзебезгә аерым әлифба, хәрефләр уйлап таптык, шуның белән үзебезне сакладык, аерым дини юнәлеш алдык, иманыбызны ныгыттык. Югыйсә, без үзебезне милләт буларак һич тә саклап кала алмый идек». Гыйбрәтле сүзләр.

һаман да әле авызыбызга су кабабыз, һаман да әле эчтән сызып, теш кысып яшибез. Без үзебезне изгән халыкның телебездән, мәдәниятебездән мыскыллап көлүенә каршы торырга көч таба алмаганбыз шул. Ә аның хыялы һаман да бер: «мономәдәният», «мономилләт», бер дин астына халыкларны туплау. Әлбәттә, бу «моно»ның ахыргы максаты бик ачык билгеле, аны хәзер инде яшереп тә маташмыйлар: урыслаштыру, кул астындагы милләтләрдән бер милләт – урыс милләте ясау.

Үз телеңне, үз тарихыңны, үз тамырларыңны белми торып, үз халкыңның әдибе дә, галиме дә булып булмый. Туган тел аһәңеннән, ата-баба моң-җырларыннан аерылган кеше беркайчан да үз халкының вәкиле була алмый. Бу – хакыйкать! Тумышың белән татар булып та, нинди генә Михаил Львов, Сергей Каратов, Роман Солнцев исемнәренә төренмә, халык сине үз итми. Ул халык өчен син чит-ят, үз халкыннан йөз чөергән бәндә булып каласың. Монысы да – хакыйкать!

Кая китеп бара безнең Габделҗаббар Кандалый, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Мөдәррис Әгъләмнәр теле? Кайда алардагы җегәр, нечкә зәвык, сүздән сурәт ясау осталыгы, тел дәрьясында киң колач җәеп йөзү? Салмак агышлы туган телебезнең дәрт-дәрманы, тәэсир көче кимегәннән-кими, тел байлыгы, тел хәзинәсе күз алдыбызда ярлылана бара...

Урам себерүченең җыен чүп-чар ияргән себеркесен хәтерләтмиме икән әдәбиятыбызга, сәнгатебезгә үрмәләгән бүгенге сөйләм телебез?

Әйе, дөньяда иң билгеле: үндүрт телнең берсе булган татар теле бүген – куркыныч астында. Бу фаҗиганең башы кайда, дисәк, ул һәркемгә билгеле, бу фаҗига 1552 нче елны милләтебез олы афәт кичергәннән, ягъни Явыз Иван гаскәрләре Казан ханлыгын басып алганнан соң башлана һәм бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Мондый шартларда милли илпарвәрлекне, туган телебезгә мәхәббәтне ничек саклап калырга соң? Миңа калса, бу җәһәттән, әрмән язучысы Геворг Әминнең «Әрмәнстан халкының җиде хикәяте» дигән китабында мондый сүзләр әһәмияткә ия: «Без, әрмәннәр, үзебезне милләт буларак саклап калу өчен, үзебезгә аерым әлифба, хәрефләр уйлап таптык, шуның белән үзебезне сакладык, аерым дини юнәлеш алдык, иманыбызны ныгыттык. Югыйсә, без үзебезне милләт буларак һич тә саклап кала алмый идек». Гыйбрәтле сүзләр.

Ни бирде безгә балаларыбызның урыс мәктәбендә укуы? Татарның милли гореф-гадәтләрен саклап, чын иманлы кеше булып үстеләрме алар, милләтебезнең дан-шөһрәтен арттырдылармы? Яисә мәдәниятебезне, сәнгатебезне үстерүгә өлеш керттеләрме? Һич юк! Киресенчә, шуның нәтиҗәсендә татар каны сыегайды, катнаш никахлар артты, халык баштанаяк урыслаша башлады.

Үз телеңне, үз тарихыңны, үз тамырларыңны белми торып, үз халкыңның әдибе дә, галиме дә булып булмый. Туган тел аһәңеннән, ата-баба моң-җырларыннан аерылган кеше беркайчан да үз халкының вәкиле була алмый. Бу – хакыйкать! Тумышың белән татар булып та, нинди генә Михаил Львов, Сергей Каратов, Роман Солнцев

исемнәренә төренмә, халык сине үз итми. Ул халык өчен син чит-ят, үз халкыннан йөз чөергән бәндә булып каласың. Монысы да – хакыйкать!

Телебезнең каты авыру икәнлеген, аңа ашыгыч ярдәм кирәклеген барыбыз да яхшы беләбез. Телнең мондый авыр хәлгә төшүенә сәбәпләр күп. Бездән генә тормаганнары да шактый. Бездән торганнары да күп. Чагыштырмача иркен заманнар да булды. Миңа калса, ул чакта мәгариф хезмәткәрләре, галимнәребез иң беренче булып җиң сызганырга, вакытны ычкындырмыйча, мәктәпләрне, башка уку йортларын татар теле дәрьясына кайтару турында кайгыртырга, гамәли эшләр эшләргә тиеш иде. Булмады. Иң кирәкле чакта галимнәр күбрәк телнең фәнни ягын карау белән генә мәшгуль булды күрәсең...

Тел мәсъәләсе, син кем булуыңа карамастан, милләтнең һәр вәкиленә кагыла. Тикмәгә генә урысның дини китаплары: «Иң элек Сүз булган...», – димидер. Сүз юк икән, димәк, кеше юк, кеше юк икән, димәк, милләт юк. Китап дигәннән, хәзер китап чыгару гына кыенлашып калмый, укучы табу да авырлаша. Чөнки татарча укучылар саны көннән-көн кими бара. Русия өлкәләре булып калган төбәкләребездә татар халкы мәнфәгатьләре белән санлашу юк, алардагы татар теле һәм әдәбияты кергән соңгы мәктәпләр дә ябылу алдында тора.

Тел мәсъәләсе, син кем булуыңа карамастан, милләтнең һәр вәкиленә кагыла. Тикмәгә генә урысның дини китаплары: «Иң элек Сүз булган...», – димидер. Сүз юк икән, димәк, кеше юк, кеше юк икән, димәк, милләт юк. Китап, дигәннән, хәзер китап чыгару гына кыенлашып калмый, укучы табу да авырлаша. Чөнки татарча укучылар саны көннән-көн кими бара. Русия өлкәләре булып калган төбәкләребездә татар халкы мәнфәгатьләре белән санлашу юк, алардагы татар теле һәм әдәбияты кергән соңгы мәктәпләр дә ябылу алдында тора.

Телне югалтуны – әдәбиятны, сәнгатьне, тарихны, үткәннәрне, гомумән алганда, милләтне югалту дип кабул итәргә кирәк. Табигатьтә исә буш урынга шундук кереп утыручы табыла, «изге урын буш тормый». Чүлләр уртасында гүзәл оазисны хәтерләткән, кешелек барлыкка килгән чордан алып гасырлар буе халкыбызның рухи байлыгын туплаган мәдәниятебезгә, тау-тау ком шуышып килгәндәй, чит тел, чит гореф-гадәт, ят психология яный. «Ком астында калган тарихка» әверелмәс өчен, бүген безнең алдыбызга ата-бабаларыбыздан калган рухи мирасны, мең киртәләр аша безгәчә килеп җиткән изге ана телебезне, эстафета итеп, киләчәк буыннарга тапшырырга тиешбез. Бу – безнең изге бурыч... Югыйсә, безне Үткәннәр дә, Киләчәк тә мәңге гафу итмәс.

Әдипнең Татарстан радиосындагы
«Тел күрке – сүз» тапшыруында 2003 елда яңгыраган чыгышын
*журналга **Рөстәм Фәйзуллин (Акъегет)** әзерләде.* ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

Ә.Р.ТЕНИШЕВ ТУПЛАНМАСЫ

Әдһәм Рәхим улы Тенишев 1921 елның 25 апрелендә Пенза каласында зыялы татар гаиләсендә туган. Бу нәселнең Пенза тармагы XIX һәм XX гасыр башына кадәрге дәвердә татар милләтенә танылган күп кенә шәхесләрне бирә. Шулардан берничәсен искә төшерик: әдип, мәгърифәтче, татар әдәбиятында беренче роман язучы («Өлүф яки Гүзәл кыз Хәдичә») Заһир Бигиев (1870-1902); рухани, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, публицист Муса Бигиев (1875-1949); язучы Гафур Коләхмәтов (1881-1918) һ.б.

Ә.Р.Тенишев 1938 елда Мәскәүнең транспорт инженерлары әзерли торган институтына укырга керә. Бөек Ватан сугышыннан соң ул Ленинград университетының Шәрык факультетын тәмамлый. Менә шуннан соң инде аның шәркыят-тюркология буенча хезмәт юлы башлана. Тенишевның укытучы-остазы танылган тюрколог С.Е.Малов була. Малов, колачлы галим буларак, рун язулары белән дә, кадими уйгыр теле һәм бүгенге заман төрки телләр белән дә кызыксына һәм шуны укучысы күңеленә сала белә.

Университетны тәмамлаганнан соң, Ә.Р.Тенишев аспирантурада кала, кадими уйгыр теле буенча фәнни эзләнүләр алып бара. 1953 елда ул борынгы уйгыр эпосы «Алтын Ярук» буенча кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый. Аннары Мәскәүгә күченеп килә, СССР Фәннәр академиясенә караган Тел белеме институтында төрки телләр бүлегендә эшли башлый.

1969 елда ул докторлык диссертация-

Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

сен яклый. 1970-2004 елларда үзенең төп хезмәтләрен бастырып чыгара: «Салар теленең төзелеше», «Сарыг-югор теленең төзелеше», «Төрки телләрне өйрәнүгә кереш», «Кытайдагы төрки халыкларда булу», җәмгысе алты томны тәшкил иткән «Төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасы».

Әдһәм Тенишев барлыгы 15 китап, 200дән артык фәнни мәкалә бастырып чыгара. Остаз буларак, 20 доктор, 30 фән кандидаты әзерли. Рус, татар, башкорт, үзбәк, уйгыр, хакас, бурят, якут, калмык, кытай, алман, француз, америка тел белгечләренең хезмәтләренә мөхәррир була. Ул инглиз, алман, француз, рус һәм төрки телләрне яхшы белә.



Теге яки бу халыкта басма китап барлыкка килү өчен ул халыкның әлифбасы, халык арасында укый-яза белүнең шактый дәрәҗәдә таралуы, белемгә булган ихтыяҗның үскән булуы, шактый дәрәҗәдә әдәби, фольклор мирасы булуы кирәк.

Әбрар Кәримуллин

Татар халкының күз уңындагы горурлыгы, танылган галим, сәләтле җитәкче, менә дигән кеше – Әдһәм Рәхим улы Тенишев 2004 елның 11 июлендә дөнья куя. Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Ә.Р.Тенишевның шәхси китапханәсеннән (хатыны Е.А.Тенишевадан 2010 елда алынган) күчерелгән бай тупланма саклана. Моңа өч меңгә якын китап һәм вакытлы матбугат басмалары керә, алар тел гыйлеменең төрле юнәлешләрен колачлый, төрки, фарсы, фин-угор, монгол, маньчжур-тунгус, роман-герман, Кавказ һәм Скандинавия халыклары, руника һәм борынгы уйгыр, гарәп, кытай, рус һ.б. телләрне өйрәнүгә багышланганнар. Тарихка һәм этнографиягә кагылышлы басмалар да бар.

Тупланмадагы басмалар рус, инглиз, төрек, алман һәм башка телләрдә 1814-2002 еллар аралыгында дөнья күргәннәр. Монда рус галимнәреннән – В.В.Радлов, С.Е.Малов, В.В.Бартольд, И.Ю.Крачковский, Н.К.Дмитриев, Н.А.Баскаков, Е.Э.Бертельс, Е.М.Мелетинский, А.М.Щербак, Х.Г.Жирмунский, А.Н.Кононов; чит ил галимнәреннән



– К.Менгес, Л.Кормаз, Ю.Немет, Н.Дәүләт, Г.Дорфер, Г.Ярринг, Г.Текин, В.Дримб һәм татар галимнәреннән – М.Госманов, М.Зәкиев, Ф.Сафиуллина, Ф.Хәкимҗанов, Ф.Гарипова һәм Ә.Тенишев фатиха биргән башка авторларның да хезмәтләре бар.

Бик сирәк калган, библиографик кыйммәткә ия басмалар – В.В.Радловның тюркологиягә караган, рус һәм алман телләрендә 1895-1908 елларда басылган китаплары, С.Е.Маловның борынгы төрки язмалар турындагы тикшеренүләре, В.В.Бартольдның Шәрыкны өйрәнү чыганакларын барлаган хезмәте, Морат Рәмзинең Оренбургта 1908 елда гарәп имласында нәшер ителгән тарихи әсәрләре, Галишер Нәвоиның факсимиль басмадагы «башлангыч чор шигырьләре» һ.б. материаллар.

Тупланмада Ә.Р.Тенишев редакцияләгән, авторлары, хөрмәтле остаз-галимгә рәхмәтен белдереп, култамга куйган китаплар да күп.

Борынгы төрки язма истәлекләрне өйрәнүгә багышланган әдәбият үзенә бер урын алып тора. Мәсәлән: итальян-кыпчак сүзлеге «Codecx Cumanicus»ны, Мәхмүт Кашгарыйның «Диваны лөгать-әт-төрек», Йосыф Баласагунлының «Kutadgu Bilig»ен, Харәзминең «Мәхәббәтнамә»сен, Заһиреддин Бабурның «Бабурнамә»сен





тел үзенчәлекләре ягыннан өйрәнеп язылган фәнни эшләр – яшь галимнәр өчен үзе бер кыйммәткә ия чыганаклар.

Шәрык кулъязмалары җыелмаларына ясалган тасвирламалар игътибарга лаек. Болар арасында – Шәркыят институтының төрки кулъязмалары тасвирламасы; Азия халыклары институтының уйгыр кулъязмалары тасвирламасы; гарәп, төрки, фарсы кулъязмаларының библиографик күрсәткечләре һәм каталоглары бар.

Тагын күләме өч йөз табакка җиткән белешмә басмалар тупланманың кыйммәтен күтәрә. Монда сүзлекләрнең нинди генә төрләре юк: фразеологик, аңлатмалы, диалектологик, этимологик сүзлекләр һәм белешмәлекләр. Кайберләрен мисалга китерик: өч томдагы «Биш телле уйгыр-кытай-монгол-санскрит-тибет сүзлеге», Ә.Р.Тенишев мөхәррирлегендә чыккан «Борынгы төрки сүзлек», «Төрки телләрнең этимологик сүзлеге» һәм башка шундыйлар.

Фольклор бүлекчәсендә риваятьләр, төрле халыкларның эпик әсәрләре урын алган. Әйтик, кыргызларның каһармани эпосы «Манас», казакъ эпосы «Кыз Җибек», татар халык дастаны «Идегәй», калмык дастаны «Җангар», «Себер һәм Ерак Көнчыгыш халыкларының фольклор үрнәкләре» сериясеннән китаплар.

Китап һәм журналлардан кала, тюркологиягә караган фәнни басмалардан төшерелеп аерым төпләнгән мәкаләләр шул өлкәдә эзләнүче галимнәр өчен әйтеп бетергесез уңайлык тудыра.

Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә Ә.Р.Тенишевның тупланмасын өйрәнү, исәпкә алу, фәнни эшкәртү буенча туктаусыз эш алып барыла. Бөтен нөсхәләр дә Милли китапханәнең исәп-хисап документларына теркәлгән, традицион һәм электрон каталогларга кертелгән. Тенишев тупланмасындагы фәнни әдәбият белән укучыларның кызыксынуы елдан-ел арта баруы – бик табигый фал. ■

Ябынчыда – «Муллалар коесы»

*Әтнә районының Ябынчы авылында тарихи һәм табигый әһәмияткә ия булган бу урынны игътибарсыз калдыру мөмкин түгел. Монда авыл имамы **Баһаветдин бине Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани**, аның хатыны **Бибихөбәйбә Габденнасыйр кызы**, 1818 елның 16 гыйнварында якты дөньяга аваз салган беренче газиз уллары – нәни **Шиһабетдин** һәм алардан соң да килеп-киткән мулла һәм абыстайлар исеме белән бәйле кое бар.*

Коеның элеккеге күренеше

Якындагы нигездә гел голәмә-меллалар гына яшәгәнлектән, халык бу су чыганагын «Мулла коесы» дип атап йөртә. 1815 елда Габделкәрим бай таләбе буенча Ябынчыга килгән Баһаветдин хәзрәт һәм аның гаиләсе дә, 1821 елда Ташкичүгә күчеп киткәнче, шушы коеның суын файдаланган.

Дөрес, 1997 елны әтнәлеләр бу коены торгызган, әмма соңгы елларда, авылда даими яшәүчеләрнең саны кимү, ә кыш айларында гомумән калмау сәбәпле, ул онытыла башлаган. 2016 елның июнь аенда, «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры **Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин** һәм аның җитәкчелегендәге егетләрнең матди ярдәме, тынгысыз хезмәте нәтиҗәсендә, «Муллалар коесы», төзекләндерелеп, туристлык маршрутына кертелде. ■

КУКМАРА МИРАСЫ

Киез итекләр иле

Әгәр Кукмараны үзенә күрә бер кечкенә ил дип гоман кылсак, аны, һичбер икеләнүсез, «Киез итекләр иле» дип йөртергә булыр иде.

ҖИМЕРГЕЧ ЗАМАН ҖИЛЛӘРЕ

...1917 елның Февраль инкыйлабының кайтавазы Кукмарадагы һич көтелмәгән вакыйгаларга этәрә. Тарихи чыганакларда бу хакта болай әйтелә (урысчадан тәрҗемәдә): «1917 елның март башларында Мамадыш өязенең Кукмара авылында башбаштаклык «өянәге» кузгалды, нәтиҗәдә, кибетләр таланды, кешеләр яраланды...» Шушы бер җөмләдә Россия империясенең чагыштырмача тыныч вә җитеш төбәгендәге вазгыять тасвирлана ләбаса! Әмма төбәктәге хәл-халәтнең әле бу башлангычы гына була шул...

1917 елның Октябрь инкыйлабы Кукмара халкының яшәешен тамырдан үзгәртә: полицияне юкка чыгарып, аның урынына эшче милиция отрядлары оештырыла. Киез-киез итек җитештерү фабрикаларын да читтә калдырмыйлар, чөнки алар белән фабрика-завод комитетлары идарә итә башлый. Хезмәт хакын түләү, кадр-хезмәткәрләрне эштән алу яисә вазыйфага билгеләү вә гайре оештыру гамәлләре белән моңарчы

И.А.Владимиров «Ярлылар комитетында сорау алу». 1918 ел

1918 ел плакаты

андый тәҗрибәләре булмаган эшче-пролетариат вәкилләре шөгыльләнә башлый. Кичекмәстән, сигез сәгатьлек эш көне кертелә, әүвәлге фабрика хуҗалары исә бары тик хезмәт хакына гына эшләүче вакытлы директор вазыйфасында калдырыла. Озакламый, бу башбаштаклыкның нәтиҗәләре дә күренә башлый: тауар җитештерү кимегәннән-кими, хезмәт тәртибе – дисциплина түбәнәйгәннән-түбәнәя бара... Бертуган Комаровлар һәм Родигиннарның киез-киез итек фабрикалары, алардан тартып алынып, яңа хакимияткә тапшырыла. Фабрика хуҗалары, үзләренә үлем куркынычы янаганын сизенеп, тиз арада Кукмарадан чыгып качалар.

Капитализмнан социалистик тәртипкә күчеш чорындагы хикмәтләрне үз күзе белән күргән бер шәхескә сүз бирик әле. Ул – 1919 елның 15 июлендә Кукмара фабрикасына Казандагы «Губтекстиль» завод идарәсеннән командировкага юлланган баш бухгалтер В.Я.Пеппе: «Соңгы ике ел дәвамында Комаровлар һәм Родигиннарның фабрикалары тәмам бөлгенлек дәрәҗәсенә төшкән. Гәрчә элеккеге хуҗалары 1918 елның июль айла-

Продразверстканың иң беренче эксперимент-тәҗрибәсе Вятка губернасында моннан йөз ел элек гадәттән тыш азык-төлек комиссары А.Шлихтер җитәкчелегендә оештырыла

рында гына Кукмара авылыннан чыгып качсалар да, асылда исә боларның эшчәнлеге 1917 елда ук туктатылган. Чөнки алар, бу вакыттан алып, оешып бетә алмаган эшче гавамының һәртөрле таләпләрен генә башкарырга мәҗбүр булганнар. Эшчеләрнең гомуми җыены 1918 елның июленнән октябренә кадәр мәгънәсез рәвештә идарә итә бирә. Бары тик октябрь азакларында гына «Губсовнарком» тарафыннан расланган завод идарәсен сайлап куялар. Шул ук вакытта «ярлылар комитеты», «продразверстка» хәрәкәтләре дә баш калкыта башлый.

Киез-киез итек фабрикалары – гаҗәеп күп һәм төрледән-төрле тармаклардан торган катлаулы механизм ул. Шуның берсе генә ватылса да, һәммә эш туктালып кала... Фабрикалар берөзлексез эшләсен өчен исә һәртөрле чималның даими булып торуы зарур. Мәсәлән, фабрика биналарын җылыту, станокларын эшләтү өчен ягулык яисә атларга

Родигиннарның киез-киез итек фабрикасы бинасы. 1920 нче еллар

Татар сәүдәгәрләре. 1920 нче еллар

азык дисеңме... Эшчеләрне дә тукландырырга һәм аларга хезмәт хакы түләргә кирәк. Идарә вә хуҗалык итү җәһәтеннән мөнәсәбәтләр, эшлекле элемтәләр исә бу вакытта тәмам өзелгән, ни чималы, ни ягулыгы юк, станоклар, җиһазларның кайсы ватылган, кайсы урланган... Әле 1918 елда элеккеге – чын хуҗалардан калган мая-запас була ичмаса. Мәсәлән, шул ук елның февралендә Комаровлар фабрикасында, чимал һәм җитештерү материалларыннан гайре, эшчеләргә таратылган азык-төлек менә шундый тәшкилияттә теркәлгән: 220 пот (3,6 тонна) елкы (ат) ите, 53 потка якын (868 кило) сыер ите, 10 потка якын (164 кило) чучка мае, 146 пот (2,4 тонна) һәртөрле ярма, 543 пот (8,9 тонна) арыш оны, 94 (плитка) такта чәй, 16 пот (262 кило) тоз. Шикәр урынына акчалата түләгәннәр. Фабрика атларын асрау өчен 225 пот (3,7 тонна) солы, шул ук авырлык күләмендә печән сарыф ителгән. Хәзер боларның берсе дә юк... 1918 елның урталарыннан бер Мамадыш-Кукмара яклары гына түгел, тулаем Россия дә икътисади кризис упкынына тәгәри башлый. Гәрчә үз мәнфәгатьләрен кайгыртсалар да, эшче вә хезмәткәрләрен дә онытып бетермәгән чын хуҗалар, эшмәкәрләр чоры тәмамлана. Авыл халкыннан мәҗбүри рәвештә азык-төлек тартып алу өчен оештырылган һәртөрле продотрядлар, «ЧК»лар заманы башлана... Бу дәһшәтле чор хакында киләсе саннарда укырсыз.

*Язманы **Марат Закир** әзерләде.* ■

ДЕКАБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 1 декабрьдә Арча районының Шушмабаш мәктәбендә филология фәннәре докторы, профессор, нәфис сүз остасы Фәрит Бәширнең тууына 60 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе булды.

● 3 декабрьдә М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет академия театрында «Үзгәреш җиле» III татар җыры фестивале үтте.

● 6 декабрьдә Россия ислам институтының 20 еллыгына багышланган тантана узды. Әлеге чарада Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

● 11 декабрь көнне ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов исеменнән РФ Конституциясенең 25 еллыгы уңаеннан тантаналы кабул итү мәҗлесе үтте.

● 12 декабрьдә Арча районының Шурабаш мәктәбе һәм Байкал клубында «Милләтне без тергезик» дип исемләнгән әдәби-музыкаль һәм фәнни чара узды. Язучы-драматург, Мөселман хәрби шурасы рәисе, «Безнең тавыш» газетасы мөхәррире, Мөселман революцион штабы рәисе, татар отрядларын оештыручы Габделгазиз Монасыйповның тууына 130 ел тулу уңаеннан үткән чарага Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галиме Зөфәр Рәмиев, Габдулла Тукай музее директоры Гүзәл Төхфәтова, «Безнең мирас» журналы редакциясе хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин да кайтты.

● Әлмәт шәһәрендә Р.Фәхреддиннең «Рухият» фонды чыгарган «Сәлимә, яки гыйффәт», Т.Шәмсуаровның «Аклыкка сыену», З.Мөдәррисованың «Тамгалы кеше»,

О.Стрелкова-Костюнинаның «Осень в Бугульме», С.Гарифуллинаның «Нет на земле другого вас...», Н.Садовинның «Блокнот журналиста», Ф.Сафинның «Әйдәгез, дуслашыйк» исемле китапларын укучыларга тәкъдим итү кичәсе булды.

● 13 декабрьдә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Г.Тукай исемендәге Әтнә дәүләт театрына 100 ел тулуга һәм Театр елын ачуга багышланган тантаналы чарада катнашты.

● 14 декабрь көнне Татарстан Язучылар берлегенең Балалар әдәбияты остаханәсендә яшь язучы Айсылу Имамиева иҗатын тикшерделәр. Ул, бертавыштан, Язучылар берлеге әгъзалыгына тәкъдим ителде.

● 15 декабрьдә Түбән Кама шәһәренең «Мирас» мәдәният сараенда «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе оешуга 50 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде.

● 16 декабрьдә Сембер шәһәренең Губернатор сараенда «Гакыйль Сәгыйров укулары» узды. Сәламләү сүзе белән ТР Язучылар берлеге рәисе, күренекле прозаик һәм драматург Данил Салихов чыгыш ясады.

● 18 декабрьдә язучы, журналист Дамир Гыйсметдингә (Дамир Минсәгыйр улы Гыйсметдинов) Актаныш җирле хакимияте һәм Татарстан Язучылар берлеге гамәлгә куйган Гамил Афзал премиясе бирелде.

● 18 декабрь көнне АКШтагы Висконсин һәм Казакъстандагы Назарбаев университетлары профессоры, тюрколог, татар тарихы белгече, милләттәшебез Юлай Шамил углы Кол Шәриф мәчетендәге Ислам мәдәнияте музеенда Алтын Урда тарихына багышланган лекция укыды.

● 21 декабрьдә Тукай клубында, чыгышлар һәм фикер алышу рәвешендә, Татарстан Язучылар берлегенең Ел йомгаклары җыены үтте.

● 22 декабрь көнне Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры оешуга 30 ел тулу уңаеннан тантана узды. Әлеге чарада редакциябез хезмәткәре, язучы Фирдәвес Зариф та катнашты. ■

Мирасворд





Борынгы сугыш киеме

Кар эчендә ясалган куян өне (диал.)

Шагыйрь, язучы, Муса Җәлилнең көрәштәше

Шагыйрь ... Шәйхи

Гарәп артикле

Батулла әкиятендәге аю баласы

Башкортстандагы район

Ишарә

Борынгы Идел

Әсәрнең композицион өзеге, бүлеге

Озын шигырь

... Дидро

Сибгатуллин, Даян

Орфография (иск.)

Дан, дәрәҗә (иск.)

Одиссей Ватаны

Япон сөнгесе

Рус шагыйре, декабрист

Мирсәй ...

Үндүрт юллык шигырь

Җитмеш төрле авыруга дәва

Совет автосәнәгатен оештыручыларның берсе

Төш вакыты үткәч укыла торган намаз

Борынгы күчмә төрки халык

А.Пушкинның тәмамланмаган поэмасы

Кәримуллин, Сәгыйди

Нәҗми, Латыйп

Борынгы римлылар һәм грекларның өс киеме

Рәт, мәгънә, җай

АКШның дүртенче президенты

Камыштан ясалган үзбәк курае



Нияз Акмалның тәүге шигырьләр җыентыгы

Эндре ... (мажар шагыйре)

Тәлгат Галиуллин романы

... Урайский

Мисыр мифологиясендә чүл Алласы

Морза

Ярдәмче фигыль

Корьәнне яттан укучы

Н.Гоголь повесте

12 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: мари, юкәр, әсәр, Ика, үзбәк, Борһан, Диас, иләмән, томак, Вахит, кобыс, рәшә, Яков, топаз, Кәлилә, лари, Касыймов, исә, ти, күрешү, Нәсими.
Өстән аска: әрбә, оят, асс, Коба, окоп, Ибраһимова, «Бала», Зәйтүнә, Нәкый, Рим, Кио, иде, Вәдүт, дәрвиш, зинар, Ла, үги, каба, Хәлили, нәкәс, иш, Кир, тәләкә.

***Рәис Габдулла** төзеде.*

«Казан Кирмәне» Дәүләт тарих-архитектура һәм музей-тыюлыгы

Фото kuda-kazan.ru сайтыннан алынды

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
елъязмасы / гыйнвар

1040 ел элек (979)

Чүл төркиләре төзегән Төньяк Хань патшалыгы (ул 29 ел дәвам итә) чиннарның Төньяк Сун династиясе тарафыннан юкка чыгарыла.

110 ел элек (1909)

Баку каласында Халикъ Ахундов мөхәррирлегендә атналык «Зәнбур» («Шөбшә») исемле сатира журналы чыга башлый.

100 ел элек (1919)

4-20 гыйнварда Казанда Гыйльми һәйәт «Имля конференциясе»н оештыра. Әлеге абруйлы җыенда Казан, Сембер, Самара, Сарытау, Әстерхан, Ырынбур, Уфа, Пермь, Вятка, Пенза, Түбән Новгород, Мәскәү һәм Петроград шәһәрләреннән вәкилләр, тел белгечләре – җәмгысе 53 кеше катнаша.

95 ел элек (1924)

1 гыйнвардан Ырынбур каласында Партиянең Кыргызстан өлкә комитеты һәм Оренбург губерна комитеты оештырган «Юл» газетасы (язучы Шәриф Камал – редколлегия әгъзасы) чыга башлый.

80 ел элек (1939)

5 гыйнварда Казан шәһәр советы президиумы Фукс урамына Галиәсгар Камал исемен бирү турында карар чыгара.

75 ел элек (1944)

9-13 гыйнварда фашист илбасарларына каршы яу-фронттан кыска вакытлы ялга кайткан язучы Гадел Кутуй сәнгать эшчәннәре һәм укучылары белән очрашуларда катнаша.

70 ел элек (1949)

«Совет әдәбияты» журналында Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» романы басыла башлый.

60 ел элек (1959)

24 гыйнварда татар совет язучысы Әсгать Айдар (1905-1959) вафат була.

25 ел элек (1994)

22 гыйнварда Татарстан Республикасы Президентының «Казан Кирмәне» Дәүләт тарих-архитектура һәм музей-тыюлыгы»н төзү турындагы Указы (Фәрманы) игълан ителә.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■



СОДЕРЖАНИЕ. ЯНВАРЬ 2019

Историческое наследие: «Гаухаршад». О.Иванова**;** «Сагид». Ризаэддин Фахруддин**;** «Встреча Нового года в Чите». У.Сулази; «Журнал «Зритель». Л.Губайдуллин; «Последнее занятие Садри Максуди Арсала в университете Сорбонна». К.Лукман**;** «Изречения Ризаэддина Фахруддина».

Татарский мир: «Драгоценный камень Альметьевского театра». Р.Сагди.

Тюркский мир: «Древо раздора». А.Сарманбетов.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

В глубине памяти: «В памяти, до сих пор в памяти!».

Художественное наследие: «Древние татарские национальные музыкальные инструменты». Р. Гилязев; «Письма с тайной». А Гаффар.

Слово – украшение языка: «Будущее языка – наше будущее!» А.Гадель.

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Колодец мулл» в Епанчино»; «Страна валенок».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. JANUARY 2019

Historic heritage: «Gaukharshad» by O.Ivanova; «Sagid» by Rizaiddin Fakhreddin; «New Year celebrating in Chita» by U.Sulazi; «Spectator» magazine» by L.Gubaydullin; «The last class of Sadri Maksudi Arsal in the Sorbonne University» by K.Lukman; «The redes of Rizaiddin Fakhreddin».

Tatar world: «The gemstone of Almetyevsk theatre» by R.Sagdi.

Turkic world: «Tree of contention» by A.Sarmanbatov.

Religious heritage: «Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

In the deepest store of memory: «Still keeping in the memory, still keeping!

Creative heritage: «The ancient Tatar national musical instruments» by R.Gilyazev; «Letters with its secrets».

Word is a decoration of language: «Future of language is our future!» by A.Gadel.

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan»; «Mullahs' well in Epanchino»; «The felt-boots country».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.e

Сергей Лывин

Сергей Осипович Лывин 1923 елның 29 сентябрендә Татарстанның Питрәч районындагы Черемыш авылында туа.

1947 елдан Казан рәсем сәнгате училищесын тәмамлый. Бөек Ватан сугышы ветераны. 1952 елдан ул СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1960 ел), Татарстанның халык рәссамы (1973 ел), Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе (1978 ел).

Казанда яшәп, 2004 елда вафат була.

«Ат белән кышкы пейзаж». 1972.
Киндер, майлы буяу

«Табигать яшеллеккә төренә». 1975-1976. Киндер, майлы буяу

АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Бакый Урманче үз өе янында

Гөлайзә кыйссасы. Галим Хисамиев
Төрки кавемнәрнең кыскача тарихы. Хәсәнгата Габәши
Бакый Урманче: «Зур эшләргә көч, кабилият, мәхәббәт сизелә үзегездә». (Б.Урманче хатлары)
Исемле кошлар хуҗасы. Айдар Хәлим
Сүзләр иленә сәяхәт. Гәрәй Рәхим
Челлә, чиләк һәм челтәр. Рәис Сәфәров

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналына башкача язылу:
- ***uslugi.tatarstan.ru*** *сайты ярдәмендә*
- ***podpiska.pochta.ru*** *сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*